Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

01

гыйнвар 2017

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

«СЕЗГӘ МИННӘН АК ТЕЛӘК...»

Мирхәйдәр Фәйзи

17 нче бит

ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ



19 декабрьдә Казан Кремлендә Татарстанның беренче Президенты, хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә багышланган китапны тәкъдим итү булды. «Молодая гвардия» нәшриятында 34 нче китап булып, «Атаклы кешеләр тормышы. Биография дәвам итә...» сериясендә дөнья күргән әлеге күркәм басманың авторлары – Игорь Цыбульский һәм Нурсөя Шәйдуллина.

Матбугат чаралары җитәкчеләре һәм журналистлар да катнашкан әлеге тәкъдим итүдә М.Шәймиев, Ә.Сәфәров, В.Юркин, Н.Шәйдуллина, И.Таһиров, Ф.Бикчәнтәев, В.Якупова, Р.Хәкимов, Л.Андреева һәм башкалар чыгыш ясады.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
1 (277)
гыйнвар 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

48

97 РӘХМӘТ АҢА! *Рафаэль Сәхәбиев*

110 ИГЕЛЕКЛЕ ФАТИХА ЯДКЯРЕ. *Тәэминә Биктимерова*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Зөлфәт*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Һөнәрчелек остаханәләре**
6 **Илчеләр.** *Ә.Мөхәммәдиев*
11 **Белоруссия татарларының кульъязма мирасы.** *З.Канапацкая*
17 **«Сезгә миннән ак теләк...»** *М.Фәйзи*
25 **Истәлекләр.** *Б.Галиев*
34 **«Үзсүзле профессор» Садри Максуди.** *Ә.Сибгатуллина*
39 **«Безнең мирас»та — хәбәрләр**

ТАТАР ГАМЕ

40 **Минтимер Шәймиев.** *Р.Бохараев*
48 **Минтимер абыкай.** *М.Ильясова*
50 **Минем укучым — Президент!** *Х.Әхмәдуллина*

ДИНИ МИРАС

52 **Габдерәшит Ибраһимов.** *А.Рәхимова*
55 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ПЕДАГОГИК МИРАС

58 **Гаилә дәресләре.** *Ф.Сөләймания*

КАУРЫЙ КАЛӘМ

62 **Иман һәм иҗат.** *Ф.Галимуллин*

ӘДӘБИ МИРАС

70 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
74 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
80 **Зөлфәт хан яки Чытырманда бер былбыл сайрый.** *Л.Лерон*
86 **Үткәннән хатлар. Шигърият Мәҗнүне**

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

90 **И, гомер агышлары...** *Н.Каштанов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

92 **Әткәйнең сабаклары.** *Р.Вәлиев*
97 **Рәхмәт аңа!** *Р.Сәхәбиев*

СӘНГАТИ МИРАС

100 **Илче күчтәнәче.** *Р.Вәли*
104 **Сорнай, гөслә, кучнай...**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

106 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 **Гармун сайрый сандугачтай...** *Г.Җәләлева*
110 **Игелекле Фатиха ядкяре.** *Т.Биктимерова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның гыйнвар ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Вак-вак ләтыйфәләр һәм хикәя кисәкләре.** *Р.Шәрәфиева*

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Гыйнвар*
119 **Мирасворд**

Заказ №М-3348. Тираж – 1700 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.12.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Төнлә кар яуган». Киндер, майлы буяу.
Р.Газиев рәсеме



ЗӨЛФӘТ
(1947-2007)

Якты уйлар якты итәр
Дөньяның күген.
Сүз күтәрер без күтәрмәс
Дөньяның йөген.

***

Акыл сату җиңел, әмма никтер,
Сатып алып булмый акылны.

***

Һәр асыл шигырьнең үз тарихы бар.

***

Күңел тарихыннан мәхрүм шагыйрь – географиядән, тарихтан мәхрүм дәүләт ул.

***

Шигырь – ул, миңа калса, ургылып болганган җиһан өермәсеннән капшап табып алынып, камил тәртипкә, һични какшатмас ритмга салынган, бердәнбер аһәңгә буйсындырылган мәҗүси, кайнар сүзләр яңгырашы.

***

Халык һәрвакыт камил сүзгә омтыла. Коймалардагы оятсыз язулар, сурәтләр, такмаклар – шушы омтылышның югалуы нәтиҗәсе.

***

Карадагынай урман... Караңгы төн...
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә...
Заманалар авыр... Юллар ябык! –
Дус-иш кирәк дөнья күтәргә...
Колонизатор ыштыр урынына салып таптаган халык язмышы хакында язылырга тиешле меңәр томнарга тора бу дүрт юл. Татар язмышын аңлатыр өчен бүтән сүзләр эзлисе юк. Татар поэзиясе – каргышлы язмыш поэзиясе.

***

Асыл шигырь догага тәңгәл.

***

Дөньяны аңларга түгел, аңлатырга маташу – шагыйрьнең һәлакәте.

***

Йөрәк әрнүе сатылмый. Аның бәһасе юк. Адәм балаларының парламентларсыз гына кабул иткән конституциясе – шигърият.

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Болгар. Һөнәрчелек остаханәләре

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Алтын Урда чорында шәһәрнең үзәк өлешендә, Җамигъ мәчете янында шәһәр базары, ә анда сәүдә-һөнәрчелек рәтләре булган. Галимнәр билгеләп үткәнчә, археологик казулар вакытында, шактый күп нумизмат материал белән бергә, чимал, ярымфабрикатлар, сөяк, пыяла, гипс, төсле металлдан эшләнмәләр һәм аларны эшкәртү кораллары да табылган. Һөнәрчелек остаханәләре булдыру – музей-туристлык комплексы үсешенең чираттагы этабы, аның төп бурычларының берсе – борынгыдан ук килгән традицион һөнәрләрне саклау һәм популярлаштыру буенча эш алып бару. «Русский стандарт» холдингы (идарә рәисе – Рөстәм Тарико) акчасына төзелгән бу бинада хәзерге заман осталарына җитештерүне оештыру һәм музейга килүчеләр өчен интерактив дәресләр үткәрү өчен барлык шартлар тудырылган. Биредә мастер-класслар һәм Болгарның традицион технологияләрен торгызучы чүлмәкчеләр, металл, күн, агач эшкәртү осталарының сәүдә киосклары урнаштырылган. ■

ИЛЧЕЛӘР [1]

Әзһәр Мөхәммәдиев

Йә, кем сән?..
Йөрешең кайдин? Үзең каю җирдин?
Арып, имгәп, каю җирдин килерсез?
Әүеңез кайда? Ни иллег булырсыз?

Котыб. XIV йөз

К.Нәфыйков рәсеме

Вәзир Баян юлчыларга хәерле юл теләде. Бибарска текәлеп карап, соңгы үгет-нәсыйхәтләрен бирде:

– Тәңре ярлыкасын! – диде ул. – Вазифаң – Сүбәдәй бәһадиргә хат илтеп тапшыру. Ә төп бурычың бер генә: күр, ишет, сораш, бел, хәтерлә һәм онытма. Үз гаскәре элмә генә түгел, шактый зур булырга тиеш аның. Кайсы илгә баскынлык итәргә җыенуын аныкларга тырыш. Һич онытма, Болгар йорты язмышы кыл өстендә тора. Әгәр дә ул сизмәстән өстебезгә килеп ябырылса, илебезне харап итәчәк. Ә моңа юл куярга безнең һич иркебез юк! Даладагы күчмә халык, үзең беләсең, хәвеф-хәтәр килсә, мал-туарын, хатын-кызын, бала-чагасын ала да күченеп китә. Утрак тормышлы халык исә шәһәрләрен, авылларын һәм алар утырган елга-су буйларын – туган җирен үзе белән алып китә алмый. Туган җир-су, ата-баба җире – ул изге җир. Ышан, бу башыбызга беренче мәртәбә килгән бәла-каза гына түгел һәм соңгысы да булмас, безнең бурычыбыз – бернигә карамыйча, аны саклап калу!

– Ышанычыңны акларммын, остаз!

– Сиңа иптәшкә Тәкин чауш бара. Ул өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк тә. Аның сүзен тыңла, ләкин патша белеге[2] – синең кулыңда. Кирәк-нитә калса, үзең белгәнчә эшлә. Чөнки дошманга якынрак урнашкан кәрван-сарайларда яки ямнарда ямчыларның алмашка ат бирмәскә маташулары мөмкин. Ә арыган атлар белән ерак китә алмассыз. «Белгәнгә – белек, белмәгәнгә чыгар да селек», – дигән борынгы болгар бабайлар. Юлыгыз уң булсын...

Кәрвансарайдан һәм утардан торган бер ямнан икенче ямга чапкын ат өстендә, өч көн буе артык тиз баруларын искә алмаганда, сәяхәт әллә ни үзенчәлекле булып башланмады. Юллар башы Рахман бий яхшы ук тәртип кертеп өлгергән иде булса кирәк: алар барып җиткән бер ямда патша тамгасы сугылган белекне күрсәтү белән ямчылар илчеләрнең ак күбеккә баткан атларын ял иткән яңа чапкыннарга алыштырып кына торды.

Шул ук көнне алар зур көймәләрдә атлары-ниләре белән Иделне кичеп, шактый зур Сембер шәһәрен уздылар, ә икенче көнне инде Идел буйлап Самар шәһәре турына төшеп җиттеләр, ләкин ул Иделнең сул якка таба шактый ерак борылышында урнашканга күрә, аңа кереп тормадылар. Аннары Укәк[3] аша Бөрҗан шәһәренә таба юл тоттылар.

– Артыгын ашыгабыз түгелме? – дип сорады Тәкин чауш. – Шактый юл алынды, арылды да.

Бибарс исә дәшмәде, ләкин атының тезгеннәрен бераз тарта төште. Аның тизрәк үзенең туган шәһәренә барып җитеп, әнисен күрәсе килә иде.

Болгардан әле артык ерак кителгән кебек тоелмаса да, табигать күз алдында үзгәрә барды: урманнар сирәгрәк күренә башлады, ә кырлар, акрынлап, чәнечкеле үләнле далага әверелә барды. Бернинди болытсыз, чалт аяз күктәге кояш кыздырганнан-кыздыра. Бары чал Идел генә, берни дә булмагандай, эссе кояш нурлары астында, салмак кына, диңгезгә таба ага. Яр буендагы кызган комлык һәм комаякларда – ком утрауларында – акчарлаклар кычкырыша.

...Өченче көнне, тагын иртәдән алып кичкә кадәр бертуктаусыз ашыгып ат өстендә чапканнан соң, арыган юлчылар

[1] «Илчеләр» – «Чыңгызхан хәйләсе» әсәренең чираттагы бүлеге.
[2] Белек – указ, язу.
[3] Үкәк хәзерге Саратов тирәсендә, ә Бөрҗан урынында исә Волгоградтан югарырак урнашкан Дубовка утыра. Ул Идел ярында Тын елгасының иң якын килеп аккан борылышы турында урнашкан булган.

Бөрҗан шәһәренә якынлаштылар. Көне буе кайнар кояшта янганга күрә, бу зур булмаган, ләкин төзек һәм матур шәһәр аларга эссе һәм коры дала уртасындагы гүзәл бер бакчалы сарай булып тоелды.

Көн кичкә авышкан булса да һаман да эссе, ә урамдагы шәм кебек булып үскән өянкеләр аз булса да күләгә һәм җиләслек бирә. Өч ягыннан коры кылган гына үсеп утырган дала урап алган шәһәр урамнары, сөзәкләнеп, Иделгә таба төшә. Астарак, шәһәр уртасында, яшеллек арасыннан зур таш мәчет манарасы күренә.

Ниһаять, юлчылар шәһәрдән читтәрәк олы юл буенда урнашкан ям йортына килеп җитте. Ям йорты саман кирпечләреннән тоташ итеп салынган өч бинадан гыйбарәт булып, бер башы аның – ямчы өчен, икенче башы – кунакларга, ә уртадагы ачык түбәлесе атларга дип салынган иде, күрәсең.

– Биредә кунып китәрбез, – диде Бибарс, атыннан төшешли.

Яр башында утырган Бөрҗан шәһәренә күзен дә алмый карап торганнан соң, Тәкин:

– Күп шәһәрләр күргәнем бар, әмма дә мондый, синең туган шәһәрең кебек төзек һәм гүзәлен күргәнем юк иде әле. Кызганыч, этиеңне һәлак иткәннәр явыз илбасарлар... – дип өстәде.

– Тагын берничә көн ат өстендә чапсаң, баш астына салган ияр дә йомшак ястык булып тоела башлар әле, – дип җавап бирде Бибарс, көлеп. – Бу гади шәһәр генә түгел, ә мәгълүм кирмән дә.

– Рәхим итегез, кунаклар, – диде ерактан килгән юлчыларны каршы алырга чыккан ям тотучы. – Исән-имин генә килеп җиттегезме? – дип сорады ул, Бибарс сузган белекне карап.

– Рәхмәт, сезнең хәер-фатиха белән.

– Сезгә иртәгә атлар кирәк булырмы, әллә олау гынамы?

– Бәрәкалла, атлар кирәк булмыйча, нәрсә кирәк булыр икән соң безгә? – дип гаҗәпләнде Тәкин ямчының соравына.

– Кызыксынуымның сәбәбе шул, – диде ямчы үзенең соравын аңлатып, – Румга яки Кырымга юл тотсагыз, биредән Тын[4] елгасына бары бер илле чакрым чамасы гына юл кала. Юлчылар һәм сәүдәгәрләр ул уңайга иркенләп олау белән китәләр, ә Тын елгасына барып җиткәч, тауарларын өчәнгә яки туры килсә, бишәнгә төяп, юлларын дәвам итәләр.

– Безгә атлар кирәк булыр.

– Һәм яхшы атлар, – дип өстәде Тәкин.

– Елгага барып, юл тузаннарын юыштырып килик әле, – диде Бибарс, ямчыга карап, – ә син, ага кеше, исемеңне сорамадым ...

– Туктар.

– Туктар ага, кичке аш әзерләттер, акчасыннан тормабыз.

– Сукта[5] булмас инде, Туктар абзый, тик сарыкның калак сөяген, йә умырткасын зуррак итеп салдыр, юлда чабачаба эчләр какланып бетте, – дип өстәде Тәкин.

Бераздан алар, шәһәр читеннән яр буена төшеп, Иделгә карап хозурланып тордылар. Текә яр астындагы култыкта кояшта каралган берничә малай кармак салып утыра. Юлчылар яр астына төшеп уңгарак каерылдылар һәм комлыкта чишенеп, Идел суының рәхәт, җиләс агымын тоеп, ләззәтләнеп су коендылар.

Су коенып менешли Тәкиннең игътибарын биек итеп эшләнгән мәрмәр бинасыннан читтәрәк салынган мәчет манарасы җәлеп итте. Әлбәттә, мондый манараларны аның Болгарда да күргәне бар иде. Манара җиргә салынган дүртпочмаклы таш нигездән гыйбарәт булып, югарыга таба түгәрәкләнә һәм очлая бара. Манара зәңгәр күк төсле крәч йөгертелгән фирүзә кирпечләр белән

---

[4] Тын – Дон елгасы.

[5] Сукта – тозлап-борычлап чабылган үпкә-бавыр тутырылган майлы эчәк. Яңа чалынган сарык эчкарынынннан ясыйлар.

капланган. Кирпеч аралый пәйгамбәр исеме язылганнары чиратлаша, ә шахмат тәртибендә ниндидер тамга кабатлана иде.

– Егылып китим, балык башына охшаган менә бу тамга, – диде ул, манарага төртеп күрсәтеп, – синең куендагы белектә дә бар!

Бибарс, манарага якынрак килеп, тамганы игътибар беләнрәк карады.

– Дөрес әйтәсең, балык башыннан бигрәк, бу тамга борынгы төрки әлифбасындагы «б» хәрефен хәтерләтә һәм ул Болгар патшалары тамгасы булса кирәк.

Мәчетнең киң ишеге ачык булганга, алар эчке якка керделәр һәм алтышар-алтышар биш рәт булып тезелеп киткән мәрмәр баганалар, ә түр якта аршын озынлыгындагы төсле крәч хәрефләрдән торган сүрә белән бизәлгән мөнбәр күрделәр. Ишеккә таба килгән ак сакаллы олы гына яшьтәге кешене күреп, Тәкин аңа беренче булып сәлам бирде:

– Гафу итәсез, – диде ул аңа, тегесе сәлам алганнан соң, – без – Болгар әмире йомышы белән юл тотучылар. Мәчетегезнең матурлыгына хозурланып торуыбыз. Ә манарадагы болгар әмире тамгаларын күргәч, кызыксынуыбыз тагын да артты.

Карт шактый ук сөйләшергә яратучан кеше булып чыкты. Ул, юлчылар янында туктап, иркенләп сөйләп китте:

– Кешесенә туры килдегез, улым, мин – бу мәчетнең имамы, – диде ул. – Бабалар сүзенә караганда, мәчетне борынгы хазәр патшасы Болан каган салдырган. Ул Идел буенда беренчеләрдән булып ислам динен кабул иткән[6]. Болгар әмире тамгасына килгәндә исә, мәчетнең мәрмәр дивары ике аршын калынлыкта булса да, ул карап торуга гына шулай калын кебек, ә үзе борынгыларча ике чыт итеп төзелгән. «Өй салуның ние бар, мүклисе дә чутлыйсы», ди мәкаль. Менә шул эчтән һәм тыштан салынган мәрмәр чыт уртасына балчык тутырылган. Заманалар үтү белән ул тузган, урыны белән ишелеп төшкән. Шуңа күрә дә әмир, тәңре аңа озын гомер бирсен, мәчетне төзәттерде, ныгыттырды. Ә мөнбәр янындагы өстенә баскыч-баскыч итеп кирпечтән салынган зәңгәр гөмбәзле кабергә килгәндә исә, картлар сөйләвенә карганда, анда каган Болан күмелгән, дип сөйлиләр...

– Нишләп ул башы белән Мәккә ягына түгел, ә көнбатышка табарак каратып күмелгән? – дип сорады Тәкин.

– Мәҗүси заманнардан калган гадәт. Бездә кайберәүләр хәзер дә шулай җирлиләр, тик мәетнең йөзен генә һәрвакытта да Мәккәгә таба каратып күмәләр.

– Рәхмәт, хәзрәт. Укымышлы кеше белән сөйләшү яңа бер китап ачкан кебек, үзе бер куңелле хәл, – диде Бибарс, болгарларча мәдхия әйтеп.

– Мөмкин булса, тагын бер соравым бар, хәзрәт: мин үзем тумышым белән Кыпчак сәхрәләреннән. Бөрҗан халкының сөйләшүе башкачарак, мәсәлән, сез «мәтсет» дип сөйләшәсез. Сез хазәр токымыннанмы?

– Дөрес, улым, без хазәр ыруыннан, ләкин тарих язмаларына караганда, хазәр ул халык исеме түгел, ә ил исеме булса кирәк. Чөнки болгары да, суары яки хазәры да заманында шул ук бер дәүләткә – Хазәр дәүләтенә кергән һәм бер телдә – гомумтөрки теленең кыпчак җирлегендә сөйләшкән.

Тәкин, рәхмәт әйтеп, мәчет картына хәер биргәндә, Бибарс та үзеннән өлеш өстәде. Ләкин аның күңелен һаман бернәрсә борчып торды. Чөнки Бөрҗаннан Баян остазга ияреп Болгарга йөз тотып чыгып киткәннән бирле, әнисенең исәнме-түгелме икәнлеген белми иде ул... Хәзер аның күңелендә бер генә хис – тизрәк шәһәргә кереп, та-

---

[6]Идел буенда рәсми рәвештә ислам кабул итүнең 737 нче елда булганлыгы гарәп чыганакларыннан мәгълүм.

ныш урам һәм тыкрыклар буйлап туган өенә – әнисе янына ашыгып барып, аның белән күрешү иде. Аның үзе яшәгән җир идәнле кечкенә бер бүлмәгә Болгар кешесе Тәкин чаушны ияртеп алып барасы килмәде. Әнисе турында да аңа бернәрсә дә сөйләп тормады. Шуңа күрә дә текә ярдан күтәрелеп, шәһәр капкасы турына җиткәч, ул:

– Ярар, Тәкин, сарык ите пешкәндер, син кәрвансарайга кайтып кичке ашны ашый тор, ә мин таныш урамнарга бер күз салып чыгыйм әле, – дип, капкага таба борылды.

Таныш урамнардан атлый-атлый, Бибарс шәһәр читенә таба китте. Әле күпчелек халык эштә булганга күрә, урамнарда халык сирәк күренгәли. Үзләренең тар гына тыкрыклары борылышында ул һич тә көтмәгәндә каршыга килүче икенче берәү белән бәрелешә язды. Тегесе куркуыннан чигенде һәм таш диварга сыенып юл бирде. Аның бала вакытта сабан туйларында үзе белән бергә көрәшеп, уйнап йөргән таныш иптәше икәнлеген күргәч, Бибарс елмаеп куйды:

– Кая чигенәсең, Минаҗ, әйдә, көрәшәбез!

– Кит аннан, Бибарс, син бит бу! Яхшы киемнәрдән булгач, мин сине бер түрә дип торам, чигенмәссең!

– Нинди яхшы кием инде, юлдан гына мин. Иртәгә иртүк тагын юлга чыгасым бар, әнинең хәлен белеп чыгыйм дигән идем. Шәт, исән-тазадыр бит?

– Исән, исән! Бурнаш морзаны беләсең бит, син дә аның кул астында хезмәт иттең, минем дә аның янына китеп баруым. Ул әниеңә һәрвакыт ярдәм кулы сузып тора.

– Рәхмәт, монысы күңелле хәбәр!

– Ярар, Бибарс, мин Кирмән түбәсенә сакка ашыгам. Кайткач, иркенләп сөйләшербез!

– Иркенләп сөйләшеп булмас, Минаҗ, бергә килгән юлдашым кәрвансарайда чапкыннар барлап, көтеп калды. Үземә бүген үк аның янына китәргә кирәк, чөнки иртә таң белән без юлда булырга тиеш. Сау бул!

Ул өй ишеген ачып кергәндә, әнисе сәкедә баш астына катлап салынган мендәр өстендә ятып тора иде. Ишек тавышын ишетеп, ул җәһәт кенә торып утырды һәм Бибарсны танымыйча, аңа карап:

– Кем булдың син, улым, танымыйм, күзләрем начар күрә башлады. – дип эндәште.

– Әй, әни, бердәнбер сөйгән улыңны танымый тору ярамый бит инде! – дип, шаяртып эндәште Бибарс, әнисен кочаклап.

Әнисе белән күрешүе бик кадерле һәм күңелле мизгелләр булса да, тиз генә китәрмен, дип уйлаган иде, ләкин озак та тормыйча, Минаҗга яңа суйган ярты сарык түшкәсен күтәрткән, ә үзе чәй-шикәр тоткан морза Бурнаш килеп керде. Ул Бибарс белән кочаклашып күреште. Ә Бибарс үзенең юлга чыгарга бик тә ашыгуын аның исенә төшергәч, ул көр бер тавыш белән:

– Ярты сәгатьтән без сине озатырбыз, Бибарс! Биредә туып-үсеп, болгар патшасына хезмәт иткән егетләребезне чәй эчертмичә дә җибәрә алмыйбыз бит инде, – диде ул, елмаеп. – Аннары, – дип өстәде ул, – без биредә Болгар дәүләтенең көньяк-көнчыгыш чикләрен саклаучы хәрби кешеләр. Шуңа күрә, һичшиксез, болгар хөкүмәтенең аяусыз һәм явыз юлбасарларның басып алуына каршы юнәлтелгән катгый сәясәтен без дә белеп торырга тиеш!

Бурнаш морзаның ярты сәгать дигәне ике сәгатькә сузылды, ләкин әнисе Бибисараның нурлы йөзенә карап сөйләшеп үткәргән бу сәгатьләр өчен ул үкенмәде.

Дәвамы бар ■

ТАТАР КИТАБЫ

Белоруссия татарларының кулъязма мирасы

Зорина Канапацкая

Бөек Литва кенәзлегендә татар теле турында тәүге мәгълүмат XIV гасыр башына нисбәтле. 1324 елгы франциска елъязмасында: «Литва дәүләтенә Христос тәгълиматын өйрәтер өчен җибәрелгән монахлар, күтмәгәндә, ниндидер ханнан килгән кешеләрне һәм аларның үзләренчә дога укуларын күрәләр», – дип язылган. Инглиз патшалыгының илчесе Жилбер де Ланнуа (1386-1462), 1414 елның февралендә Вильнүстән Тракай аша Пруссиягә барганда, көндәлегенә күп авылларда татарларның шактый ишле булуын һәм аларның туган телләрендә сөйләшүен теркәп куйган.



Мостафа Мискевич күчереп язган Коръән. Минск районы, Узда. 1853 ел

* Мәкалә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе һәм Саба муниципаль районы хакимияте 2016 елның 14-15 июлендә Ә.Г.Кәримуллин истәлегенә багышлап оештырган укуларда чыгыш ясаган Белоруссия дәүләт университеты доценты, тарих фәннәре кандидаты Зорина Ибраһим кызы Канапацкаяның доклады нигезендә әзерләнде. Авторның сөйләгәннәре белән http://beznenmiras.ru/ сайтыннан танышырга мөмкин.

Бөек Литва кенәзләренең курку белмәс, батыр татар ир-атларын үзләренә хәрби хезмәткә чакыруы гадәти хәл булган. Тевтонлыларга каршы 1319 елгы сугышта да татарлар бөек кенәз Гедимин (1316-1341) гаскәренең иң алгы сафында кан койган. Соңрак Литваның бөек кенәзләре Кейстут (1381-1382) һәм Ольгерд (1345-1377) Тәре йөртүчеләр ордены белән бәрелешләрдә, Польша һәм Мәскәүгә каршы сугышларда да еш кына Дәште Кыпчак татарлары белән килешү төзегән. Шул вакыттан ук кайбер татар гаскәриләре, литва кенәзләренә даими рәвештә ярдәм итеп һәм аларда солдат хезмәтен башкарып, шундагы шәһәр һәм замок тирәләренә төпләнеп тә калганнардыр, мөгаен.

Татарлар яшәгән иң зур авыл XIV гасыр азагында, ягъни бөек кенәз Витовт идарә иткән елларда (1350-1430) оешкан. Аның заманында Алтын Урда дәүләте һәм Гәрәй нәселеннән булган Кырым ханнары белән тыгыз элемтә урнаша. 1569 елда, Польша патшалыгы һәм Бөек Литва кенәзлеге арасында булган Любин килешүе нигезендә, Речь Посполитая оешкач та, Кырым ханлыгы белән уңай мөнәсәбәтләр дәвам иткән.

Бөек Литва кенәзлегенә XIV-XV гасырлар чигендә Алтын Урда һәм Кырымнан күчеп килгән татарлар чагатай телендә сөйләшкән. Белоруссия татарларының шул чорда язылган хамаилләрендә (догалыкларында) дә чагатай телендәге текстлар шактый күп. Алтын Урда составына кергән кабиләләрнең төрле диалект-шивәдә аралашуы бәхәссез, әмма язма һәм сөйләм теленең үсешендә хәлиткеч рольне югары катлам вәкилләре сөйләшкән чагатай теле уйнаган. Бу тел белорус татарларының борынгы кулъязма мирасында, кайбер фамилияләрдә, герб һәм азык-төлек атамаларында сакланып калган.

Белорус татарлары XVI гасырдан башлап госманлы мәдәниятенең көчле йогынтысы тәэсирендә яши. Татарлар изге хаҗ сәфәрен кылганда Госманлы дәүләтендә туктала торган булганнар. Бу йогынтының бер дәлиле булып 1558 елда Польша татарлары турында язылган «Risale-i-Tatar-i-Lech» кулъязмасы тора. Әмма бу чорда татарлар чагатай телен онытa башлый, Казан һәм Идел буе, Урта Азиядәге төрки дөнья белән элемтә өзелә, күпмедер дәрәҗәдә якын булган Кырымның да теле һәм мәдәнияте госманлаша. Төркиягә сәфәр кылган татарлар госманлы телен бик тиз үзләштергән һәм үзләре белән дини китаплар да алып кайткан. Шуның нәтиҗәсе буларак, Белоруссия татарларының XVII гасырда һәм аннан соң күчерелгән кулъязмаларында госманлы телендәге текстлар еш очрый.

«Risale-i-Tatar-i-Lech» исемле хезмәттә шәһәрдә яшәүче татарларның телне онытулары, әмма үз динен саклаулары турында мәгълүмат та теркәлгән. Шул ук вакытта төрекчә сөйләшүче татарлар да булган, гадәттә аларның күбесе Госманлы дәүләтендә яшәп кайткан кешеләр.

Татарларның XVI гасырда ук туган телне онытулары турында башка чыганаклар да дәлилли. 1581 елда билгесез авторның Давид Хитраэсуга язган хатында белорус татарларының җирле телләрдә сөйләшүе искәртелә. XVII гасыр башында кайбер татар авылларында яшәүчеләр төрекчә сөйләшкән. П.Чижевский үзенең 1616 елгы «Alfurkan tatarski» китабында белорус татарларының үзгә, гадәти булмаган телләре турында яза. Әмма XVII гасыр дәвамында белорус татарлары тулысынча диярлек төрек телен дә оныта, моны шул чорның күренекле тарихчысы Ибраһим паша язмалары дәлилли.

Татарларның чагатай телен, соңрак госманлы төрекчәсен дә онытулары славян телле гарәби язулы китаплар барлыкка килүгә сәбәп булган. Аларның белорус теленә беренче тәрҗемәләре XVI гасырда, ә поляк телендәгеләре XVII-XX гасырларда барлыкка килә.

Әлеге китапларның эчтәлегенә

килгәндә, алар Коръәннән өзекләр, пәйгамбәрләрнең, беренче чиратта Мөхәммәт с.г.в.нең тормышкөнкүрешеннән мәгълүматлар һәм хәдисләрдән гыйбарәт. Мигъраҗ, ягъни пәйгамбәребезнең (с.г.в.) Аллаһ хозурына күтәрелүе турындагы риваять XVIII-XIX гасырларда күчерелгән биш китапта һәм Белоруссия галиме Ибраһим Канапацкийның шәхси тупланмасындагы Ибраһим Хәсәневич кулъязмасында да (1832) очрый. Шәркыятьче Г.М.Мередит-Оуэнс һәм белорус мәгърифәтчесе А.Надсон бу риватьяне Лондондагы Британия китапханәсендә сакланучы 1831 елгы китапта таба. Әлеге риваять Белоруссия Милли китапханәсе коллекциясендәге кулъязмада да бар. Шулай ук әлеге китапларда сюжеты Коръәнгә нигезләнгән башка әсәрләрне дә табарга мөмкин.

Һәр китап, кагыйдә буларак, әхлакый тәрбия бирүне максат итеп куйган. Аларда ата-ананы, өлкәннәрне, авыру-ятимнәрне, күрше-тирәне, галим-голәмәне, имамнарны хөрмәт итү – үзәк темалардан. Бередә XVIII гасырда күчерелгән бер китапның бүлек исемнәренә тукталып үтү урынлы булыр: «Ата-анага ихтирамлы мөнәсәбәт турында», «Ятимнәргә итагатьле мөнәсәбәт турында», «Күршеләр белән яхшы мөгамәлә турында», «Кунакларга кадер-хөрмәт белдерү», «Өлкәннәргә һәм галимнәргә хөрмәт», «Исерекләр турында хикәят». Китапларда кеше тормышындагы рухи-әхлакый кыйммәтләр турында сөйләүгә зур урын бирелгән.

Безнең фикеребезчә, нәкъ менә шушы китапларда белорус татарларының тарихи риваятьләре дә саклaнып калган. Кызганыч ки, хәзерге көнгә кулъязма мирасның күп өлеше юкка чыгу сәбәпле, XIX гасырның беренче яртысында яшәгән авторларның әсәрләреннән кайбер өзекләр генә билгеле. Аларда кыпчак ханнары, биләмәләре, хан басмачылары турында мәгълүматлар бар.

Күп китапларда ислам дине канунннары турында, гореф-гадәт, йолалар, мөселманның бурычлары, ураза, сәдака бирү, намаз, хаҗ кылу хакында тәфсилле итеп язылган. Бу хезмәтләрдә иң үзәк мәсьәлә – иман һәм Аллаһның барлыгы, берлеге. Төшлекләр, Коръән хәрефләре белән киләчәкне фаразлау, йолдызнамә, шәрыкның маҗаралы сюжетларына корылган әсәрләр күп күчерелгән. Шуңа күрә, әлеге кита-

Ибраһим Хәсәневич гарәп, белорус, поляк телләрендә күчереп язган китап. Минск районы. 1832 ел



Гарәп, белорус, поляк телләрендә язылган тәфсир. Китапның хуҗасы Ягъкуб Мейшутович булган, ә аннары –Исмәгыйль Канапацкий. Минск районы, Смиловичи. 1797 ел

пларны эчтәлеге буенча дини-фольклор әсәр буларак тасвирларга мөмкин.

Белоруссия татарларының язма мәдәниятен өйрәнгәндә хамаилләр – төп тексты гарәп һәм төрки телләрдә язылып, белорус яки поляк телендә мәгънәләре аңлатылган догалар җыентыгы да кызыксыну уята. Зур күләмле хамаилләрдә, догалардан тыш, календарь, төрле авыруларны кыска дога белән дәвалау ысуллары, авыр көннәр турында мәгълүмат, төшлекләр, астрологик фаразлаулар да бар. Слоним шәһәрендә догалары гарәпчә, ә аңа аңлатмалары чагатай телендә язылган хамаил сакланып калган. Чагатай хамаилен хәзерге урыс яки поляк теленә тәрҗемә ителгәне белән чагыштырып карасак, гарәпчә текстның шул ук икәнлеге күзгә ташлана. Хамаилләрнең дә эчтәлеге китаплар кебек үк төрле, андагы кайбер текстларны башка китапларда да очратырга мөмкин. Хамаилгә, гадәттә, аеруча еш укыла торган догалар кертелгән һәм алар күп күчереп таратылган. Форматы гадәти китаплардан гаять кечкенә булуы аларның көндәлек, белешмә әдәбият сыйфатында куллану өчен яраклаштырылганлыгы турында сөйли. Нәкъ менә хамаилләрдә чит этник тирәлектә һәм башка климат шартларында Белоруссия мөселманнарының дини күзаллаулары, мөселманча яшәү рәвешләре ачык чагыла. Бу чыганакларда ислам диненең славян гореф-гадәтләре һәм ышанулары белән яраклашуы күзәтелә.

Татар халкының дини әдәбиятында тәфсирләр дә төп урынны алып тора. Коръән текстлары, тәфсирләрдән өзек буларак, барлык төр язма истәлекләрдә, аеруча дини китапларда һәм хамаилләрдә еш очрый.

Тәфсирләр – Коръәннең юл араларына язылган шәрех-аңлатма һәм тәрҗемәләрдән гыйбарәт. Аларда белорус теленә поляк теленең йогынтысы һәм поляк телендә белорус теле элементлары ачык күренә. Коръәннең белорус теленә тәрҗемә ителгән кулъязмасы табылмаса да, аерым китапларда белорусча тәфсирләр еш очрау аның булганлыгы турында фаразларга нигез бирә.

Тәфсирләр нигездә зур форматлы кәгазьдә язылган, уртача күләме 1000 биттән гыйбарәт. Хәзерге көнгә берничә тәфсир табылган, алар арасында иң борынгысы – Минск мәчете имамы Үрәш бине Исмәгыйль тарафыннан 1686 елда күчерелгән «Минск тәфсире». Татарлар Коръәнне дөрес укырга өйрәтә торган китапларны – тәҗвидләрне дә еш күчергән.

Дини китапларны гадәттә мулла-

мөәзиннәр, шулай ук физик хезмәткә сәләтсез, әмма иманы нык булган картлар күчереп язган. Китап язу – саваплы гамәл, бу эшне башкарган кеше зур ихтирам һәм хөрмәткә ия булган. Коръәнне аеруча матур каллиграфик хәрефләр белән җентекләп күчерергә тырышканнар, ә хамаилләр гадәттә тиз язылган. Язу өчен каләм – каз каурые, язу карасы итеп өйдә эшләнгән энкауст – кара буяу яки зәгъфраннан ясалган кызыл кара файдаланылган. Энкауст атмосфера йогынтысына гаять чыдам булган. Китаплар әйбәт сыйфатлы кара, ялтыравыклы энкауст белән яхшы кәгазьгә язылган, кайбер ядкярләрдә, мәсәлән, хамаилләрдә энкауст начар булып, вакыт узу белән кулъязманың сыйфаты шактый начарайган. Китапларда баб, ягъни бүлек исемнәрен язар өчен кызыл энкауст файдаланганнар. Шундый китапларда аятьләр дә кызыл кара белән күчерелгән. Ляховичи шәһәрендә кабергә куеп калдыра торган догалыклар да яхшы сыйфатлы зәгъфран белән язылган.

Китап язу вакытны күп алган. Бу хезмәт шактый кыйммәт булу сәбәпле, аннан нигездә татарның хәлле кешеләре файдаланган. Белоруссия татарларында китап буыннан-буынга кадерле ядкяр булып күчкән. Коръән һәм догалыкларга аеруча сакчыл мөнәсәбәт күрсәтелгән, аларны кыйммәтле асылташ кебек саклаганнар. 1529 елда Польша короле Сигизмунд I нчегә үтенеч белән мөрәҗәгать иткән кенәз Мәхмүт һәм Фирс Юхнович Ассанчуковичлар сөйләвенә караганда, абыйлары Килдеш Дмитрович Петрович алар исеменә, «сарай һәм төрле күчемсез милек белән бергә, көмеш, китаплар, крепостнойлар, атлар һәм мөгезле эре терлек» кебек мал-мөлкәтен яздырган.

Китапны сәнгати яктан аеруча зәвыкле итеп күчерүче кешеләрдән «мугир» (мөһер, казан татарларында шәмаил) язуын үтенгәннәр. Гадәттә Коръән аятьләре янына мәчетнең рәсеме дә матур итеп ясалган. Рамга салынган «мугир»лар белорус татарларының йорт һәм мәчет диварларын бизәгән.

Китап азагына күчереп язучы үз исемен, датаны теркәп калдырган. Мәсәлән, хәзерге Польшадагы татар авылы Куршиняныда табылган XVIII гасыр китабына гарәп язуы белән: *«Бу китап Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) Мәккәдән Мәдинәгә күчкәненең (ягъни һиҗри белән) мең ике йөз дә алты йөзенче елында, җөмадиәл ахирнең бишенче көнендә Сандыковщизнада Литва гаскәре наместнигы Йосыф Хәлишевич тарафыннан язылды»*, – дип теркәлгән. Аннан соң шундый ук эчтәлектәге ике җөмләдә китапның милади вакыт хисабы белән 1792 елның 29 гыйнварында язылганлыгы күрсәтелгән. Аның беренчесе поляк телендә поляк хәрефләре белән, икенчесе белорус телендә кирилл графикасында язылган. Аңлашыла ки, бу язмалар белорус татарларының дини әдәбияты тарихын өйрәнгәндә, кулъязмаларны тасвирлаганда гаять зур әһәмияткә ия.

Белоруссия китапханәләрендә һәм Гродно шәһәренең дин тарихы музеенда татарларның XVII гасыр азагы-XIX йөзнең беренче яртысына нисбәтле 39 кулъямасы (шул исәптән кулъязма фрагментлары) бар. Белоруссиядәге коллекция, дөньяның башка дәүләти тупланмалары белән чагыштырганда, шактый бай. Чагыштыру өчен: Литвада – 40 (XVIII гасырның беренче яртысы-XX гасырның беренче яртысы), Россиядә – 8 (XVII гасырның уртасы-XIX гасырның беренче яртысы), Украинада – 1 (XIX гасыр башы), Польшада – 10 (XIX гасыр башы-XX гасырның беренче яртысы), Англиядә – 3 (XVIII гасырның беренче яртысы-XIX гасырның беренче яртысы), Германиядә 1 (XVII гасырның беренче яртысы) кулъязма саклана.

Белоруссия татарлары кулъязмаларын өйрәнү белән шөгыльләнүчеләр арасында Лондондагы Франциск Скорина исемендәге белорус китапханәсе директоры А.Надсон, поляк галимнәре

А.Дрозд һәм Ч.Лапич, Швейцариянең тел галиме П.Сутер, Литва галиме Г.Мишкинене һ.б. бар. Белоруссия ФА Үзәк фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләре М.Тарелко һәм Е.Титовец тарафыннан, әлеге китапханәдә сакланучы кулъязма мирас белән бергә, Белоруссия Милли китапханәсе һәм Гродно дәүләт дин тарихы музеендагы татар китаплары да тикшерелде. 1997 елда Минск, 2000 елда Варшава, 2003 елда янә Минск, 2005 елда Вильнүс шәһәрләрендә татар кулъязма китапларының каталогы басылып чыкты*. Ибраһим Канапацкийның тырышлыгы белән 1997 елда Белоруссия дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты музеенда, 2001 һәм 2003 елларда Белоруссия ФАнең Үзәк фәнни китапханәсендә белорус татарларының кулъязма мирасы тупланган күргәзмә оештырылды.

Татар китабын каталоглаштыру эше болар белән генә тәмамланмады. Кулъязма мирасның шактый өлеше шәхси тупланмаларда да саклана, әмма аларның күбесе исәпкә алынмаган һәм өйрәнелмәгән. Кызганыч ки, белорус татарларының әдәбияты турында тар даирә белгечләре генә белә. Әлегә кадәр бер генә гарәби язулы язма мирас та, басылып чыгып, хәзерге укучысын тапмады. Аларны киләчәк буынга җиткерү, хәвеф-хәтәрдән саклау өчен электрон күчерелмәләре дә алынмады.

Белоруссия татарларының кулъязма мирасы славистлар һәм шәркыятьчеләр өчен шактый зур фәнни әһәмияткә ия булуы турында А.Зайончковский, Е.Карский, И.Крачковский, А.Самойлович кебек галимнәр язып чыкты. Әдәби-дини җәһәттән тыш, алар, борынгы белорус теле ядкяре буларак, тарихи-лингвистик яктан да игътибарга лаек.

Шуны әйтергә кирәк: иске белорус теле кирилл хәрефләренә нигезләнеп, язуда әлеге телнең XVI гасырдагы кайбер үзенчәлекләре чагылыш тапмаган, әмма болар XVI-XVIII гасырда күчерелгән гарәби язулы татар язма истәлекләрендә сакланып калган.

Е.Карский фикеренчә, нәкъ менә гарәби язулы кулъязмалар *«XVI-XVIII гасырдагы белорус теле турында шактый кызыклы мәгълүмат бирә. Әгәр дә гарәп графикасында язылган барлык белорус текстларын укып чыгабыз һәм тикшерәбез икән, телнең традицион орфографиядә язылган ядкярләрдә чагылыш тапмаган шактый кызыклы үзенчәлекләре табылыр иде»*.

Шулай итеп, гарәп графикасында язылган белорус телле татар кулъязмалары, башка чыганакларга караганда, бу телнең фонетик үзенчәлекләрен яхшырак чагылдыра. Татар кулъязма китабы тарихын өйрәнү белорус теле тарихындагы ак тапларны бетерергә ярдәм итә. XVII гасырда башланган поляклашу белорус телен гамәлдән кысрыклап чыгарганнан соң да, татарлар дини генә түгел, дөньяви эчтәлектәге язмаларны да элекке гадәт буенча белорус телендә күчергән. Кулъязмаларның полякча язылган дип саналганнарын да нык белоруслашкан поляк теленең җирле сөйләм варианты дип әйтергә мөмкин. Шуңа күрә, гарәби язулы татар кулъязма мирасы белорус-поляк телләре багланышын өйрәнгәндә дә мөһим чыганак булып хезмәт итәргә мөмкин. ■

* Татар кулъязма китабының каталоглары:
Рукапісныя і друкаваныя кнігі беларускіх татар: Каталог выставы / Укладальнікі: Доўнар Л., Самайлюк Т., Дзем'яновіч Т. – Мн., 1997.
Drozd A., Dziekan M., Majda T. Pismiennictwo i muhiry Tatarow polsko-litewskich. – Warszawa, 2000. – T. 3.
Мишкинене Г. Каталог арабскоалфавитных рукописей / Г. Мишкинене, С. Намавичюте, Е. Покровская – Вильнюс, 2005.
Рукапісы беларускіх татараў канца XVII – пачатку XX стагоддзя з калекцыі Цэнтральнай навуковай бібліятэкі Нацыянальнай акадэміі навук Беларусі / Укладальнікі: І.А. Ганчарова, А.І. Цітавец, М.У. Тарэлка. – Мн., 2003.

Сезгә миннән ак теләк...

Казан (Идел буе) федераль университетындагы Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, Ә.Максуди, Х.Габәши, Х.Гали, Г.Тукай, Г.Ибраһимов һәм башка татар әдип-галимнәренең кульязма мирасы саклана. Шулар арасында татар әдәбияты классигы Мирхәйдәр Фәйзинең (1891-1928) дә шәхси архивы игътибарга лаек.

1971 елның апрелендә Мирхәйдәр Фәйзинең туганы Сәгыйть ага Фәйзуллин әдипнең шәхси архивын университет китапханәсенә тапшыра һәм хәзер ул көнчыгыш кулъязмалары секторында аерым фонд булып саклана. Кульязмалар арасында М.Фәйзинең көндәлек дәфтәрләре турындагы васыяте дә бар: *«Мин кайда гына үлеп, бу дәфтәрләр бәйләме кемнәрнең генә кулына төшсә дә, һичбер таралмастан, агам Мортаза Фәйзуллин яки агам Закирҗан Фәйзуллинга тапшырылсын. Бу нәрсәләр агаларым, апам, җиңгәләрем кулына барып төшсә, һичбер юлына хыянәт итми, Казанның Гыйльми үзәге белән хәбәрләшеп, шунда җибәрелергә тиеш. Барысы хәзергәчә 70 нумер, моннан соңгылары өстәлә барыр. Шулай ук башка нәрсәләр, мәсәлән, кульязмалар турысында да шул ук сүз».*

Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең баш библиографы, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре Диләрә Габделхәй кызы Абдуллина (1934-2006) М.Фәйзинең шәхси архивын җентекләп өйрәнде һәм 1988 елда тасвирламасын аерым китап итеп бастырып чыгару бәхетенә иреште.

Узган 2016 елда татар әдәбиятының классигы, драматург Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 125 ел тулу уңаеннан төрле чаралар узды. Көндәлекләрнең хәзерге көнгә кадәр басылганы, киң даирә укучыларга барып ирешкәне юк. 100 ел элек язылган бу дәфтәрләр, гарәп хәрефләре белән булганга, өйрәнүдә кайбер уңайсызлыклар да тудыра. Без әлеге кыенлыкларга карамый, кулъязманы хәзерге имляга күчереп, иң кызыклы өлешләрен сайлап кына «Безнең мирас» журналы укучыларына тәкъдим итәргә булдык. «Сезгә миннән ак теләк...» дигән исемне көндәлектәге шигъри юллардан алып, үзебез куйдык.

Шунысын да искәртү урынлы булыр: 1912 елда языла башлаган көндәлекләр, алда әйткәнебезчә, 70 дәфтәр булган. Әмма 1923, 1926 елларда М.Фәйзи бу язмаларны яңадан карап-тикшереп чыга, шулвакытта дәфтәрләрдән кайбер сүз, җөмләләрне кисеп ала, сызгалый, яңа сүзләр өстәп яза. Ә инде 14 нче һәм 35 нче дәфтәрләрне, безгә билгесез сәбәпләр аркасында, бөтенләй юк итә. Бу турыда авторның үз искәрмәсе дә бар. Көндәлекләрдә даталар 61 нче дәфтәргә хәтле иске календарь исәбе белән бара, 1924 елның 2 августыннан яңа исәпкә күчелә. Без исә, даталарны үзгәртмичә, автор ничек теркәгән – шулай бирергә булдык. Дәфтәрдә соңгы сүзләр 1927 елның 10 июнендә язылган. Шул көннән алып, М.Фәйзи көндәлеген яба, гомеренең соңгы елында булган кайбер вакыйгаларны, үзенең авыру хәлен, хискичерешләрен өзек-өзек кыска язмалар рәвешендә генә куен дәфтәренә теркәп бара.

Текстта авторның тел-стиль үзенчәлекләре тулысы белән саклана.

Рәйсә Шәрәфиева

ИЛЛЕ БЕР КӨНЛЕК СӘЯХӘТЕМ ЯХУД МАЛМЫЖ СӘФӘРЕ ХАТИРӘСЕ

1916 ел

Июль 6нда төштән соң Орскидан үз атыбыз белән чыгып киттек. Малмыжга кадәр юлдашым Сәгыйд[1] иде. Ул көн Җүнәйгә барып кунып, иртәгесен 8 ндә Габдулланы пар аты белән яллап, иртә сәгать 6 да Җүнәйдән чыгып китеп, сәгать 1 дә Арсайга килеп, Габдулла исемле бер кешегә төштек. Хәзергә поезд туктап, киләчәктә разъезд гына булачак бу авыл, биек таулары белән мәшһүр Пичмән[2] авылыннан 12 чакрым ары, шундый ук гаҗәп яратылган таулар арасында, Кораган суы буена утырган. Йитмешләп өе, бер тимер түбәле мәсҗеде бар. Күренеше шактый матур. Һәр яны агачлык. [...]

Мирхәйдәр Фәйзи. (1910)

Иртәгесен 9нда сәгать 8дә Арсайдан кузгалып киттек. Киткәндә Габдулланың бер кеше утыртканын белдек. Вә шунда бер никрут[3] иптәшем – башкорт егете белән күрештем.

Йә Ходай, ничә еллар көтеп тилмергән үз поездыбызга утырыр көнебез дә килде. Гаҗәп төсле тау араларыннан, тау читләреннән, тауны кисеп ачылган җирләрдән үтеп алга тәгәри башладык. Бу сәгатьтә мин чиксез күңеллелек вә ямьгә күмелгән бер бәхетле бәндә идем. Элек бераз Кораган буйлап барып, аннан Сакмарга килеп чыктык. Җырларыбызга, көйләребезгә, хикәяләребезгә мөнәсәбәте булган бу тарихлы җылгага килеп кавышу вә аның матур манзарасын күрү бик зур бәхет, бик зур табыш кебек тоелды. Бик мөтәэссир булдым[4]. «Сакмар» көенә:

Сакмар буйлары, һай, бигрәк һәйбәт,
Ак тирмәләр тегеп җәйләргә;
Кайдала гына барсаң дус-иш кирәк
Каршы чыгып атың бәйләргә, –

җырын көчле тойгы белән җырлап йибәрдем. Сакмар буйларында яшәп, бу моңлы көйләрне, матур җырларны җырлап киткән иҗадым күз алдыма килеп гәүдәләнделәр. Иске хәлләрне уйлап, үз-үземнән югалдым. [...]

Бик күп мөселман, рус авыллары күренеп калса да, белгән кеше булмады. Кәлтәй, Рәдүд, Каргалыларны белеп үтә алдым. Юл әүвәл

[1] Сәгыйд – Мирхәйдәр Фәйзинең хәзерге Балтач районы Шода авылында имам булган абыйсы Сәетгәрәйнең олы улы, Ишмөхәммәт хәзрәтнең оныгы.

[2] Пичмән – Письмянка (станция).

[3] Никрут – рекрут.

[4] Мөтәэссир булдым – тәэсирләндем.

бик озак тау арасыннан барып, тәдриҗи[5] сурәттә таулар икегә аерылып бүген күбәя бара. Оренбурга йитәрәк кенә әтраф таудан әрчелә. Стансаларда халык менә-менә урыннар тәмам тулды. Сигез вагон третий класс, җиде четвертый, калганнары товар: агач, комларга хаслы булып, бер паровоз алтмыш ике вагон тагып барды.

Стансаларда татар вә башкорт хатыннарының су, кымыз, төрле җиләкләр сатып торулары җанга бик ягымлы тоелды. [...] Кымызның стаканын 5 тиенгә эч, диләр. Бер башкорт хатыны карлыган кагының кадагына 1 сум сорап тора иде. Алдамыйсың икән, дип киттем. Карлыганның чашкасын 10 тиенгә саттылар. Дубновкада Сәгыйд Фәхреддинев[6] утырып, аның белән күрештек. Оренбурда өйләренә чакырды. Оренбурга шул көн кич сәгать 10нарда килеп, вокзалдан ерак түгел Мәхмүдгәрәй абзыйлар фатирына төштек. Вокзал эшләнмәгән әле. Мәхмүдгәрәй абзыйларның фатирлары мәркәздән шулкадәр ерак ки, бер тапкыр шәһәргә җәяү барып кайтсаң, ике көн хәл җыярга кирәк. Извозчиклар яман кыйбат. [...] Сәгать 6 да поездга төштек. Җиңги озата төште. Вагоннар гаять дәрәҗәдә тыгыз иде. Сәгать 7дә кузгалып киттек. [...] Самарга 13ндә иртәге 10да йитеп, шундук ике сумга извозчик яллап пароходка төштек. [...] Менә инде без Идел өстендә барабыз. Көн матур. Палубада чәйләп, кәнфитләп чәй эчтек. Су мул. Әтраф фәүкылгадә[7] матур. Каршы пароходлар килеп үтәләр. Бездән алда кузгалган берничә пароходны, бигрәк тә «Самолет»ны бик тантаналы сурәттә басып үттек. Таныштай кешеләр очрамады. Урыс кызы дип килеп тә, татар кызы булып чыккан берәү белән баштарак сизеп танышмавыма соңыннан үкендем. Җиләк-җимеш пристаньнарда гаять күп. Истифадә иттек[8]. Чия, кура җиләк, карлыган, бөрлегәннәрнең кадагы 15 тиен. Пешкән күкәй 4 тиен. Ставрополь, Сингилей, Сембер, Тәтеш шәһәрләрен үтеп, 14ндә иртә сәгать 10 да Богородскийга йиттек. [...]

Чистайга туктап үттек. Пристаньга чыгып җиргә аяк бастым. Бу мине бик мөтәэссир итте. Пароход кузгалгач, бик озак Чистайга карап бардым. Бик күп күренешләр алдыма килеп гәүдәләнде. Әтине искә алдым. Аны кызгандым. Үткән чакларын, хәзерге хәлләрен уйладым. Аның инде бу җирләрне килеп күрә алу ихтималы юклыгын уйладым. Әтинең авылы Шакмайга[9], мин басып торган җирдән 30 гына чакрым булып, керми китүем бик зур хөрмәтсезлек, ихтирамсызлык кебек тоелды.

1906 нчы ел әти белән Шакмайга барып, китәргә ат җиккәч кенә бергә зияратка барып, Әхмәтҗан бабай[10] кабере янында бик моңлап Коръән укуы, йомшак, ләкин көчле генә искән җилнең шаулап әтинең тавышын дерелдәтүе, әтинең, җылап: «Хуш, әти, мин моннан соң кабереңә бәлки килә дә алмам, соң килүемдер», – диюләре күз алдыма килеп, күземнән яшьләр чыкты. [...]

16нда кич сәгать 5тә Горкига барып йиттек. Бу суда Мамадыш шәһәрен үтеп, Малмыж икенче иде. Извозчик яллап, ике чакрымдагы Малмыжга киттек.

МАЛМЫЖ

Малмыж пристаньнан 3 чакрым чамасы эчтә, Шушма суы буенда 4-5 мең халыклы кечкенә генә бер шәһәр. Риваятьләргә күрә,

[5] Тәдриҗи – акрынлап.

[6] Сәгыйд Фәхреддинов – «Шура» журналының баш мөхәррире Ризаэддин Фәхреддиннең улы.

[7] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[8] Истифадә иттек – кулландык.

[9] Шакмай – Мирхәйдәр Фәйзинең әтисе Мостафа Чистай өязенең (хәзерге Яңа Чишмә районы) Шахмай авылында туган.

[10] Әхмәтҗан бабай – Мирхәйдәрнең бабасы Әхмәтҗан Фәйзулла улы. Шахмай авылында 1800 еллар башында ул салдырган ике катлы бина әле дә бар.

элек чирмешләрнең пайтәхете[11] булган, имеш. Күп булса, 20-30 кварталлар булып, бер частьта гына идарә кылына. Бер ирләр, бер кызлар гимназиясе, бер городской ышкул, бер аптик, бер бальнис, бер чиркәү, бер кечкенә генә бакчасы, «Жизнь мира» исемле бер кинематографы бар. Мәсҗед юк. Мөселманнардан сәүдәгәр халык кына булып, җыенысы 30-40 йорттан ары түгелдер. Земствоның мөселман кызларына махсус бер ткацкий мастерское бар. Гыймарәт[12] җәһәтеннән зуррак авылдан артыклыгы булмаса да, һәр йортта диярлек алма бакчасы вә болай бакчалар күп булганлыктан, агачларга күмелеп, күренеше бик күңелле булып тора.

Асыл максатыбыз булган Малмыжга йиттек. Җизни, әни саулар, абыстай ята иде. Бик куанды. Үзе чиктән тыш җабык вә хәлсезлеге көчле иде. Әни үзенең саулыгы канәгатьләнерлеген әйтеп куандырса да, абыстайның хәле бик кызганыч иде. Шулай да, утырып тора алуы, яхшы гына сөйләшүе беркадәр күңелне җуатты.

Өйдә эшләп йөрүчеләр, җизнигә кардәш тиешле, ткацкийны бетереп шәһадәтнамә алган вә оек машинасында да эшли белә торган Фатыйма исемле бер һөнәрле кыз белән аның апасы Камилә булып, Камилә хәзер вакытча уракка киткән иде. Фатыйманың эшләгән материалларының яхшылыгын, матурлыгын, нәфислеген күреп шаккаттым. Төрле калын вә юка нәрсәләр, одеаллар, ашъяулык, тастымал эшләгәннәр ки, шундый яхшы һөнәрнең безнең якларда таралмавына тәәссеф иттем. Әни өйне бик сагынган иде, шунлыктан кайту хакында да сөйләшеп алдык. Мин баштук Малмыжда атна-ун көннән ары тормам, дип уйлаган идем. Һәрхәлдә абыстайның хәленә каралыр инде. 16нда Сәгыйд Шодага китте. Мин гаетнең өченче көнендә ала килергә куштым. Бәйрәмне авылда итәргә теләвем зур булдыгы хәлдә, туры килмәде.

Бүген абыстайның хәле яхшырак күренде. Габделхәй[13] монда булса да, аның фатирына баруны җизнидән рөхсәт булмаганга, урамда очрашып күрештек. Бакчага кереп, аннан Габделхәйнең дименә[14] җиңелеп, яшерен генә фатирына бардык. Бу русско-татарский школа бинасы булып, Габделхәйләр күптән түгел генә булып үткән перепись[15] эшләре белән чуалалар икән. Җизнинең тыюына килгәндә, шушы ишегалдында аның дошманнарыннан берсенең торуы, вә безнең барып йөрүебез белән җизнинең ышкул белән мөнәсәбәттә булуын истидлял итеп[16], тагы фетнә чыгару ихтималыннан саклану, имеш. Ышкулада сабикъ[17] Малмыж мулласының баласы, минем күптәнге танышым учитель Камил Мансуров белән күрештем. 18ндә гает укылды. Җизнинең бер өе мәсҗед хезмәте итеп, ул да булса мулласыз. Җомгаларда күрше авыл муллалары килеп укыталар икән. Гаетне каладан 12 чакрым арыдагы Йөрек авылының бер яшь мулласы укытты. Яшьлегеннәнме, ничектер, вәгазендә күп каушау күрелде. Әллә нинди көлке мәгънәле сүзләр ычкындырып, Малмыж халкына гает буе көләргә мәүзугъ[18] әзерләп бирде.

Җизниләрдә бәйрәм ашлары да пешерелмәгәнгә, авыру ятканга, җизни дә артык тәкәллефсез[19] кеше булганга, гает күңелле булмаячагы анык иде. Һәм шулай булды да. Хатыннар килеп, чәй эчми генә китәләр иде. Ирләрдән бары өч кеше – Габделхәй, Камил, Малмыж учителе Габделбәр Кадыйровлар гына килеп, чәй эчеп чыкты-

[11] Пайтәхете – башкаласы.

[12] Гыймарәт – төзелеш, корылма.

[13] Габделхәй – атаклы Түнтәр мулласы Ишмөхәммәтнең улы Габделхәй Динмөхәммәтов. Ул Малмыжда һәм аннан ерак түгел Иске Йөрек авылында рус-татар мәктәпләрен оештыруда катнашкан шәхес.

[14] Дименә – өндәвенә.

[15] Күптән түгел генә булып үткән перепись – 1916 елда авыллардагы халыкны, малмөлкәтне исәпкә алу максатыннан оештырылган.

[16] Истидлял итеп – нәтиҗә чыгарып.

[17] Сабикъ – әүвәлге, элекке.

[18] Мәүзугъ – тема.

[19] Тәкәллефсез – гади, артыгын кыланмый торган.

лар. Алар белән мин дә чыгып, «Аеклык сыйххәте[20]» залында булачак Петроград мөселман комитеты[21] җыелышына бардык, ләкин җыелмадылар. Анда Малмыжның алдынгы яшьләреннән берсе булган бакалейный һәм фруктовый магазин тотучы Сафа Сәйфуллин белән таныштым. Аннан җыйнаулашып чыгып, элек Урбар дигән авылда мулла булып, Ишми доносы белән указы алынганга, хәзер Малмыжда сәүдә белән торган Хәбибелхак дигән кешегә барып чәй эчтек. Габделбәр Кадыйров энесе Габделәхәт белән таныштым. Аннан чыгып, Хәкимов приказчигы Зариф дигәнгә бардык. Анда Сафа Сәйфуллинның энесе Сөнгать исемле бу ел майда гына каралып калган егет белән таныштым. Моннан ун ел элек килүемдә кечкенә генә булдыгы хәлдә урысча теттереп сөйләшүе белән минем исемне китергән бу бала, хәзер инде тагы да шәбәеп, дәп-дәү егет булып та өлгергән. Бу мәҗлестә хазир[22] дә булды. Шуның белән беренче көнне озаттык. 19нда әнине Йөреккә ала килделәр. Китте. Абыстай кәефле генә торды. Төшкә кадәр ялгыз булдым. Җизни белән бакчада борчак җыйдык. Бакча зур, һәйбәт. Алма агачлары күп булдыгы хәлдә, бу ел алма уңмаган иде. Беседкага кереп байтак «Сәгадәтбану», «Җәмилә» көйләрен җырлап утырдым. Габделхәй килеп, аның белән байтак йөрдем. Сәйфуллиннарга барып байтак утырдык. Күңелле генә булды. Анда «Вакыт»та язулары күренә торган Нурулла Буртасов, Нәҗип Мәнафов, вә элегендүк белеп, күңелемнең ихтирам иттеге Хәким абзый вә башкалар белән күрештем. Аннан чыгып, Габделхәйләр фатирына бардым. Анда городской ышкулда укучы, Йөрек мулласының баласы Гафур белән таныштык. Сеңлесе гимназиядә укый икән. Аннан кайтып ятканчыга кадәрге вакыт, 20сендә төшкә кадәрге ялгызлык мине бик ялыктырды. Чәйгә йөрешләр яхшы күңелле чыгуы белән бәрабәр, күңелем каршындагы ямьнәрнең берсенә дә очрамаганга, Малмыж бәйрәме бик күңелсез уза икән, дигән уйга килдем. Вә урамдагы бер күренешнең тәэсирен, күңелемдә җыйналган моңларга болгап, тәрәзә төбендә утырдыгым хәлдә, шушы шигырьне ясап ташладым:



М.Фәйзи истәлекләреннән 5 нче дәфтәр: «Илле бер көнлек сәяхәтем...» 1916 ел

ГОРБӘТТӘ[23] БӘЙРӘМ

Әйтәләр, бәйрәм бүген, мин күрмим бәйрәм көнен.
Күңелемә кунган кара кош, күрмимен былбыл гөлен.
Шаулатып шатлык белән йөргән халык тулган урам,
Тәрәзәдән карап сөрелгән бәндәдәй мин тик торам.
Ул хатын-кыз, бар да тыз-быз; ул балалар дәрьясен
Ул егетләр, ут кебекләр селкетәләр дөньясын.
Үттеләр җырлап егетләр заулатып гармун белән,
Бер адашкан кош кебек мин утырамын тик моң белән.

[20] Сыйххәт – исәнлек, сәламәтлек.

[21] Биредә сүз 1915 елның 5 февралендә Петроградта ачылган «Яралы мөселман гаскәриләренә һәм аларның гаиләләренә ярдәм өчен «Вакытлы мөселман комитеты»ның Малмыж бүлеге» турында бара.

[22] Хазир – шунда булучы.

[23] Горбәт – мосафирлык, туганнарыннан аерылып чит җирдә булу, ялгызлык.

Мондый көндә миндә уй вә моңнан пакь идем,
Бер гариб-горбәт кошы булдым, аларга ят идем.
Эчтә утырып, тәрәзә аша тик котлыймын бәйрәм белән,
Йөрегез үзегез гөр килеп, үтсен бу бәйрәм ямь белән.
Тетрәсен бу дөнья дер-дер, уйна, гармун, җырла, җыр.
Бүз бала, бездән кала дөнья, бу чак бер юлгадыр.
Мин дә тиңдәш сезгә, тик чит, йөрегез үзегез бергәләп.
Сезгә миннән ак теләк, бу сүзләрем булсын бүләк!

Малмыж яшьләренең бәйрәм итә белмәүләренә эчем пошып йөргәндә, арт урамнардан берсендә гармун белән үтеп барган бер төркемне күрү – азрак буяу кушып булса да, бу шигырьне язуыма сәбәп булды. Бу эшне бетергәннән соң, яттым да йокладым.

Берәүнең уятуы белән сикереп торганда каршымда Сәедгәрәй абзый торадыр иде. Мине алырга килгән, озакламый әни дә Йөректән кайтты. 21ндә абыстай, минем төсем итеп тотарсың дип, бер сөлге бирде. Озакламый без Шодага киттек.

***

Бу якта җир тыгызлык сәбәпле, су буе җирләрдә авылларның арасы ике чакрым, өч чакрым, иң ерагы 4 чакрымда гына булып, шуннан да ерагы юк. Хәтта бер чакрым аралы гыналары да бар. Сырттан барганда гына арасы 4-5-6 чакрымлы авылларга очрала. 35 чакрымдагы Шодага барып йиткәнче 7 авылның эченнән үтеп, ераклыгы берәр чакрымга булу игътибары белән 5 авыл күренеп кала. Эченнән үткән авыллар: Кәллә, Үҗәл, Завод, Карымдан, Кучкен, Дорга, Кугнур. Күренеп кала: Чутай, Нөнәгәр, Күргим, Сәрдек, Ушла.

Яңгыр яву сәбәпле, Заводның Габдулла муллага кереп варенье белән чәй эчеп, бал белән май ашап чыктык.

Авыллар һәркайсы диярлек икешәр, өчәр мәсҗедле. Зур өйләре, сарай-келәтләре һәммәсе агачтан булып, һәр ишегалдында агач вә бәрәңге, кыяр бакчалары бар. Бу якта, кайда карасаң, анда агачлык һәм урман. Ишегалды вә бакчаларда гына түгел, урам буйлап агач тезелеп киткән авыллар да бар. Вятка губернасының ярты җире урманлык булганлыктан, дүрт ягыңа күз салсаң да, агачлык күрүдән котыла алмыйсың. Өйләр һәркайсы урамга өч тәрәзә каратып кара-каршы вә баераклары өй кара-каршы, кара-каршы ясап, крис[24] кебек итеп салганнар. Монда халыкның һәрберсендә үк булмаса да, азрак хәле барлары өй яннарында алма, җимеш бакчасы ясаганнар. Шунлыктан, җиләк-җимеш бик күп була. Моны баераклары бик мөкәммәл эшләп, бакчасына барып керсәң, мыжгып торган җиләклек эчендә каласың. Ул кура җиләкләре, чияләр, карлыганнар, крыжовниклар, кара җиләкләр, бар да бар. Һәр авылда мотлак бер махсус сарайда 2-3 насос, 7-8 пичкә[25] вә гайре пожар кирәкле әсбабы булып, капка баганаларына утка кем ни алып киләчәкләрне язылып куелган. Шул әсбабны карап тикшереп торыр өчен, ел саен чират белән пожарный староста сайлана икән. Волосной правлениеләрнең үзенең атлары була икән ки, авыл халкына чират белән олау йөртү[26] мәшәкате йөкләтелми.

Һәр авылда җылга булу өстенә, суны чишмәдән алалар. Чишмә

[24] Крис – крест.

[25] Пичкә – бочка.

[26] Олау йөртү – йөк йөртү.

чыкмаган бер генә авыл да юк. Ул чишмә яны кызларның, егетләрнең иң кадерле урыннары була икән. Авыл саен мотлак тегермән бар, хәтта кайсы авылда икешәр. Монда халык җирләрен өчкә бүлеп иген игә, ягъни һәр ел бер өлешенә арыш, берсенә сабан ашлыгы, берсе такыр кала. Ул такыр басуны печәннән элек сөреп, арыш урагы беткәч, август башларында яңадан сөреп арыш чәчәләр икән. Ул бу ел тишелеп чыгып, бөтен җир кувырып[27] утырганда, хәтфә кебек ямь-яшел булып тора, ди. Аннан, җир туңгачрак, өстенә мал йибәреп ашаталар икән. Бу елгы арыш урынына киләсе язны сабан ашлыгы, ягъни солы, бодай кебекләрне чәчеп, сабан ашлыгы урыны такыр басу булып кала, ди.

Авылның һәр ягында «басу капкасы» дигән капкалары бар. Шуның такыр басу ягы ачык булып, чәчелгән ягын мал чыкмасын диеп тоталар ки, һәр үтүче ачып чыгып, ябып китәргә мәҗбүр. Җир тарлыктан басулар бөтенләй авылга килеп терәлгәннәр. Һәр кеше үзенә тигән җиргә берничә таяклап бүлеп-бүлеп чәчкәнлектән, иген басулары нәкъ корама юрган шәкелен[28] алып торалар. Печән бу якта юк. Болыны бар авыллар гына чапкан булалар икән. Атларын, малларын бездәгечә кырга йибәреп йөртү мөмкин түгел. Җәен, кышын кулда гына булып, азыклары: башак, салам, ипи-фәләннәр икән. Шунлыктан, кирәгеннән артык мал асрый алмыйлар. Соңгы елларда клевер чәчеп үстерү рәваҗга[29] китеп бара икән. Бер чәчкәне 5-6 елга бара, ди. Һәр авылда умарталы кешеләр берничә. Иген урырга машиналар татар авылларына таралмаган әле, кул белән уралар. Җир өсте кызыл яулыклы абыстайлар белән тулган була. Арышны июль 15ләреннән алып ура башлыйлар. Көлтәгә бәйләп, 15 көлтәне бергә бик матур итеп өеп утыртып куялар, моны суслун[30] дип атыйлар. Шуннан кирәк кадәрен өйгә алып кайтып, чабагач[31] белән сугып алалар. Артыгын ындырга, яхуд күбесенчә кырда ук кибән ясап куялар. Җиргә дүрт таш куеп, шуңа агачлар тезәләр дә шуның өстенә көлтәнең орлыклы ягын эчкә каратып бик матурлап өяләр. Җирдән ярты аршин кадәр югары тора. Тычкан тиюдән дә яхшук имин була икән. Ашлык ташый торган арбалары бездәгечә ырыдван[32] булмый, кадимгечә ящик арбаның артына баскыч сыман бернәрсә беркетәләр дә, шул ярый. 200 көлтәне бик матур итеп төяп кайталар.

Монда халык ике эш арасында бер генә көн дә ял итә алмый. Эш эшкә ялганган да киткән. Сабан чәчү, арыш басуын сөрү, печән өсте, арыш уру, арыш басуын тагы сөреп чәчү, сабан ашлыгын уру, көлтә кертү, тирес түгү... Көн яздырмый шул тәртип белән тезелгән дә киткән. Җәй буена бер көн сабан туйлары, өч көн җыен булып, шул гына икән бөтен җәй буена ирекле көннәре. Сабан туе үзара булып, җыенның беренче шарты – чит авыллардан кунаклар чакыру икән.

Монда тиресне җиргә түгәләр, шунсыз ярамый. Ягуга, әлбәттә, агач мул бу якта. Бу тирәләрдә һичбер авыл юк ки, аның зияраты агачлык вә чите әйләндерелгән булмасын. Каберләр куе агачлык эчендә бик күңелле күренәләр. Чите бик яхшы әйләндерелгән булу өстенә, һәр кабердә тактадан ыспай гына ясалган чардуган. Мондагы зиратлар күңелгә куркынычсыз гына тоелып, үлемнең дәһшәтен яхшук киметеп торалар.

Киенү рәвеше дә бездәгенең тәмам киресе, дип әйтерлек. Ха-

[27] Кувырып – кызып, пешеп.

[28] Шәкелен – формасын.

[29] Рәваҗ – базарда сатылу.

[30] Суслун – көлтә чүмәләсе.

[31] Чабагач – кулдан ашлык сугу коралы, каеш белән беркетелгән ике таяктан тора.

[32] Ырыдван (рыдван) – гадәттә көлтә, салам, утын ташый торган арба.

тын-кызларында аякта чабата, тула оек. Күбесенең өстендә кызыл күлмәк. Башка төсләр ары-сары гына, хосусан кызларда гына очрый. Башларында шәл урынында зур француз яулык. Баш яулыгы өстеннән бөкләми генә җабынып йөриләр. Кызларның билендә матурлап бетергән алъяпкыч та була. Кыр өсте, кич кырдан кайтканда юл өсте болар белән бик җагымлы бер күренеш тәшкил итәләр. Кырдан кайтканда кызлар бик киенешеп кайталар. Чәчүргечләрендәге тезелгән тәңкәләрен шалтыр-шолтыр китереп, ялтырап торган уракларын кулларына тотып, ваграк атлап, нык басып китүләрен авылның иң матур күренешләреннән санарга ярый. Хосусан аларның чишмәгә суга килүләре бик шагыйранә.

Бу чишмәгә кызлы өйләрендән мотлак кызлар һәм яшь киленнәр киләләр икән. Кояш баеган вакытларда чишмә янында гайре мөтәнаһи[33] бер чуарлык, шул нисбәттә бер күңеллелек хасил була. Егетләр йөргән кызларын күбесенчә шушында очратып сөйләшәләр. Һәрвакыт арырак җирдә көянтә-чиләкле бер кыз белән бер егетнең сөйләшеп торганын күрергә була. Бәгъзе вакытта егетләр гармун белән дә килеп калырга да өлгерәләр, хосусан җомга көн. Чишмәгә якын гына чирәмдә егетләр җырлап, уйнап торалар. Чишмә яны кызлар белән сырыла. Сөйләшү, көлешү, мөзахләшү[34], мыскыллашу китә. Һәрбер йиткән кыз егетләр белән сөйләшүдән качмаска мәҗбүр. Бер кыз сөйләшмәсә, үзен эре тотса, суфыйланса[35], яисә бөтенләй чишмәгә төшмәсә, аңа көн юк икән. Һәр җирдә егетләрнең хурлавына дучар була икән. Өе турыннан җырлап үтүләр, чишмә янында хурлаулар, чиләгенә нәрсәләр салулар, хәтта капкасын буяуларга кадәр була, ди. Картлар, гаҗәп төсле, бу чишмә яны манзарасын күрми үтеп китә бирәләр. Андагы хәлне бик яхшы белгән ана да кызын чишмәгә төшүдән тыймый. Гадәти горефләр зөмрәсенә[36] кергән бер эш ул, кыскасы.

Ирләрнең киенүләре: аякта чабата, чалбар юк, күбесенчә күккә эре ак бизәкле ыштан, озын күлмәк, алъяпкыч, кырпусыз[37] бүректән гыйбарәт. Бу – өлкәннәрендә. Егетләре бу нәрсәләрне бик ыспай итеп кияләр үзләренчә вә көязлеккә бик әһәмият бирәләр. Аякта гомумән чабата һәм оек, чалбарсыз һич йөрмиләр. Бик бөреп теккән ап-ак киндер алъяпкычларын билләренә бөтенләй уратып бәйләп, җиңсез камзул яисә тужурка кияләр. Башларында кара такыя[38] һәм эшләпә. Мин йөргәндә көннәрнең кояшсыз булуы сәбәпледерме, һәммәсе диярлек такыядан иделәр. Итек киючеләр сирәк очрый. Ләкин шул киемнәре үзләренә бик килешә. Заманачарак итептерме инде, тужурка вә кара такыя кигәннәр. Шул чабаталары, ап-ак алъяпкычлары белән дә бик ямьле күренәләр. Хосусан алъяпкычларын мин бик яраттым. Үз киемнәрен азрак тәртипкә салып кына, үзгәртми алып килүләре миңа бик ошады.

Текстны басмага Казан федераль университетының
Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе Сирәк китаплар
һәм кульязмалар бүлеге баш библиографы
***Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.*

Дәвамы бар ■

[33] Гайре мөтәнаһи – исәпсез-хисапсыз.

[34] Мөзах – мәзәк, көлке.

[35] Суфыйлану – изге кеше булып кылану.

[36] Зөмрә – төркем.

[37] Кырпусыз – кырыена мех тегелмәгән, мех тотылмаган.

[38] Такыя – чәчләрне яшерү өчен кия торган баш киеме.

Истәлекләр

Бари Галиев

Кадерле редакция!

Сезнең һәм укучыларның игътибарына әтиебез (ирем Галибнең әтисе) язып калдырган истәлекләрне җибәрәм. Бари Гали улы Галиев (1901-1979) Башкортстанның хәзерге Учалы районындагы Юлдаш (элек Аккуҗа) авылында туган. Дәү әнисе Фәхерниса Низаметдин кызы (185?-1932) Малмыж өязенең (хәзер Кукмара районы) Мәмәшир авылыннан. Дәү әтисе Шәфик Сабит улы Сабитов (1849-1908) Алабуга өязеннән (авылы билгесез). 1870 еллар тирәсендә дәү әтиемнең гаиләсе Казан якларыннан китеп, Учалы районына барып урнашкан (элек Оренбург губернасы). Анда улы Гали (1873-1946), ә 1901 елда оныклары Бари туган.

Бари Галиев 1914-1916 елларда Казанда «Мөхәммәдия», 1916-1918 елларда Троицкида «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыган. Күп еллар буе Учалы районының Ахун авылында башлангыч класслар укытучысы булып эшли, аннан 5-7 классларда математика, география укыта, уку-укыту бүлеге мөдире вазифасын башкара. 2001 елда Ахун авылында әтиебезнең тууына 100 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе үтте, авылның бер урамына аның исеме бирелде.

Менә аның хатирәләреннән кайбер өзекләр. Текстта авторның тел-стиль үзенчәлекләре тулысы белән саклана.

Хөрмәт белән,

Фәридә Җәүдәт кызы Галиева (чыгышым Әгерҗе районының Иж-Бубый авылыннан).

Зеленоград – Мәскәү шәһәре

КУКМАРА РАЙОНЫНЫҢ МӘМӘШИР АВЫЛЫ ТУРЫНДА

<...> Минем әтинең әтисе Шәфик, әнисе Фәхерниса Казан губернасы Мамадыш өязеннән килгән кешеләр (минем дәү әни 1932 ел вафат булды). Шушы дәү әни 1911 яки 1912 елны үзенең иленә кайтып килергә булган.

Дәү әнинең энеләре Зыятдин, Сабир, Гыйлаҗ, тагын бер сеңлесе Мамадыш өязе Мәмәшир авылында[1] яшиләр икән. Дәү әни шунда барды. Иптәшкә дипме, нәрсәгәдер инде, дәү әни мине үзе белән алып барды. Без ул якка баручы бер Казан ягыннан килеп, Калкан* авылында яшәүче Зиннәт дигән кешеләр белән бардык. Уфага кадәр поездда, аннан пароход белән «Елабуга» дигән җиргә барып, анда безне ат белән алып киттеләр. Ул чак, дәү әнинең энеләрен күрмәгәнгә 25 ел булган икән. Без анда 1,5 яки 2 ай булдык. Анда Сабантуй, җыен дигән нәрсәләрен төрле авылга йөретеп күрсәттеләр. Ул якта яшәүче татарлар тормышы безнең якка караганда бик башка, бик кысынкылыкта яшиләр иде. Мин аны шуннан бик истә калдырганмын. Безнең якта алпавыт-помещиклар булмагач, җир бик иркен, мал да күбрәк асрала иде. Ә без барган Мәмәшир авылы зур авыл (3 мәчетле иде), бер генә кешедә ике ат, калганнарында берәр генә ат асрыйлар иде. Бу ике ат тоткан кеше бай, сәүдә итә, аннан ат көче белән тегермән әйләндерә. Аннан тыш, ул якта, Кукмарада зур гына пуйма[2] басу фабрикасы бар икән. Монда әлеге бай кеше йон тетү машинасын эшләтә иде. Ул авылның кызлары пуйма чыбарлау эше белән шөгыльләнәләр иде. Боларны мин бигрәк нык хәтерлим. Чөнки мин 1914-1916 елларда, Казанда укыганда, шул авылга каникулга барып йөрдем. Шул авылга якын гына бер авылдан минем белән бер класста укучы бар иде (исеме Габдрахман), мин шуның белән барып йөрдем. Каникул вакытында авылга

Бари Галиев – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте

кайтмадым. Минем дәү әни аннан 25 ел элек, дәү әти белән ат белән барганын сөйли иде. Ат белән бер ай буена бардык, дигән иде. <...>

«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ТУРЫНДА. 1914-1916 ЕЛЛАР. КАЗАНДА УКУ ЕЛЛАРЫ

Шушы елларда Өрген мәктәбендә укучы берничә бала төрле яшьтә, төрле класста укучылар, әтиләр киңәше белән, Казанга укырга җыелдык. Болар түбәндәгеләр:

1) Халиков Гобәй Ахун улы (Өрген авылы);

2) Мөхәммәтов Мәүлет Шаһивәли улы (Илтабан авылы);

3) Мәүлет Галимулла улы;

4) Идрисов Шаһый Җиһан Әхмәтшарад улы (Ураз авылы);

5) Сираҗетдинов Төхфәт Фәткулла улы;

6) Гыйлман... (Кунакбай авылы);

7) Имангол авылыннан Шаһиев Әхмәт Әхмәтгәрәй улы (ул 1913 елны ук Казанда укыган);

8) Солтанов Гали (Имангул авылы) – болар бар да рөшдинең[3] 4 классын беткән;

9) Мин – Барый Галиев, иң кечкенәләре, 13 яшьтә.

Рөшдинең 2 нче классын гына беткән идем, югарыда әйткән укучылар белән бергә 1914 елның август азагында, бергә җыйналып, Казанга укырга киттек. Ул чакта, поездга Миасстан утыра торган булгач, барыбыз да, юл уңае, безнең авылга (Башкортстанның Учалы районындагы Юлдаш – элек Аккуҗа авылы. Анда мулла булып Зәйнулла ишан Рәсүлев эшләгән – иск.) җыелып, 2-3 ир кеше, бер атка утырып, чемодан урынына кечкенә сандыкларга әйберләр тутырып, юлга чыктык.

Уфагача поезд, аннан, поездтан төшеп, пароход белән Казанга барыла. Мин кечкенә булсам да, поезд, пароходта беренче утыру түгел, икенче тапкыр иде. Мин 9-10 яшьләрдә дәү әнием белән алар туган як Казан тирәсе Мамадыш районына кунакка барган чакта, поездларга утырганым бар иде. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, адрес буенча, «Казан, Тихвинская улица, Галиевское училище» дип йөртелә. Көз укуга баручылар башта туры мәктәпкә бармый, ә мәктәпкә якын «Амур» яки «Сарай» дигән номерга төшәләр икән (Ул хәзерге гостиница була). Боларның «Амур» дигәне яхшырак, мәктәпкә якын. Шунда бер бүлмә алып, 3-4 кешелек, мәктәпкә кергәнче яшисең. Әгәр икенче-өченче елларга барсаң, аннан алда килгән укучылар, номерга килеп,

Галимҗан Баруди

алар үзләренең, син үзеңнең җәй үткәрү, мәктәптәге үзгәрешләр турында сагынышып сөйләшәсең. Бу хәл бик күңелле, истә калырлык хәл булып, классташлар арасында дуслыкны ныгыта.

МӘКТӘПНЕҢ ЭЧКЕ ТӘРТИБЕ

Мәктәпкә беренче тапкыр баручылар, тиешле документларын мәктәп идарәсенә тапшырып, алыну турындагы хәлне 2-3 көн көтәләр. Электән укучылар булса да, мәктәп йортына кереп китәргә бик ашыкмый, көз көне, акча да мулрак булганда, шәһәрдә иркен рәвештә теләгән кино, театрларга һәм башка яңалыкларны карап көн үткәрәләр. Беренче баручы авыл балаларына карау, йөрү өчен, билгеле инде, бик күп нәрсәләр бар. Ул чакта бит авылда без кино дигән нәрсәне күрү түгел, ишеткән дә юк бит. Болай сынауны биреп тормадык, документларга, шәһадәтнамәләргә карап (уку турындагы танытма яки аттестат) мәктәпкә алдылар. Билгеле, ул чактагы авыл мәктәпләре бик чуар, бердәм программа белән укымый, кай җирдә кем ничек тели, нәрсә укытырга теләгән, ниндирәк укытучы укыта, шуңа карап укучыларның да белеме дә бик төрле. Безне дә, кайберебезне икенче класска, кайберебезне беренче класска, кайберебезне, яхшы дигәннәрен, үзе үткән ел укыган классына алдылар. Ул да шартлы рәвештә. Әгәр өлгерә алмаса, кире түбәнгә төшерә.

Мәктәпкә алынганда идарә укучылардан 13 сум акча ала. Аңлатуларынча, 10 сумы – ятак өчен, 3 сумы – аванс тәртибендә. Әгәр кыш буе мәктәпнең бер әйберенә дә зарар итмәсәң, яз көне, уку беткәч, 3 сумны кире үзеңә бирәләр. Әгәр берәр нәрсәне ватсаң, бозсаң, ул әйбернең тиешле хакын шушы 3 сумнан тотып, калганын бирәләр икән.

Бездәге 4 класс рөшди урынына, бу мәктәптә 4 класс – игъдади[4] яки сәнәви[5] дип йөртеләләр иде. Мин шуның икенче классына алындым, Өргендә дә икенче классны укыган идем.

Билгеле, шәһәр мәктәбе татарларның иң зур мәктәбе булгач, безнең мәктәпкә караганда уку, тәртип ягыннан да күп башкалыклар булды.

Бу мәктәп – Казан байлары Галимҗан Баруди дигән зур дин башлыгы карамагында оештырылган мәктәп. Анда 4 класс игъдади, 3 класс гали[6] дип йөртелә. Башлангыч класслар бөтенләй юк.

Барлыгы 5-6 йөз укучы була иде. Укучылар күбесе диярлек читтән, төрле яктан һәм 5-6 кеше Төркиядән укырга килгәннәр. Укытучыларның күбесе Төркиядә, Истамбулда, Бәйрут мәктәбендә укыган кешеләр иде.

Мәктәп бинасы зур бер ихата белән уратып алынган, урам якка чыгарга зур тимер капка булып, җәяүлеләргә кечкенә капкасы бар. Ул капкада һәрвакыт өзлексез каравыл. Көндез кечкенә капка иртәнге сигездән кичке бишкәчә эчтән чыгарга, ә тыштан керү өчен кичке җидегәчә ачык була.

Шуннан башка вакытта чыгармый да, пропускың булмаса, кертми дә. Атнага бер – кечеатна көн чыгу җидегә, чыгып калган булсаң, тугыз сәгатькәчә тыштан кертелә. Капкада төрле хәнҗәр

куеп тегелгән Кавказ формасы кигән, яхшылап татарча да сөйләшә белмәгән бер черкәс кешесе иде. Бу кеше бик строгий кеше булып, күргәзелгән вакыттан башка вакытта һич чыгармый да, кертми дә иде.

Йортның үзендә кечкенә кибет, ашамлык һәм укучыга көндәлек кирәк әйбер бар. Шул ук йортта кышкысын катук (каток, шугалык – иск.), вакытлыча гына булган авыруларга аерым ике бүлмәле бер йорт, мәктәпнең үзендә фельдшер да бар иде.

Кыскача, болар бар да укучылар чыгып йөрмәсен өчен эшләнгәннәр. Столовой да шушы йортта булып, көненә бер мәртәбә шушы зданиеләрнең подвалына корылган столовойда аена 3 сумга ашаталар.

Иртән, кич үз ятагында чәй була. Ятакта бөтен бер класс – 40 бала. Бер бүлмәдә аерым куйка, ике укучыга бер тумбочка, аяк-өст киемнәре өчен гомум шкаф була торган иде.

Дәрес әзерләү класста билгеле сәгатьтә, яту, тору звонок буенча.

Мәктәп бинасына һичбер төрле музыка коралы кертергә рөхсәт ителми. Капкадан чыгару бик иртә ябылгач, бик иртә була торган кинолардан башка, һичбер күңел ача торган җиргә барырга мөмкинлек куелмаган.

Ике ел уку вакытында бер мәртәбә 10-15 укучы класс җитәкчесе аша гариза биреп, Яңа елга каратадыр инде, ниндидер бер балалар кичәсенә бардык. Анда безгә яхшы, матурлап эшләгән, ефәк кап белән, бәйрәмне котлап язылган күчтәнәч бирделәр.

ИКЕНЧЕ ЭШ

Кечкенәрәк булган безнең класс укучылары, безнең белән бер класста укучы зуррак укучылар, бигрәк тә Нәкый Исәнбәт, Вафа Бурнашлар җитәкчелегендә (Фәтхи Бурнашның энесе) ул чакта (Фәтхи Бурнаш та шул мәдрәсәнең югары классында укый иде) бик нык сорау белән бер концерт куярга рөхсәт ала алдылар.

Ул концертны кую өчен тик әлеге подвалда булган столовой бүлмәсен рөхсәт иттеләр. Анда да бертөрле дә музыка кертергә рөхсәт итмәделәр. Хор, декламация, шигырь уку, җырлаулар булды. Мин үзем дә, хордан башка, салкын чишмә көенә бер җыр җырладым.

ИСТӘ КАЛГАН ӨЧЕНЧЕ ХӘЛ

Габдулла Тукайның туган көнен искә алып бер кичә үткәрергә укучылар рөхсәт сорадылар. (Бу вакытта Тукай үлгән иде инде.) Шуны үткәрергә рөхсәт итмәделәр. Мәктәп рөхсәт итмәсә дә, аларның рөхсәтеннән башка үткәрергә булдылар.

Зур класслар җитәкчелегендә Фәтхи Бурнаш, тагын кемнәрдер, түбәнрәк классларны да яшерен рәвештә әзерләп, 13 апрель көнне, дәрескә 10 минут калгач, һәрбер укучы, үзенең Коръәнен алып, һичбер нәрсәгә карамый, мәктәпнең «дәресханә» дигән бер бүлмәсенә җыелырга өйрәттеләр. Бу бүлмә зур бүлмә. Мәктәпнең иң зур хуҗа укытучысы Галимҗан Баруди дигән Мулла (Мулла сүзе зур хәреф белән язылган – иск.) дәресне шунда бирә. Күргәзелгән вакыт җитүгә, барлык укучы да шул бүлмәгә йөгерде. Укытучылар никадәр каршы төшсәләр дә, аларны тыңламый, шул күргәзелгән урынга җыелдык. Укытучылар никадәр, чыгыгыз, һәркем үз классына керсен, дәрес укырга кирәк, дисәләр дә яки бу хәлне хөкүмәт белсә, мәктәпне ябулары мөмкин, дип куркытсалар да, бер укучы да чыкмады. Тукай хакында сөйләү, аны искә алу, шигырьләрен укып, ул эшләрне каплар өчен, Коръән дә укып таралыштык. Ул көнне уку булмады. Шуның шаукымы булса кирәк, ул вакытта бер укучыны да җавапка тарттырмасалар да, 1915 ел көзенә зур класста укучылардан 2-3 кеше укуга алынмады. Шушы алынмаучылар арасында Фәтхи Бурнаш та бар иде.

<...> Кайтып йөрү бик ерак булгач,

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре. Алгы рәттә, сулдан беренче (ак күлмәктән) – Нәкый Исәнбәт, икенче (утырган) – Бари Галиев

бер каникулны Мәмәшир авылында кунак малай булып үткәрдем.

<...> Минем белән бер класста укучы Габдрахман дигән иптәшкә ияреп, Казаннан 130-150 чакрым җиргә ат белән бардык. <...>

Башка каникул һәм ял көннәрен, мәктәпнең үзенең бакчасында кечкенә булса да катук бар, шунда конькида йөреп үткәрелә иде. Мәктәп үзе конькилар алып куйган да, көненә 2 тиенгә бирәләр иде (2-3 сәгатькә). Кайбер укучыларның үз конькилары бар иде.

Югарыда әйтелгән Фәтхи Бурнаш безнең мәктәптә укымый, үзе хак түләп, русча укый. «Кабан күле» аръягында кечкенә бер бүлмәдә яшәде. Аның энесе Вафа Бурнашев минем белән бер класста укыгач, без анда бергәләп йөрдек. Шул вакытта Фәтхи Бурнашев мандолинасын сатарга булды.

Минем мандолина уйнарга теләк булып китте дә, мин шушы мандолинаны сатып алырга булдым. Тик шундый шартта: бу мандолина аның үзендә, яз – без кайтканча тора, һәм ул миңа 2-3 көй өйрәтергә тиеш. Мин ял яки башка көнне төштән соң аңа килеп өйрәнергә тиешмен. Шулай эшләдек тә. Тик мин күп килеп йөри алмадым. Көн кыска, соң калгач, ерак кына булганга, кайтып йөрергә кыен. Озак булсаң, соңга калудан куркасың, чөнки капкадан кертмиләр. Шул сәбәпле, күп йөреп булмады. Мәктәпкә китерергә кушмыйлар. Шулай итеп, мин аны 1916 елны өйгә алып кайттым.

Мәктәп идарәсе укучыларны никадәр кысып тотса да, укучылар, бигрәк тә зуррак укучылар, бакча аркылы, койма аша чыгып, театрга йөргәлиләр. Кечкенә укучылар да бик сирәкләп кенә баргалыйлар иде.

Минем белән бергә, бер үк класста укучылардан, соңгы вакытта матбугат аша Нәкый Исәнбәтнең укытучы булып эшләвен, аннан язучы булып, соңыннан Галим (Галим сүзе зур хәреф белән язылган – иск.) булып калуын, әле дә (1974 елларда) исән булып, Казанда яшәвен белеп яшәдем.

Мәкәрим Мәһәдиев Башкортстанда,

сәнгать, дөресе, театрда эшләвен, тик бик иртә вафат булуын белдем.

Фәтхи Бурнашның язучы һәм иртә вафат булуы беленде.

Үзебезнең районнан (Башкортстанның Учалы районы) Казанда укучылардан барысы да укытучы булып эшләделәр.

Шулардан: Шаһиев Әхмәт – 1924-1926 елларда, Казанда, больницада вафат (Имангол авылы); Халиков Гобәй – 1930-1932 елларда Сарманда вафат (Өрген авылы); Солтанов Гали – 1955 елда Учалыда вафат булды (Имангул авылы); Гыйлман – беренче империалистик сугышта вафат булды (Кунакбай авылы); Мөхәммәтов Мәүлет (Илтабан авылы), Сираҗетдинов Төхрәт Фәткулла улы (Кунакбай авылы) һәм мин, барлык гомерне укытучы булып эшләп, әле дә (1977 елда) исән-сау, пенсионер булып яшибез. <...>

***

Билгеле, монда, Казанда укыган чактагы истәлекләр, төрле булган вакыйгаларны күп итеп язарга булыр иде, тик шунда бетереп, мәктәптән тыш бер истәге хәлне генә языйм әле.

Сугыш еллары булганга, солдатка алынучылардан безнең яклар, хәтта авылдашлар да килеп очрыйлар иде. Шуларны мәктәпкә кертеп яки столовойга алып барып, кунак итәм, дисәң, мәктәпкә дә, столовойга да солдат киеме белән кертмиләр иде. Шуның өчен, без бер тапкыр бер укучының пальтосын, бүреген алып барып кидереп, минем бер авылдан Фәткуллин Лотфулла дигәнне кунак иткән булып, авыл хәлләрен сорашып, сөйләшеп, озаткан истә калган.

1914-1916 елларда укыганнан соң, 1916-1917 елларда Казанга безнең яктан берәү дә бара алмады, тик Верхнеуральскидан берәү – Мәҗитов дигән генә барды. Мин, Солтанов Гали, тагын 2-3 кеше 1916 ел көзенә Троицкидагы «Рәсүлия» мәктәбенә укырга кердек.

<...>

Без укыган мәктәп үзәктән читтә, «Амур» дигән якта иде. <...>

Бу мәктәпнең төп хуҗасы Зәйнулла Рәсүлев. <...>

Язылды: 1961-1974 еллар

РӘСҮЛИЯ МӘДРӘСӘСЕ ҺӘМ ЗӘЙНУЛЛА РӘСҮЛЕВ ТУРЫНДА

1916-1918 ЕЛЛАР. ТРОИЦКИДА УКУ

Безнең яктан Казанга барып укырга теләүчеләр берәү дә булмагач, аннан элек минем белән Казанда укучы Солтанов Гали (Имангол авылы) Троицкида бер ел укыган икән, аннан тагы 2-3 кеше 1916 ел көзенә Троицкидагы «Рәсүлия» мәктәбенә укырга кердек.

Мин бу мәктәпнең игъдади дигән 3 нче классына укырга алындым, бу инде 8 еллыкны беткәч укыла торган 4 класснең өченчесе.

Монда миңа уку җиңел тоела иде. Сугыш еллары булгангамы, укучылар артык күп түгел, тик бик олылар булды. Кайбер укучылар, бигрәк тә казакълардан, аерым класста укымый, үзләре теләгән дәресләргә, бигрәк тә дин дәресен тыңлау өчен, төрле класска кереп йөриләр. Шул дәресне генә тыңлыйлар.

Бу мәктәптә тәртип Казандагы кебек түгел, укучылар үзләрен бик иркен тоталар. Дәрестән соң укучылар теләгән кадәр шәһәрдә йөри, китапханәләргә, клубка, киноларга, театрларга йөриләр. Мәктәпкә музыка (гармуннан башкасын) кертеп була. Читтән килгән укучылар мәктәп ятагында ятып, ашарга үзләре әзерлиләр. Аерым столовой юк.

Мәктәпнең зур гына бер бинасын алып, аны солдатларга, казачыйларга казарма иттеләр. Шуның өчен зуррак класс укучыларын квартирага чыгардылар.

Без, 6-7 укучы мәктәпкә бик якын Шәфиков дигән бер кешенең зур гына бер бүлмәсенә квартирага чыктык. Анда

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Зәйнулла Рәсүлев

яшәве бик уңайлы, ашау-эчү, дәрес әзерләүгә дә бик җайлы иде. Без төрле класстан булып, минем белән укыган бер классташ Гали Мурзакаев (Мәхмүт авылы) булды, Ахуннан — Бакиев Мөхибулла, Ваһапов Солтанхәмид, Казанколдан Юлдыбаев дигәннәр укыдылар.

Укучыларга иркенрәк булгач, клубка, төрле түгәрәкләргә йөрдек.

Мин, Мурзакаев Гали – мандолина өйрәнү түгәрәгенә, Солтанов Гали скрипкага өйрәнергә йөрдек.

Без укыган мәктәп үзәктән читтә, «Амур» дигән якта иде.

Шәһәрдән мәктәпкә кайтканда, зур күпер аша чыкканда, һәрвакыт диярлек әллә нинди малайлар безне камап, акча сорап, кайчакта сугыш башлыйлар иде.

Укучылар шәһәр яктагы клубларга, түгәрәкләргә йөри торгач, зур гына итеп бер постановка куйдылар. Китапның исеме «Ахрызаман» дигән. Бу театрда халык шулкадәр күп булды, клубка сыймадылар. Җыелган акча сугышта ранен булган, госпитальдә ятучыларга ярдәмгә бирергә билгеләнгән иде.

Бу мәктәпнең төп хуҗасы – шул тирәнең, дөресрәге хәзерге Учалы районы (Башкортстан) Куңай авылында үсеп, башта Аккуҗа (хәзер Юлдаш) авылында мулла булып торган Зәйнулла Рәсүлев.

Ул бик ныклап ислам динен ныгыту

Троицк.
«Рәсүлия» мәдрәсәсе.
XX гасыр башы

өстендә эшләп, үз тирәсендә күп кенә дин әһелләре әзерли башлагач, аның өстеннән донос булып, патша Россиясе аны Костромага сөргенгә җибәрә. Аннан кайткач, бу авылда яшәми, Троицкига күчеп бара, анда ишанлык итә. Үз исеменә мәктәп ача, үзенең бер улын – Габдрахман Рәсүлевне мөдир итеп билгели. Бу – 1850-1870 еллар тирәсе.

Без укыган чакта һәр көн шул ишанга бер-ике йөз кеше килеп тора. Хәергә сарык, куй, сыер малы, кайчак сирәкләп дөя дә хәер итәләр. Килгән кешеләр икенчеләрдән җыеп акча китереп бирәләр иде. Аның өендә һәр көн иртән сәгать 9дан сәгать 2-3кә кадәр кеше була. Чәй кайнаудан өзелми. Һәрбер килгән кеше шунда чәй эчеп, хәер биреп, ишаннан дога алып, кайберләре дәрес алып кайталар да 5-6 айдан яңадан киләләр.

Габдрахманның Рәүф дигән минем белән тиңдәш улы бар иде. Ул гимназиядә укый. Без ике-өч укучы аларга барып уйный торган идек.

Шулчакта 2-3 көнгә бер җыелган 20-30 куйны шәһәр читендә булган дачаларына озаталар. Ул тирәдә мал йөртү өчен әзрәк урын бар, анда аларны сатып торалар иде. Кайчакта Рәүф белән аларның атында, ял көннәре сирәкләп, дачага баргалый идек. Рәүфне укырга да ат белән генә гимназиягә алып барып куялар, барып алалар иде.

Яз була башласа, Алтай, Тургай якларыннан казакълар килеп, шушы мәктәптә укучы олы укучыларны, җәй көне казакъ балаларын укыту өчен, укытучы итеп алып китәләр. Алар җәй көне укытып, бераз акча эшләп, кыш тагын үзләре укыйлар иде.

Мәктәп шул укытучыларны яки муллалар әзерли торган иде.

1917-1918 елларда, бигрәк тә февраль көннәреннән соң, шәһәрдә төрле яшьләр түгәрәкләре күбәеп китте. Ул арада, нindидер сайлауга өндәп, төрле листовкалар, афишалар урамнарда күренә башлады. № 5, 3, 8гә тавыш бирегез һ.б. һ.б. Билгеле, без әле ул турыда бернәрсә дә аңламый идек. Азак кына,

Бари Галиев – «Рәсүлия» мәдрәсәсе шәкерте. Троицк, 1917 ел

үсә төшкәч, учредительное собраниегә сайлау булгандыр, дип белдек. Төрле яктан агитаторлар да килеп, клубларда төрле докладлар, речьләр сөйләгәннәре искә төшә.

1917-1918 уку елына безнең мәктәпкә яңа бер укытучы килгән иде. Яшь түгел, 40-50 яшьләрдәдер, теле дә саф татар теле түгел, какса, ябык кына. Үзе тарих дәресе, аннан гәрәп теле дәресләре алып барды. 1918 нче елның язында, уку бетмәстән алда, шәһәрдә әзрәк атышлар булды. Бер яктан атлы казачыйлар булганын белсәк тә, икенче яктан нинди гаскәр икәнен белмәдек. Бу шау-шу тиз басылды.

Шулчакларда әлеге яңа килгән укытучы, берничә зуррак егет булган укучылар белән, мәктәптән качып, Чиләбе ягына, «Кызыл гвардиягә» киткәннәр, дип сөйләделәр. Шунда безгә таныш булган Ваһапов Солтанхәмид дигән укучы китте.

1917 елның февраль-март айларында шушы мәктәпнең төп хуҗасы, башлыгы булган Рәсүлев Зәйнулла ишан вафат булды.

Ул үзенең мәктәбен һәрвакыт яшәтү максаты белән, аны экономик яктан тәэмин итү максатында, нинди акча беләндер, бик ачык белмим (үз акчасымы, әллә мәктәпнең берәр фонды булганмы?), шул Троицки шәһәреннән, ике йорт сатып алып, мәктәп файдасына биргәнен укучыларга белдерделәр. Берсе – шәһәрдәге бер зур аптека йорты. Асты – магазин, өсте аптека иде. Икенчесе типография йорты иде. Ул йортлар арендага бирелеп, шулардан килгән акча мәктәпкә булырга тиеш, диделәр.

1917 елның язында Зәйнулла ишан үлгәч, ул мәктәптә аның якыннары да укый иде. Шул укучыларга, алар 5-6 иде булса кирәк, 5әр сум алтын акча бирделәр. Мәктәптәге барлык укучыларга да берәр сум алтын акчадан бирергә кушылганмы, но алтынның берәр сумлыгы юк, аны саттык, дип, безгә бер сум 20 тиен акча бирделәр. Күрәсең, ул чакта алтын акча күтәрелә төшкән.

Зәйнулла ишан үзе сау чакта һәр җомга, көн саен аңа барган кешеләргә, шул исәптән укучылар барса аларга да, берәр чынаяк чәй эчереп, 20 тиен акча бирә иде. 20 тиен булса да, акча алу өчен, күп укучылар җомга көн шунда баралар иде.

Ул үлгәч, ишанлык, шул мәчеткә мулла булып та, мәктәпнең төп хуҗасы булып та аның улы Габдрахман Рәсүлев калды.

1917 елның көзе, 1918 еллар революция булып киткәч, андый хосусый мәктәпләр бетте. Без анда укырга барып йөрмәдек.

Соңыннан, ничәнче еллардадыр, Троицкида татар педагогия техникумы оештырылды. Ул да гимназия бинасында булса кирәк. Тик шунысы: анда элек безне укыткан Атмабаев Рәхимян, Юсупов һ.б.ларның шул мәктәптә укытуларын ишетә идек. <...>

Шулчакларда кайбер авылларда кызлар өчен дә аерым мәктәпләр ачылды.

Аккуҗадагы кызлар мәктәбендә бер ел минем сеңлем – Җиһан Гали кызы Галиева, үзе авыл мәктәбендә 3-4 классны гына беткән булса да, укытучы булып эшләде. Миңа шулчакта аңа ярдәм итәргә куштылар.

Кызлар мәктәбе безнең өйдә булды. <...>

1961-1974/1975 еллар

УКЫТУЧЫ БУЛУЫМ.
1919-1921 ЕЛЛАР

<...> Менә шушы чакларда мине Белорецкига чакырдылар. Белорецкида безнең кантон үзәге инде. Мине «КОНО»га чакырганнар (кантонный отдел народного образования).

Аның мөдире безнең белән бервакытта Казанда укыган Мәҗит Максудов дигән егет икән. Ул миңа: «Син кайда? Ни эш бетереп йөрисең? Башка безнең белән укыганнар бар да хәзер укытучы булып беттеләр, әйдә, син дә укытучы бул!» – дип киңәш бирде. Мин шул көннән Мансур авылына икенче укытучы булып билгеләндем.

Чыннан да, минем белән бергә укыганнардан — Халиков Гобәй, Мөхәммәтов Мәүлет, Сиражетдинов Төхфәт, Шариев Әхмәт, Солтанов Гали – бар да укытучылар иде <...>.

1961-1975 еллар

---

*Калкан, Өрген, Кунакбай, Имангол, Юлдаш (Аккуҗа), Ураз Мәхмүт, Ахун, Казаккол, Мансур – Башкортстанның Учалы районы авыллары.

[1] Мәмәшир авылы Вятка губернасы Малмыж өязенә кергән – ред.
[2] Пуйма – Башкортстанда киез итекне пуйма яки пима дип йөртәләр.
[3] Рөшди – урта класслар.
[4] Игъдади – өлкән сыйныфлар.
[5] Сәнәви – еллык.
[6] Гали – югары.

P.S. Бари Гали улы Галиев хатыны Нaҗия Әхмәтвәли кызы белән матур тормыш кичереп, сигез бала үстерә. Балаларына яхшы тәрбия биреп, үзләре дә кадер-хөрмәт күреп, вафат булдылар. Урыннары җәннәттә булсын! ■

«ҮЗСҮЗЛЕ ПРОФЕССОР» САДРИ МАКСУДИ

Әлфинә Сибгатуллина

Төркия Җөмһүриятенең яңа гына төзелгән һәм ныгый барган чорында Йосыф Акчура, Садри Максуди (Арсал), Әхмәт Зәки Вәлиди (Туган), Габделкадыйр Инан, Закир Кадыйри (Уган) кебек Идел-Урал буйларыннан килгән татар һәм башкорт галимнәренең Мостафа Кәмал Ататөреккә үз акыл-фикер көче һәм белеме белән ярдәм итүе күпләргә мәгълүм.

Большевиклар инкыйлабын кабул итмичә, Рәсәйдән чит илгә китәргә мәҗбүр булган бу олуг затларның кайберләрен хәтта Ататөрек шәхсән үзе Төркиягә чакыртып ала. Ләкин аларга монда да идеологик яктан «утырып бетмәгән» болгавыр чорда катлаулы шартларда яшәргә, авырлыклар белән урнашып килә торган җөмһүрият системасындагы юлбашчы культын, диктатура таләпләрен үз җилкәләрендә тоярга туры килә. Аларның кайберләре «өстән төшерелгән» идеологияне, фәннилектән

Cumhuriyet

Deniz Bank türkçedir

Dün Mecliste bir meb'usun iddiası tenkid edildi

İsmail Müştakla arkadaşlarının tez ve mütalealari

Türk deniz ticareti için hayırlı bir hamle

«Deniz Bank» terkibi izafilerin üçüncü nev'ine girer ve Türk gramerine yüzde yüz uygundur»

Japon işgalindeki arazide kapitülâsyonlar kalktı

Ankarada Atatürk günü

Elcezire Valisi

Tevfik Şamiye, acaba nereye kaçırıldı?

Büyük Şefin Ankaraya vardığı günün 18 inci yılı tezahüratla kutlulandı

Dünyanın harb

«Җөмһүрият» газетасында «Deniz Bank» һәм Садри Максуди турында мәкалә. 1931 ел

ерак булган уйдырма теорияләрне кабул итә алмый һәм шуның аркасында яңадан горбәткә, Төркиядән читкә китәргә мәҗбүр була.

Эш шунда ки, Ататөрек «өммәттән – милләткә», диндарлыктан – дөньявилыкка лозунглары астында оештырган, үз заманы өчен алдынгы саналган күп кенә реформалар белән беррәттән, Көнбатыш дәүләтләре каршында Төркиянең һәм төрек милләтенең дәрәҗәсен югары күтәрү максатын да куя. Ул халыкның үз-үзенә ышанычын арттыру буенча актив эш алып бара һәм бу юнәлештә бер-берсенә бәйле булган төрки тел һәм тарих буенча үз концепцияләрен тормышка ашырырга омтыла. Евроцентризм идеологиясенә каршы рәвештә, Мостафа Кемал паша төркиләрнең асыл кавем, аксөяк раса, башка кавем-кабиләләрдән күпкә өстен булуы турындагы фикерләргә басым ясый башлый һәм Анадолуны «төркиләрнең җиде меңьеллык бишеге» дип игълан итә. Ул яклаган «кояш тел теориясе»нең* нигезендә төрки телнең таш гасырдан ук зур мәдәният теле булуы һәм җир йөзендәге башка телләрнең шул телдән килеп чыгуы идеясе ята. Борынгы халыклар шумер, хетт, этрусклар, хәтта ирландиялеләр, баскылар да төрки халыклардан үсеп чыккан дип карала. Бу теориягә нигезләнеп, төркиләрнең тарихы да өр-яңадан күздән кичерелә: аларның борынгы бабалары башта Үзәк Азиядә яшәгән, анда, янәсе, кайчандыр диңгез булган, ул кипкәч, аның буенда яшәгән халыклар күчеп китәргә мәҗбүр булганнар, шуның нәтиҗәсендә, төркиләрнең көнчыгыш төркеме кытай мәдәниятенә нигез салган, икенче бер төркеме Һиндстанга хуҗа булган, өченчесе исә көньякка китеп, Сүрия, Палестина һәм Мисыр җирләрен кулга төшергән, хәтта Испания биләмәләренә кадәр барып җиткән дип күрсәтелә. Әдрән һәм Эгей диңгезләре буенча килгән төрки кабиләләр, имеш, атаклы крит цивилизациясен нигезләгәннәр, борынгы грек мәдәнияте, әлбәттә инде, төрки кабилә булган хеттлар тарафыннан бар ителгән имеш, диелә. Аурупаның эченә үк кереп китә алган төркиләрнең бер өлеше, шулай ук диңгез аша чыгып, Британия утрауларына хуҗа булган. Бу теория буенча, күчмә төрки кавемнәр аурупалылардан акыл һәм мәдәният ягыннан күпкә өстен булып, мәгарә этабында яшәгән аурупалыларга яңа тормыш шартларын өйрәткән... Тиздән әлеге фикерләр яңа гына төзелгән фәнни оешмалар – Төрек тел курумы һәм Төрек тарих курумының эшчәнлеген билгеләүче тезисларга әверелә, Ататөрекнең үз җитәкчелегендә күптомлы төрек тарихын язу эше җәелдерелә.

Дөньякүләм танылган уку йортларында белем алган күренекле татар-башкорт профессорлары алдына менә шул төрдәге фикерләрне фәнни яктан исбатлап, хезмәтләр язу бурычы куела. Табигый рәвештә, аларның күбесе моны кабул итми, Ататөрек сәясәтенә яраклаша алмый, шуның нәтиҗәсендә, билгеле бер этапта рәсми даирәләрдә куылу-кыерсытылуларга дучар була. Мәсәлән, 1931 елда Ататөрек кушуы буенча әзерләнгән «Төрки тарихның төп юнәлешләре» проектының кайбер тезисларын Зәки Вәлиди Туган Әнкарада 1932 елда узган Тарих конгрессында тәнкыйть итә, аеруча Урта Азиянең чүлгә әйләнүе теориясен, дәлилләр китереп, кискен рәвештә кире кага. Конгресстагы бу чыгышына җавап итеп, аны примитивлыкта, ялган чыганаклар һәм ысуллар куллануда гаеплиләр. 1934 елда Зәки Вәлиди әлеге концепциянең нигезсезлеген ассызыклап, «Ком астындагы унҗиде шәһәр һәм Садри Максуди бәй» исемле хезмәт яза, ләкин ул Төркиядә тыела. «Фәнни компетентсызлык»та гаепләнгән галим Истанбул университеты профессорлыгыннан азат ителә һәм Төркиядән китәргә мәҗбүр була.

Ислам тарихында төркиләрнең ролен гарәпләрнекеннән өстенрәк итеп «күрсәтә алмавы өчен», әл-Әзһарны бетергән дин галиме Закир Кадыйрига дә Ататөректән авыр сүзләр ишетергә

туры килә. Инде менә «Төркия» газетасының 2014 елгы 11 май санында Йылдырай Огур исемле журналистның «Бер кичтә наданга әйләнгән ординариус профессорның хикәясе» исемле язмасын укыгач, тагын бер галимебез – Садри Максуди Арсалның да (1878-1957) шундый ук хәлгә төшү вакыйгасының детальләрен белдек.

Сорбонна университетында укыткан С.Максудины 1923 нче елда, Йосыф Акчура ярдәме белән оештырылган «Төрек ожагы» оешмасында доклад сөйләргә дип, Әнкарага чакыралар, шул килүдә Мостафа Кемал паша белән күрешү дә планлаштырыла. Бу очрашуда Ататөрек аңа тормышын үзгәртердәй тәкъдим ясый: *«Яңа дәүләт төзибез. Сезнең кебек галимнәргә ихтыяҗыбыз булачак»*, – дип, Төркиягә чакыра. Милли тойгылар белән янган С.Максуди бу тәкъдимне сөенеп кабул итә һәм гаиләсе белән Әнкарага күчеп тә килә. Яңа республиканың беренче уку йортларыннан булган Хокук мәктәбендә гомуми хокук дәресләрен укыта башлый, «Төркия хокук тарихы»н яза, «Миллият» газетасында төрек теленә реформа темасына караган мәкаләләр бастырып, Ататөрекнең хөрмәтен казана, Төрек тарих курумының нигез салучыларыннан берсе була. Миллиятчелек рухы һәм кемалист тарафдарлыгы никадәр генә көчле булмасын, С.Максуди да тарихның төркиләрдән башлануы, бөек мәдәниятләргә төркиләрнең нигез салуы кебек уйдырма теорияләргә кушылмый, «кояш тел теориясе»[1] турында аның фикерен сораган Ататөреккә: *«Бу теорияне аңларга минем акыл-фикерем җитәрлек түгел»*, – дип җавап бирә.

Ниһаять, беркөнне әлеге темалар тирәсендәге ыгы-зыгыларга түзмичә, ул «Паша хәзрәтләре!» дип мөрәҗәгать итеп, Ататөреккә хат яза һәм: *«Шумер, хетт, һиндләрне төрки дип атап булмый, моны Аурупага кабул иттерә алмыйбыз»*, – дип йомшак кына кисәтә. Төрек тарихы өчен язылган тезисларының профессор тарафыннан тәнкыйть ителүе, әлбәттә, Ататөреккә ошамый, кәефен төшерә, ләкин ул үз линиясен барыбер дәвам иттерә, тарих конгрессларында да үз юнәлешеннән тайпылмый.

Профессор дип зурлап эндәшкән һәм 1928 елдан бирле мәҗлесләренә даими чакырылган Садри Максуди белән Ататөрекнең арасы Чанкаядагы сарайда әзерләнгән бер табын артында шактый нык бозыла. Ататөрекнең якыннарыннан булган Җәмал Гранда истәлекләрендә әлеге вакыйга болай тасвир ителә: *«Кичке мәҗлескә хокук профессоры Садри Максуди дә кунак булып килгән иде. Төрле темаларга сөйләшкәндә, сүз чиратына диңгез юллары банкына җитте һәм Төрек тел курумы тәкъдим иткән атамалар турында фикер алыша башладылар. Диңгезчелек Банкы дипме, әллә Диңгез Банк дипме атау яхшыракмы – шул турыда бәхәсләштеләр. Садри Максуди Диңгез Банк (Deniz Bank) атамасының грамматика кагыйдәләренә туры килмәү фикерен әйтә һәм үз позициясеннән бер адым да артка чигенми иде. Бәхәсне шунда туктаттылар. Ике сәгатьләп вакыт үткәч, Ататөрек, нәрсәгәдер ачуы килеп, Максудига борылды да:*

---

* «Кояш тел теориясе»нә нигез салучылар булып, Аурупа галимнәре исәпләнә. 1935 елда Ататөреккә Венадан бер кулъязма хезмәт килә, бу H.F.Kvergie исемле профессорның французча язылган «La Psychologie De Quelques Des Langues Turques» («Этимологик, морфологик һәм фонетик аспектларда төрек теле») дигән 40 битле китабы була. Ул, башка галимнәрнең, башлыча тюрколог W.Czermak хезмәтләреннән һәм атаклы З.Фрейдның психоанализыннан алынган фикерләргә таянып, шундый тезислар яза: беренче кешеләрнең тәүге күреп белгән объекты кояш булган, алар тирә-яктагы бар нәрсәне, хәтта соңыннан абстракт төшенчәләрне дә кояшка бәйле рәвештә танып фикер йөртә башлаган, имеш. Барлык телләрнең тамыр башлангычы бер телгә барып тоташа. Төрки телдәге абстракт төшенчәләрне тикшереп караган галим аның иң борынгы телләрдән булуын исбатларга омтыла. Ататөреккә бу теория бик ошый һәм ул да, барлык телләр төрки тел тамырыннан үсеп чыгып тармакланган, дигән фикерне яклый.



Әхмәт Зәки Вәлидинең «Ком астындагы унҗиде шәһәр һәм Садри Максуди бәй» исемле китабы. Истанбул, 1934 ел

«Сез профессор түгел!» – диде. Һич көтелмәгән бу сүз барысын да гаҗәпкә салды, профессорга исә зур удар булды. Барыбыз да баскан җиребездә сын кебек катып калдык. Бераздан гаҗәпләнү хисеннән котылган Садри Максудиның болай дип җавап биргәнен ишеттек: «Бер дә алай түгел, мин – профессор. Һәм дә миңа ул исемне һәм кафедраны Төркиядә түгел, Швейцариядә бирделәр. Бер дә булмаса, шунда китеп, дәрес бирермен. Менә хәзер мин торып, мондагы бер командирга: «Син командир түгелсең!» – дисәм, ни булыр, аның командирлыгы юкка чыгармы?! Тик аңа шундый сүз ишетү никадәр авыр булса, миңа да нәкъ шулай ук авыр. Әмма әлегә командирларга кафедра бирмиләр», – диде. Ататөрек Садри Максудиның кулына шәраб бокалы тоткан килеш әйткән бу сүзләренә җавап бирмәде. Бераздан мәҗлес таралды. Максудины мин башка бервакыт мәҗлесләрдә күрмәдем».

1937 елның 24 декабрендә Төркия Бөек Милли Мәҗлесендә диңгезчелеккә бәйле бер канун карала. Җөмһүрият халык партиясеннән депутат булган Садри Максуди да була бу җыелышта. Законның беренче маддәсендә әлеге дә баягы «Дениз Банк» атамасы килеп чыккач, банкның исеме шулай булганын аңлаган С.Максуди, трибунага чыгып: *«Дениз Банк атамасы төрек грамматикасына күрә түгел, төрекчәдә банк сүзе юк, банка сүзе бар, шуңа күрә Дениз банкасы дип атарга тәкъдим итәм»*, – дип чыгыш ясый һәм үз фикерен язма рәвештә Милли Мәҗлескә тапшыра. Профессорга беркем дә каршы килми, тәкъдим тавышка куела һәм күпчелек тавыш белән кабул ителә. Канунны, яңадан төзәтер өчен, комиссиягә юллыйлар. Шунда бер депутат Максудиның колагына иелеп: *«Садри бәй, нишләдегез Сез, Дениз Банк исемен Ататөрек куйган иде бит!»* – ди. Максуди кыска һәм төгәл итеп җавап бирә: *«Ни булса да хакыйкать барыбер үзгәрми бит!»* – ди.

Милли Мәҗлестәге хәл турында хәбәр тиз арада Чанкаяга барып ирешә. Ататөрек, ачуланып, Мәҗлестәгеләргә: *«Әгәр шулай икән, Максудига җавап бирәсез һәм дә радиодан!»* – дип боера. Бу вакытта инде кич җиткән була. Мәҗлестән 7 кеше (араларында депу-

татлар һәм профессорлар да була), машиналарга утырып, Туна проспектындагы радио үзәгенә китәләр. Эфирдагы бөтен программалар туктатыла, төнге сәгать икегә кадәр, әлеге 7 кеше «Дениз Банк» атамасының – төрекчә, Садри Максудиның исә... надан булуын аңлату белән мәшгуль булалар. Чыгыш ясаучыларның кайберләре Максудины гаять каты тел белән «фаш итә», икенчеләре исә, кыяр-кыймас кына, аның төрки тел кануннарын «белмәвенең» сәбәбен, татар булса да, төрки мохиттә тәрбияләнмәвендә, дип күрсәтә. Шунысы кызык, радиодан төрки тел турында лаф орып, галимне гаепләүчеләр арасында тел белгечләре юк дәрәҗәсендә була, күпчелеген элеккеге хәрбиләр, ягъни фәрманны берсүзсез үтәүчеләр тәшкил итә.

Радиодан профессорның «тетмәсен теткәч», чират Милли Мәҗлескә җитә: 27 декабрь көнге утырышта «Дениз Банк» мәсьәләсе иң беренче итеп карала һәм тавышка куеп алынган теге карар юкка чыгарыла. Садри Максудига анда да яхшы гына «эләгә», икенче көнне барлык газеталарда аны хурлап язмалар бастырыла, ул гына да җитми, радиода һәм Милли мәҗлестә сөйләнгән «нотыклар»ның текстлары да газеталарда тулы битләр белән бирелә. Йылдырай Огур әфәнде бу язмаларның кайберләреннән өзекләр дә китерә, Садри Максудиның белемен шик астына алып, аның «төрекчәсенең бозык булуы, үзе белмәгән тел буенча башкаларга акыл сатарга маташуы» турында чыгыш ясаучыларны исемнәре белән атый. «Deniz Bank 100% төрекчә» исеме астында «Җөмһүрият» газетасына интервью биргән һәм алдагы көнне радиодан да сөйләгән Вәдид Узгөрән исемле бер депутат, мәсәлән, болай ди: *«Мин Садри Максуди әфәндене нәрсә дә булса да беләдер, дип уйлаган идем. Дениз Банк атамасына каршы килүеннән аңладым ки, бу бәндә берни дә белми икән... Әгәр ничә еллар буе Төркия төрекләре, төрек яшьләре синең бозык төрекчәң белән биргән дәресләреңне тыңлый икән, моны үзең өчен бер аерым хөрмәт икәнен белеп, төрек нәзакәтенең югары үрнәге, дип кабул итәргә тиешсең. Югыйсә, син – Төркиядә төрекчә сөйләшергә, төрекчә дәрес укытырга дәрәҗәң җитмәслек бер кеше. Кешелек дөньясында, синең кебек, наданлыгын белмичә, үзен галим дип санап йөрүче гафилләр аз түгел шул»*, – дип әйтә.

Башта радиодан, аннары газета рубрикаларында «җаһил» (надан) дип игълан ителгән Садри Максуди инде Ататөрекнең Сорбоннадан Төркиягә чакыртып алган, йөзләрчә тапкыр мәҗлесләрендә утырган, «профессор» дип хөрмәт итеп эндәшкән, китабына кереш сүз язган, тел һәм тарих мәсьәләләрендә аның белән киңәшләшкән ординариус профессор Максуди түгел, ә бәлки режимга каршы торучы шәхес булып күренә башлый. Ул Милли Мәҗлес утырышларында бүтән катнашмый, Ататөрек үлгәч, аның урынына килгән Исмәт Инөню дә аны 1939 елгы яңа Милли Мәҗлескә алмый. Бары тик 1950 елда гына ул, демократик партия вәкиле буларак, Әнкарадан депутат булып сайлана һәм куылган Милли Мәҗлескә яңадан кайта.

1951 елның 10 августы. Милли Мәҗлестә Инөню заманында ябылган «Дениз Банк»ны яңадан ачу өчен канун проектын тикшерәләр. Хөкүмәт проектны тагын «Дениз Банк» исеме белән әзерли. Моны белеп алган Садри Максуди ул көнне Мәҗлескә бармый. Әмма трибунага чыккан депутатлар Садри Максуди теге вакытта каршы чыккан атаманың чыннан да дөрес булмавын искә төшерәләр һәм банкның исеме «Диңгезчелек Банкы» (Denizcilik Bankası) дип үзгәртелә. Шулай итеп, Садри Максуди реванш ала. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

«БЕЗНЕҢ МИРАС»ТА – ХӘБӘРЛӘР

Фотолар һәм видео **beznenmiras.ru** сайтында

● 1-2 декабрьдә «ТАТМЕДИА»га караган кайбер басмаларның баш мөхәррирләре һәм Удмуртиянең күренекле каләм әһелләре, төрле министрлык вәкилләре, «Яңарыш» газетасы хезмәткәрләре катнашында Ижау каласындагы «Халыклар Дуслыгы йорты»нда эшлекле очрашу узды.

Әлеге күркәм чарада «ТАТМЕДИА» генераль директоры урынбасары, «Мәгариф» журналының баш мөхәррире Сөмбел Таишева, «Безнең мирас» һәм «Ялкын» журналларының баш мөхәррирләре Ләбиб Лерон белән Йолдыз Миңнуллина, шулай ук «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, язучы-драматург Рәдиф Сәгъди катнашты. Казаннан килгән кунаклар 6 нчы татар гимназиясендә, 107 нче «Энҗе» татар балалар бакчасында, Карл Маркс урамында урнашкан яңа мәчеттә булганнан соң «Спартак» мәдәният сараенда халык белән очрашты.

● 5 декабрьдә Кәрим Тинчурин театрында Татарстанның халык артисты, Муса Җәлил бүләге лауреаты, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, «Безнең мирас» журналының даими авторы Гөлзадә Сафиуллинаның «Әй, татарлар!» дип исемләнгән юбилей кичәсе булды.

● 7 декабрьдә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының киңәйтелгән утырышы узды. Редакциябезгә әлеге чарада журнал чыга башлауның 25 еллыгы уңаеннан Ринат Закировның Рәхмәт хаты һәм истәлек бүләге тапшырылды.

Хөрмәтле "Безнең мирас" журналы хезмәткәрләре!

Егерменче гасырның 90нчы елларында милли күтәрелеш чорында "Мирас" журналының беренче саны дөнья күрде. Бу милләтебез өчен бик мөһим вакыйга иде. Заман белән бергә атлап барган басмага 25 яшь. Сезнең журналның кабатланмас үз язу рәвеше, үзенең кыйбласы бар. Язмаларыгыз халкыбызның тарихын барлау белән генә чикләнми, аның мәдәниятен, сәнгатен пропагандалау буенча да игелекле эшләр алып бара.

Редакция коллективына һәм авторларга иҗади рух, гомумкешелек кыйммәтләренә тугрылык, киләчәккә омтылыш хас. Сез бүгенге көндә үрнәк булырлык эшләр башкарасыз. Халкыбызның тарихын барлау, эшкә чын күңелдән бирелгәнлек, энтузиазм, иң мөһиме - хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгы, "Безнең мирас"ны файдалы һәм милләт өчен бик тә кирәкле журналга әверелдерде. Киләчәктә дә тоткан кыйблагыздан тайпылмассыз дип ышанам.

Барыгызны да "Безнең мирас"ның юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм, милләтебезнең киләчәген кайгыртып яшәвегезне телим. Сезгә иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете юлдаш булсын. Татар халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген дөрес яктыртучы булып калыгыз!

Бөтендөнья татар конгрессы
Башкарма комитеты рәисе Р.З.Закиров

2016

● 7 декабрьдә Казанның Мәрҗани мәчетендә «Россиянең дин әһелләрен берләштерүдә Мәрҗани мәчетенең роле: Ишмөхәммәт хаҗиның тормыш юлы, мирасы» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл» узды. Биредә

күренекле дин әһеле, остаз Ишмөхәммәт Зәитовка (1752-1841) багышланган «Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы» исемле китап тәкъдим ителде. Китапның авторы – Россия һәм Башкортстанның Язучылар берлекләре әгъзасы Гали Гатауллин.

● Татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайның (1886-1913) шәхси әйберләреннән тагын бер экспонат табылган. Бу хакта «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарихи-этнографик музее директоры Ришат Камалов хәбәр итте.

Аның сүзләренчә, Г.Тукайның чемоданы Әтнә районының Каенсар авылында сакланып калган. «Тукайның апасы Саҗидә Каенсарда яшәгән. Габдулла исә анда хәрби комиссариатка кайта һәм автобиографик әсәрендә дә юл кәрзине белән кайтуын сурәтли. Күзенә ак төшү сәбәпле, аны хәрби хезмәткә алмыйлар. Кире киткәндә, ул чемоданын калдыра. Без ул чемоданны тикшереп карадык, кыяфәте буенча шул чорга туры килә. Әдәби чыганаклар да аның Тукайныкы булуына ишарәли», – диде Ришат Камалов. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВКӘ – 80 ЯШЬ!

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ

Равил Бохараев

Зирәк акыллы дәүләт эшлеклесе киләчәк буыннар рәхмәтен үзенең тирән кризис шартларында тарих тәгәрмәчен упкынга төшереп җибәрмәс өчен гадәттән тыш чаралар күрү сәләте, иҗади осталыгы белән дә яулый. Кыска гына булса да, үзенең ныклы сәяси, икътисади, мәдәни, милли юнәлешләрдәге күп яктан үрнәк булырлык тарихи яңарыш юлын Татарстан Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә үтә.

Демократия турында сүз барганда яисә лаф органда еш кына бик мөһим бернәрсәне оныталар. Аеруча әһәмиятле карарларны демократик кабул итү дәүләт җитәкчеләрен ул карарларны тормышка ашырганда катгый шәхси җаваплылыктан азат итми бит. Шуңа күрә демократик дәүләттә югары хакимлек һич тә, теле әле генә ачылган тар карашлы кеше уйлаганча, бик рәхәт нәрсә түгел, ә зур җаваплылык. Аны демократияләшү давылында хакимияткә ыргылучы сәясәтчеләрнең сирәге генә аңлый һәм үз өстенә алырга мөмкин.

1996 елның февралендә мин Минтимер Шәриповичтан: сайлау алдыннан Сезне нинди хисләр били, дип сорагач, ул, каршылыклы хисләр, дип җавап бирде. Бер яктан, республика халкының үзенә ышаныч белдереп, икенче мәртәбә Президентлыкка сайлавына ул шикләнми иде. Шуңа күрә, республика коммунистлары, сәяси сиземлек күрсәтеп, үзләренең альтернатив кандидатын сайлауга куймаска карар кылды. Шул ук вакытта, М.Шәймиев бу эш аңа никадәр проблемалар йөкләгәнне һәм аларны үзе хәл итәсен дә бик яхшы белә иде.

Соңгы елларда сәяси җаваплылык декларатив төшенчә булудан туктады, ләкин моны сәясәтчеләрнең бик азы гына аңлады. Сәясәт совет елларында яхшы куелган дәүләт спектакленнән бик тиз дары һәм кан исе аңкытып торган фаҗигагә әверелде.

Бу шартларда күпмилләтле Татарстан халкы исеменнән 1990 елда Татарстан Республикасы дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итү дә, аны бөтен халыкның хуплавы да, 1992 елгы референдумда кабат яклап чыгу да чиктән тыш җаваплылык кына түгел, батырлык та, тел-теш тидерә алмаслык тәвәккәллек тә таләп итте. 1992 елның язында федераль үзәк вице-президент А.Руцкой теле белән «милли карьеристларны һәм сепаратчыларны 10-15 елга төрмәгә утыртырга кирәк, югыйсә, дудаевлар һәм шәймиевләр калачак» дигән таләп куйды. Ул милләт җитәкчеләрен генә түгел, халыкның үзен дә куркытып каралга әзер иде. Ә Россиянең Югары Советы Рәисе Р.Хасбулатов М.Шәймиевне тимер читлеккә бикләп, Мәскәүгә алып килү белән янады. 1992 елгы референдум көннәрендә соңрак Чечняга басып кергән танклар Татарстанга керергә дә әзер торды.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Бу хәл Татарстанның бердәм җитәкчелегенең күпмилләтле халкы каршында тарихи җаваплылыгын яхшы аңлавы аркасында гына булмый калды. Хәзер республиканың казанышлары бөтен дөньяга билгеле.

Татарстан Президентының сабыр акылында, үз эшенә инанганлыгында һәм оста шахматчыларча һәр адымын төптән уйлап эш итә белүендә холкының, шәхесенең ныклыгы чагылды, дәүләт идарәсе юлындагы һәр адымы шөһрәткә омтылу түгел, ә тормыш сабагы икәнлеген күрсәтте. Ә тормышны белүне, өйрәнүне ул, үз сүзләре белән әйткәндә, теләсә нинди шөһрәттән дә югарырак куя. М.Шәймиевнең табигате, холкының ныклыгы тормышны белүгә нигезләнгән (андый сыйфатны яңа сәясәтчеләр хәзер «прагматизм» дип атый), һәм моңардан хәбәрдар булмаган кайберәүләр Президент йөзенфеноменын ачыкларга тырышканда кыен хәлдә кала.

Алга куйган олы максатка ирешер өчен халыкны корбан итмичә, киресенчә, аның хәленә кереп, яклап эш итүнең сирәк үрнәген дәүләтчелеге кабат аякка басып килгән вакытта, иң читен, иң кыен чорда Татарстанга җитәкчелек иткән сәясәтче Минтимер Шәймиев күрсәтте. Дөньяның сәяси тарихында халыкка шундый хөрмәт үрнәге бик сирәк очрый торган хәл.

Халыкара һәм Россия политология сүзлегендә хәзер бик еш кулланыла торган төшенчә – «регион» («төбәк») дигән сүз бар.Татарстан турында да шулай диләр. Ләкин сабыр һәм төптән уйлап эш итүче Гаагада четерекле мәсьәләләр караганда Татарстан делегациясе әгъзалары күз алдында безнең «регион» – башыннан күпне кичергән гүзәл туган ягыбыз – Алабугамы ул, Бөгелмәме, Актанышмы, әллә Минзәләме, Чулман-Камамы, Идел-Волгамы, Чирмешән-Актаймы, легендар Казанмы яисә Казан артымы – изге, бөек Ватан образы торгандыр. Ватан искә төшкән саен хәтердә йөрәкнең иң түренә кереп урнашкан һәм ишеткән саен аны сулкылдатып тибәргә мәҗбүр иткән татар халык җырлары, әниләребез җырлары яңгырагандай була. Рухы һәм йөрәге белән татар булган һәр кеше кебек, андый җырларны Президент М.Шәймиев тә тыңларга һәм җырларга ярата.

Минтимер Шәрип улы Шәймиев Татарстанның Актаныш районындагы Әнәк авылында 1937 елның 20 гыйнварында туган. Аның да балачагы һәм яшүсмер еллары даими хезмәттә, тор-

Тантаналы көн

М.Шәймиев Венгрия Президенты Арпад Генц белән. Болгар. 4 июль, 1993 ел

мыш мәктәбендә һәм белем юлында уза. Дәрескә барыр алдыннан үзенә йөкләнгән хуҗалык эшләрен бетереп китәр өчен аңа иртәнге сәгать биштән торырга туры килә. Ә шулай да ул ун ел буена гел «бишле»гә генә укый. Президент Минтимер Шәймиев еш кына, иң яхшы, иң ышанычлы кадрлар авылда туып үсә, ди икән, ул монда авыл тормышы кешеләргә төпле хезмәт тәрбиясе бирүен, чын-чыннан җаваплылык хисе тәрбияләвен истә тота. Авыл хезмәте көндәлек хезмәт һәм аны иртәгәгә калдырып булмый шул.

Элеккеге совет республикаларының кайберләрендә һәм Россиядә тирән сәяси, икътисади, социаль һәм милләтара кризис шартларында Татарстандагы иҗтимагый-сәяси тотрыклылык, икътисади үсеш табышмак белән бер. Аны аңлау өчен сәясәтне өйрәнүчеләр һәм вакытлы сәясәтчеләр бик нык баш вата. Бер-ике көнлек, вакытлы статистика мәгълүматларына таянып, алар Татарстан җитәкчелегенең нинди минминлеге республиканың иҗтимагый тормыш үсешенә, икътисадының акрынлап ныгый, тотрыклылана төшүенә шулай уңай йогынты ясады икән, дип баш вата. Берничә ел элек Татарстанны давыллы базар диңгезендә «коммунизм утравы булып кала бирә» дип гаепләгәндә чит ил һәм Россиянең сәяси, икътисади күзәтүчеләре әнә шул статистика мәгълүматларына таянды.

Ләкин гомумроссия хосусыйлаштыру шаукымы тынгач, шул ук күзәтүчеләрнең Татарстан моделе белән кызыксынуы күзгә күренеп артты. Татарстан базарга керү юлында ныклы нигез салмыйча бер генә адым да ясамады бит.

«Без тамырдан үзгәрешләрне әмер белән (ул әмер ныклап уйланмаган булса, бигрәк тә) кертү ярамаганны белдек, – ди Президент Минтимер Шәймиев. *– Без максатыбызга, теләгебезне ачык белеп, тирә-якка артык каранмыйча юл тоттык. 1992 елда республикада радикаль реформалар башланганнан бирле безнең күрсәткечләр тулаем Россиянеке, хәтта алдынгы саналган өлкәләрнеке белән чагыштырганда да әйбәтрәк. Республика үзе күздә тоткан төп максат-*

Күңелле мизгел

ларга иреште. Һәм бездә халык өстенә төшкән авырлыклар башка төбәкләр белән чагыштырганда азрак булды».

Чыннан да, Россиягә караганда акрынрак башласа да, Татарстан ышанычлы төстә икътисади тизләнеш алды, чөнки чираттагы эшкә алдагысы нәтиҗә биргәч кенә кереште.

«Тел – халыкның рухы. – Президент Минтимер Шәймиев бу сүзләрне еш кабатлый. – *Телне югалту – милли рухыңны югалту дигән сүз. Безгә тигез хокуклылык беренче чиратта татар теле үсешенә мөмкинлек тудыру өчен кирәк. Бу исә тигез хокуклылык принцибын бозу түгел, ә тарихи гаделлекне кире кайтару булыр».*

1952 елда Казан алынгач һәм дәүләтчелек юкка чыккач, чәчәк аткан бөек шәһәр культурасының көчләп авыл җиренә сөрелүе халкыбызның тарихи хәтерендә тирән саклана. Мәдәният сөрелә, ләкин ул татар авылында эзсез югалмый. Киресенчә, борынгылыгы һәм куәте белән мәдәният авыл гыйлемлелеген, авыл тәрбиясен иң югары гуманлы цивилизация дәрәҗәсенә күтәрә. Буыннан-буынга татар галимнәре һәм шагыйрьләре авылда яши, аларның хезмәтләре, Россия империясе чикләре аша үтеп, еракларга тарала. Нәкъ менә авылда мәдрәсәләр булу аркасында барча халык укый-яза белә. Нәкъ менә авылда тарихи мәгълүматлар телдән-телгә күчеп йөри, бөек Кол Галинең бөтен кешелек дөньясы горурлыгына әйләнгән «Йосыф кыйссасы» кебек кулъязма әсәрләр сакланып кала. Татар халкының 1552 елдан соң исемнәре дөньяга тарал-

Минтимер Шәймиев белән Рөстәм Миңнеханов

ган иң күренекле вәкилләре, кагыйдә буларак, авылдан чыккан. Бу очраклы хәл түгел һәм, шунысын да әйтик, татар мәдәнияте бары тик җиргә генә бәйле, дип раслау да дөрес булмас. Әлеге хәл иң элек тарихи гаделлек тантанасы. Ул цивилизациянең элеккеге халәтенә – халкыбызның шәһәр мәдәнияты һәм дәүләтчелеге яңару юлына табигый төстә кире кайтуын чагылдыра.

Татар авылы – мәрхәмәтле ана һәм мәңгелек ризык чишмәсе генә түгел. Ул хезмәт сөючәнлеге белән данлыклы укытучы – әхлак һәм тарихи фәлсәфә укытучысы. Моны совет елларында хакими катлау гына аңлап җиткермәде. Авылда туып үскән, халык әхлагы канына сеңгән М.Шәймиев моны яхшы белә. Күчеш чорының иң авыр елларында ул аграр өлкәне өстенлекле өлкәләрнең берсе дип игълан итте, авылга ярдәм программасы булдырды. Моның нәтиҗәләренә күз салсаң, күңелгә шатлык йөгерә. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү елдан-ел арта, авылларда иҗади хезмәт кайный. Татарстан авыллары, юллары күзгә күренеп яңара, матурая.

Тормышка киңрәк карасаң, гасырларга сузылган фаҗигале тәҗрибәне белсәң, шул тәҗрибәдән туган халык фәлсәфәсен аңласаң, Минтимер Шәймиевнең хезмәтчел крестьян егетеннән һәм илленче елларда дәрәҗәле булган Казан авыл хуҗалыгы институты студентыннан алып Мөслим ремонт-техника станциясенең баш инженерына, республиканың мелиорация һәм су хуҗалыгы министрына, соңрак яңадан туган дәүләт Президентына кадәр үткән юлы гаҗәп түгел, киресенчә, гаять табигый хәл. Президентның көндәлек хезмәтендә, чын хуҗаларча төптән уйлап эш итүендә, дәүләти гамәлләрендә хезмәт халкы, көзгедәге кебек, үзен күрә. Минтимер Шәймиев мисалында «социаль нигез» дигән төшенчәнең мәгънәсе әнә шулай ачыла.

(Язма «Президент Минтимер Шәймиев» дигән китаптан (Flint River Press Ltd 1996, Лондон) алынды.) ■

Татар әдипләре – Минтимер Шәймиев турында

«Кызык сүз әйттең әле син, Туфан...» Минтимер Шәймиев Туфан Миңнуллин белән

«Гади татар авылында туып-үскән малайдан Ил башы дәрәҗәсенә күтәрелү өчен гаҗәп зирәк акыллы, тырыш, тәвәккәл, көчле характерлы, белемле, мәгънәле һәм тагын бик күп асыл сыйфатларга ия булырга кирәк.

Ә бит бәйләнеп куелган дәүләтнең Президенты булу бәйсез дәүләт башлыгы булудан күпкә авыррак».

Туфан Миңнуллин

«Президент буларак та, халык улы буларак та әйткән сүзегез безнең күңелләргә үтеп керде:

– Булдырабыз!

Бу горур сүз халык хыялларына, омтылышына, халәтенә туры килде. Сез чын мәгънәсендә асыл ир-егетләр сүзен әйттегез. Әйе, нинди генә эшләргә алынсак та, без – булдырабыз!

Холкыгыз, яшәешегез безнең хисләргә тәңгәл. Һәм затлы, олпат яшькә җиткән чорыгызга бу рух ифрат та килешеп тора».

Зөлфәт

Гамьле әңгәмә. Минтимер Шәймиев Фәнис Яруллин белән

«Һәр кенәгез Сезнең елларга тиң,
Һәр кенәгез Сезнең – бер гомер.
Галиҗәнап Вакыт бирер әле
Үз бәясен Сезгә, Минтимер».

Фәнис Яруллин

Йөзләрдә – бәйрәм шатлыгы.
Минтимер Шәймиев Шәүкәт Галиев белән

*«**М**өстәкыйльлек безнең байрагыбыз,*
***И**рекле ил туды дөньяга –*
***Н**игезе нык-тирән тарихларда,*
***Т**атарстан булыр өр-яңа!*
***И**маныбыз камил. Ышаныч нык,*
***М**аксатыбыз, алга дәшәсең:*
***Е**лдан-елга үсеп, күтәрелеп,*
***Р**еспубликам мәңге яшәсен!»*

Шәүкәт Галиев

«Житәкчелек – олуг сәнгать,
Килми ул бер дә юктан.
Ул башлана шигъриятттән,
Килә әдәбияттан.
Килә изге туган яктан,
Табигый матурлыктан.
Табигатьнең матурлыгы,
Зиһене Сезгә йоккан.
Халыкны сөйгән батырлык
Озакка барыр, дибез.
Халкыбызның бәхетенә
Озын гомер телибез».

Әхсән Баян

Беренче карашка ул Татарстан төбәгендәге бик күп авыллардан әллә ни аерылып та тормый кебек. Биредә дә күркәм кешеләр яши, бу авылның да үзенә генә хас матур, ямьле табигате бар, ошбу авыл балалары да – шук-шаяннар, самими-саф җанлылар, эшчән-тырышлар, җырга-моңга, шигърияткә гашыйклар...

Бик күп авылларның халкы үзләрендә туган күренекле шәхесләре, олпат кешеләре – шагыйрьләре, язучылары, галимнәре, артистлары, табиб-мөгаллимнәре белән лаеклы рәвештә горурлана. Нур Баян, Рахмай Хисмәтуллин кебек шагыйрьләр дә – Әнәк авылының горурлыгы, мактанычы.

Шулай да Әнәк авылы тагы кеме-нәрсәсе, кай ягы белән аеруча данлыклы соң?

Әлбәттә, күпләрегез дөрес тәгаенли – хак уйлый: Әнәк – Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең туган авылы.

Шәймиевләр гаиләсе. Уртада – Шәрип абый, аның янәшәсендә, уңда – Нәгыймә апа; сулда – олы кызлары Дөргалия; арткы рәттә, сулда – Мәрзия, аннары – Мәдәния, Минтимер, Мәрзиянең кайнанасы – Өммегөлсем; Шәрип абый алдында – Дөргалиянең кызы, Нәгыймә апа янында – Мәрзиянең кызлары. 1954 ел

(Минтимер Шәймиевнең балачагыннан кайбер хатирәләр)

Мәдәния Ильясова

МИНТИМЕР АБЫКАЙ

БЕР УРАМДА – СИГЕЗ БАЛА

Әрлән урамы... Әнәктәге безнең дүрт йортлык урамны халык әнә шулай атап йөртә иде. Өске як урам – Йомран урамы. Без бер урамда сигез бала үстек – Зөфәр, Сәхия, Халидә, Нәфисә, Галия, Мөнҗия апа (утыз алтынчы елгы) һәм Минтимер абыкай белән мин...

Тату үскәнбездер инде, әйткәләшкәнебезне, сугышканыбызны бер дә хәтерләмим.

ҮРӘЧӘЛЕ ЧАНА, ТАКТА ЧАҢГЫ

Кыш көне тау шуганда чаналар җитми иде. Үрәчәле өч чана каян килеп шулхәтле балага җитсен инде. Әле өстәвенә шулар еш ватылып-җимерелеп тора... Ярый әле Нуретдин абый белән Минтимер абыкай бар – алар ватык чананы шундук рәтләп куя. Тагы шул хәтердә: Минтимер абыкай (Габделхак абый белән бергә) һәр малайга

тактадан чаңгы ясап бирде. Олтанлы киез итекләр киеп, шул чаңгыларны тагып, куанышып шуа иде малайлар...

ӘТИ... АБЫЙДАН ӨЙРӘНӘ

Безнең Минтимер абыкай бик әйбәт укыды. Бала чагыннан ук аңа әткәй бик зур өмет белән карый иде. «Син безнең прокурор булырсың, син безнең министр булырсың, син безнең галим булырсың!» – дип әйтә торган иде. Безнең әти мәдрәсәдә өч сыйныф кына укыган кеше. Күп нәрсәне үзлегеннән өйрәнгән. Минтимер абыйның әтигә партия тарихын тулысы белән сөйләп-аңлатып чыкканын хәтерлим. Шулвакытта ук аның фикерләү дәрәҗәсе зур булган инде...

КАГЫЙДӘ ҺӘМ МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК

Минтимер абый мине мөстәкыйль булырга өйрәтте. Ничек итепме? Мин сорый идем еш кына: «Моны ничек эшлисе?» – дип. Ул әүвәл: «Кагыйдәсе бар аның, укы, өйрән!» – дип әйтә иде. Мин һаман аңлый алмыйча интексәм генә – әйбәтләп төшендерә. Минтимер абыйча бу шулай инде: башта үзең укы, уйлан, тырыш, эшлә. Тагын бер бик әйбәт сыйфаты бар иде Минтимер абыйның: ул вакытны дөрес бүлә белә – уйнады, малларны карады... дәрескә утыра. Ә безгә, безнең ишеләргә күбрәк уйнау кирәк инде...

«ӘРТИСТЛӘР»

Минтимер абый белән икәү «Бала белән күбәләк»не уйный идек. Мин – беренчедә, ул өченчедә укыган чак. Әти-әниләргә без үзебезчә концертлар куя идек бит. Әнкәйнең, әллә олы апаның ефәк шәле бар иде. Мин шул шәлне бөркәнеп, күбәләк булып тезләнеп, тибрәнеп торам. Бала – Минтимер абый сөйли. Хор белән җырлый идек... Скетчлар да куя идек. Бер тамашада Минтимер абый персидәтел булып уйнады бит әле. Дуслары Гайнулла микән, берсе бригадир булды. Без – колхозчылар булганбыздыр инде. Укытучыбыз Хәдичә апа өйрәтә, без шуны уйныйбыз...

ИКЕ ТОРНА – ИКЕ «ШҮРӘЛЕ»

Кич белән, әти эштән кайткач, чабылмыйча калган, чабар өчен авыр булган җирләргә печәнгә бара идек. Абый белән икәү. Абый чаба, мин төйи идем. Кичке унберләр тирәсендә җырлый-җырлый кайта идек...

Бер баруыбызда ике шәүлә күрдем. Караңгы төшкәнрәк чак. «Минтимер абыкай! Шүрәлеләр, шүрәлеләр!» – дим. «Кайда?» – ди абыкай. «Борчак басуы кырында!» – дим.

Карады, карады да... «Нишләп шүрәлеләр булсын! Торналар бит болар!» – ди.

Шуларның очып киткәннәрен карап тордык.

Чыннан да, ике торна иде...

ҖӨНЛЕКӘЙ – КЫРГЫЙ КИШЕР

Җиләккә дә йөри идек без. Хантимер абыйга да, Минтимер абыйга да ияреп. Буш вакытлары булганда алар бөтен урам балаларын җыеп алып баралар иде. Хантимер абый Минтимер абыкайдан өч яшькә зуррак (димәк, миннән биш яшькә олы була инде). Өч-дүрт чакрым ераклыктагы Әнәк урманы дигән җиргә барабыз. (Чиялек белән Айман авыллары итәгендәге урман ул). Җиләк тә җыярга өйрәттеләр безне, балтырган да...Нинди ашый торган үлән үсә – шуны ашый идек. Хәтта җөнлекәй дигән үсемлекне табарга өйрәндек, кыргый кишер инде ул...

Пучы мәктәбендә җиденче сыйныфта укыган чактан бер истәлек. Минтимер – алгы рәттә уңнан беренче. 1951 ел

Хәдичә Әхмәдуллина

МИНЕМ УКУЧЫМ – ПРЕЗИДЕНТ!

ДӘФТӘР, ЙОЛДЫЗЛАР ҺӘМ ФАРАЗ

Минтимернең бала вакыты авыр чорга, авыр заманга туры килде...

Эт шомырты җыя идек – язу карасы өчен. Хәзерге авторучкалар юк бит ул чакта. Шомыртны кайнаткач, зәңгәр кара чыга иде. Шуңа манып яздык инде. Корымнан да кара ясаган чаклар булды. Укучы санына карап перо (каләм) бирәләр иде. Каз каурыйларыннан каләм ясадык. Дәфтәргә дә кытлык. Минтимер матур язуга дип бирелгән дәфтәргә йолдызлар ясаган. Минтимер, нишләп, минәйтәм, матур язу дәфтәреңә йолдызлар ясадың, дим. Шулхәтле дәфтәрне бетерәләрмени, дим. Үземчә орыштым инде үзен. Кечкенәдән сабырлыгы үзенә җитәрлек. Сабыр гына әйтә бу: «Апа... ни бит... күктә бернәрсә дә юк бит... Чип-чиста бит... Йолдызлар – чиста күктә... Минем дә чиста дәфтәргә йолдызларны ясыйсым килде», – ди.

Мин хәзер уйлыйм. Минтимернең алдан күрү сәләте, алдан күрүчәнлеге Аллаһы Тәгаләдән бирелгән сыйфат булгандыр инде: Җир шарының бер ноктасында үзенең дә йолдыз буласын фаразлаган мизгел булгандыр ул...

БЕЗНЕКЕЛӘР ДӨМБӘСЛИЛӘР

Мин балаларга җырлар өйрәнеп килергә куша идем. Сугыш чоры бит, сугыш турында булсын, дип әйтә идем.

Минтимер дә өйрәнеп килгән:

– Бөтенесен дә белмим, менә шушы өлешен генә беләм, – ди:

Дөмбәслиләр, дөмбәслиләр
Безнең кызыл армислар...
Тәгәриләр, тәгәриләр
Фашистлар!..

«Ул безне өлкәннәрнең күзенә туры карарга, алдашмаска өйрәтте...»

М.Шәймиев беренче укытучысы Хәдичә апа Әхмәдуллина белән. Сентябрь, 2007 ел

«Мин шул җирен генә отып калдым», – дип шуны җырлап күрсәтә.

«Щорс турында җыр» бар иде. Урысча ул:

«Шел отряд по берегу,
Шел издалека...»

Бу җырны бик яратып җырлый иде Минтимер...

«ПОЧЁМ ПРОСА?»

Чор бик авыр булса да, балалар, шул исәптән, Минтимер дә, укуга да, җыр-биюгә дә сәләтле иде.

Диалоглы сөйләмле концертларда катнаша иде Минтимер. Мин өйрәткәннәрне генә түгел, үзләре уйлап табып та уйныйлар иде. Сыйныфташы Инсаф белән. Сатучы белән сатып алучы булыйп уйныйлар:

– Почём проса? – дигән була берсе.

– Әйе, әйе, улым... Мичтә кипкән корысы! – дигән була икенчесе.

Көнбагыш сатучыдан тегесе, урысча белмәгәч, «проса» дип сорый. Көнбагыш коры бит инде, тегесе «коры» дип әйтә...

УЙЛАР, ХЫЯЛЛАР

– Мин прокурор булам, дигәч, бик усал кеше буласыңмыни? – дим Минтимергә.

– Юк, апа, прокурорны усал дип әйтеп булмый. Закон нәрсә куша, шуны эшлисең дә – бетте-китте! – дигән була...

Бервакыт диктант яздык. Диктантның исеме «Валерий Чкалов» иде. Диктантны язгач, Минтимер:

– Менә, апа, мин дә Чкалов кебек очучы булырга уйладым әле, – дигән була.

– Ярар, – минәйтәм, – кем булсаң да булырсың... Тик әйбәт укырга кирәк, акыллы булырга кирәк! – дим.

(2006 елның 12 декабрендә М.Ш.Шәймиевнең сеңлесе М.Ильясова белән беренче укытучысы Х.Әхмәдуллина сөйләгәнне Ләбиб Лерон кәгазьгә төшерде.) ■

Габдерәшит Ибраһимов (1857-1944)*

Асия Рәхимова

Россиянең төрки халыклары һәм Ислам тарихында сизелерлек эз калдырган шәхес, белем бирү мәсьәләләрендә яңалык яклы дин галиме, газета һәм журналлар оештыручы, язучы, татарлардан беренче сәясәтче, шулай ук бик күп җирләр гизгән сәяхәтче буларак та танылган Габдерәшит Ибраһимов 1857 елның 23 апрелендә Себердә – Тобол өязенең Тара шәһәрчегендә дөньяга килә.

Башта туган ягында, ә 1880-1884 елларда Гарәбстанның Мәдинә шәһәрендә мәдрәсә белеме ала. 1885 елда туган җиренә кайтып, мәдрәсәдә укыта башлый, өйләнә, өч баласы туа. Мәдрәсәләрдә реформа ясау, яңа ысул белән укытыла торган мәктәпләр ачу, Истанбулга татар шәкертләрен алып барып уку йортларына урнаштыру кебек мөһим белем-тәрбия эшләре белән шөгыльләнә. 1892 елда Габдерәшит Ибраһимов казый итеп билгеләнә, сигез ай дәвамында Оренбург шәригать мәхкәмәсе рәисе вазифасын башкара. Бу елларда ул ятимнәр һәм фәкыйрьләргә ярдәм итү җәмгыятьләре оештыра, үзе дә шуларда хезмәт куя. Казыйлыктан үз теләге белән китеп, 1897 елга кадәр Истанбулда яши, шул елларда Урта Азиягә һәм Швециягә барып, кайбер күренекле шәхесләр белән очраша.

Габдерәшит Ибраһимов хакында, Россиядә беренчеләрдән булып татар матбугатына нигез салган шәхес ул, дип әйтсәк тә ялгыш булмас. 1897-1900 еллардагы шактый озакка сузылган сәяхәттән Россиягә кире кайткач, Г.Ибраһимов татар телендә газета чыгарырга тырышып карый. Әмма рөхсәт бирелмәгәч, 1900 елда Санкт-Петербургта «Мир'ат» (Көзге) исемле альманах ача. 1900-1903 һәм 1907-1909 елларда Санкт-Петербург һәм Казан шәһәрләрендә аның 22 саны дөнья күрә. Мәҗмуга дип тә атарга мөмкин булган «Мир'ат»ның төп мәсләге – татар иҗтимагый тормышында хөкем сөргән артталыкны, искелекне җимереп, яңаны төзү, тәрәккый итү фикерен тарату һәм, иң әһәмиятлесе, исеменнән дә аңлашылганча, чынбарлыкны дөрес чагылдыру була. Габдерәшит Ибраһимов Россия мөселманнарының сәяси һәм дини бердәмлеген көчәйтү максаты белән 1904 ел ахырында Петербургта «Өлфәт» исемле башка бер журнал чыгара башлый. Матбугат эшләре белән беррәттән, мөселманнарның сәяси хокукларын яклау һәм саклау өчен дә күп көч куя.

*Сәяхатнамә белән таныша башлаганчы, кыскача гына булса да, Габдерәшит Ибраһимовның тормыш юлын күздән кичерү дөрес булыр дип санадык. Сәяхәтче галимнең тәрҗемәи хәленә кагылышлы мәгълүмат аның үзенең «Тәрҗемәи хәлем яки башыма килгәннәр» дигән китабына (китапның Флора Әхмәтова тарафыннан хәзерге графикага күчерелгән басмасы да булуын искәртеп үтәргә кирәк) һәм төрек галиме Исмаиль Түркоглуның Габдерәшит Ибраһимовка багышланган хезмәтенә (İsmail Türkoğlu. Sibiryalı Meşhur Seyyah Abdürreşid Ibrahim. – Ankara: Türkiye Diyanet vakfı yayınları, 1997. – 172s.) таянып әзерләнде.

Габдерәшит Ибраһимов

1907 ел ахырында ул сәяхәткә чыгып китә: Урта Азия һәм казакъ далаларын, шул тирәдәге шәһәрләрне гизеп, Себергә, аннан Казанга килә. Моннан ул 1908 елның 16 сентябрендә янәдән зур сәяхәткә кузгала. Уфа, Чиләбе, Кызылъяр (Петропавловск), Омск, Томск, Иркутск шәһәрләре аша Монголиягә, аннан Маньчжуриягә, Харбинга, соңрак Владивостокка барып җитә, шушыннан пароходка утырып Япониягә китә. Сәяхәтенең күпчелек вакытын Япониядә уздыра. 1909 елның июнендә Кореяга, аннан Кытайга, Сингапурга һәм Һиндстанга юл ала. 1910 елда Хиҗазга барып хаҗ кыла, аннан соң Бәйрут аша Истанбулга килә һәм шунда төпләнә. 1918 елда тагын бер сәяхәткә чыга. Бу юлы Украина, Литва, Германиядә йөреп, аннан Көнчыгыш Төркестанга килә, туган җире Себерне дә барып күргәннән соң, Россиянең кайбер төбәкләрендә була. Шул ук елны Төркиягә кайта. Япониядә Ислам динен тарату фикере һаман тынгылык бирмәгәнгә, 1933 елда 76 яшьлек Габдерәшит Ибраһимов кабат Япониягә китә. Токиода мәчет салдыру эшен башлап йөри, аны оештыра. 1937 елда мәчет ачылганнан соң, аның беренче имамы вазифасын үз өстенә ала. Япония дәүләтендә 1939 елда Ислам диненең рәсми дин буларак кабул ителүендә бу шәхеснең роле зур. 1944 елда Габдерәшит Ибраһимов вафат була һәм Токиодан ерак түгел мөселман зиратында җирләнә.

XX гасыр башы Россия төркиләре тарихы Габдерәшит Ибраһимов чыгарган газета-журналларның урынын һәм ролен танудан, аның хезмәтләреннән, ул яклаган дөньякүләм Ислам берлегебердәмлеге фикереннән башка дөрес тә,


ترجمهٔ حالم
یاکه
(باشـمه کلن‌لر)
محرر و ناشـری:
عبدالرشید ابراهیموف
طبع اولندی عبدالرشید ابراهیموفنڭ الیکتریق باصمه خانه سنده
س.- پتربورغده غلازوفسکی اورامده ۱۲ خانه ده
Электро-печатня А. О. Ибрагимова, СПБ., Глазовская 12.

Г.Ибраһимовның «Тәрҗемәи хәлем яки башыма килгәннәр» китабы

тулы да булмас иде. Үз гомерендә төрле милли һәм дини темаларга багышланган 280гә якын хезмәт һәм әсәр язып дөньяга чыгарган, төрле исемдәге дистәдән артык газета һәм журнал бастырып тараткан бу олы шәхеснең тууына тиздән 160 ел тула.

Журналда Габдерәшит Ибраһимовның «Галәм-е Ислам» («Ислам дөньясы») хезмәте бүлекләрен бирә башлыйбыз. Ике өлештән торган бу сәяхәтнамәнең беренче китабы һиҗри ел исәбе белән 1328 елда (милади 1910 ел), икенчесе 1331 елда (милади 1913 ел) Истанбулда басылган. Гарәп хәрефләре һәм галимгә хас «куе» госманлы теле белән язылган әлеге хезмәтне Төркиядә инде берничә тапкыр хәзерге төрек теленә күчереп бастырып чыгардылар. Мәсәлән, 1987 елдагы басма Мехмет Паксу, 2012 елгы басма Эртугрул Өзалп тарафыннан әзерләнгән. Без болардан һәм «Галәм-е Ислам»ның асыл басмасы ксерокүчермәсеннән дә файдаланып, аны татар теленә тәрҗемә итеп, укучы игътибарына тапшырабыз.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов


١١٤٦

عبدالرشید ابراهیم

عالم اسلام

و

ژاپونیاده انتشار اسلامیت

ترکستان — سبریا — مغولستان — مانچوریا — ژاپونیا — قوره —
چین — سنغاپور — جزایر ماورای هند —
هندستان — عربستان — دارالخلافه —

جلد

— ١ —

استانبول : احمد ساقی بك مطبعه‌سی

١٣٢٨

«Галәм-е Ислам» китабының тышлыгы

ЙА ФӘТТАХ, ЙА ГАЛИМ!*

Җир йөзендә иң мөһим мәсьәлә нәрсә, дип сорасагыз, яшәү – көн күрү мәсьәләсе, дияр идем. Кеше тырышып-тырмашып көн итә, тир түгеп эшли икән – яшәр өчен көч куеп эшли, тырыша. Кешенең бөтен уй-фикерләреннән дә алдарак торган бер уй-фикере булса, бу – аның яшәеше, тормыш итүе белән бәйле уе, фикере.

Тормыш итү мәсьәләсендә кешелек өчен ике төрле тормыш күз алдында тотыла ала. Беренчесе – иҗтимагый тормыш, икенчесе – шәхси тормыш, ягъни һәрбер кешенең үзенә генә бәйле яшәеше.

Һич тә икеләнмичә әйтергә мөмкин: кешелекне тәшкил иткән шәхесләрнең күпчелеге үз тормышы белән мәшгуль һәм шәхси тормышыннан башка берни турында да уйламый. Шул сәбәпле, үз тормышын барыннан да өстен күрә, аннан башка берни белән дә кызыксынмый.

Иҗтимагый тормышны яратучы кайбер кешеләрнең исә бөтен уй-фикерләре, бөтен борчулары һәм эш-хәрәкәтләре җәмгыятьнең яшәеше белән бәйле. Бу төр кешеләр азчылыкны тәшкил итә, ләкин араларында омтылышлары юлында, җәмгыять тормышы хакына үз тормышларын фида кылучылар да очрый.

Тормышның һәр ике төре дә гаять табигый, кешенең холкына һәм асылына хас дип санаучылар зур күпчелекне тәшкил итә.

Иҗтимагый тормыш белән яшәүгә омтылыш күбесенчә тәрбия нәтиҗәсендә барлыкка килә, ләкин ул кешенең табигате, яратылышы белән бәйле булган омтылыш дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Тәрбия аша бу сыйфатларга ия булган шәхесләр, гадәттә, күпмедер вакыт үзләрен җәмгыятькә хезмәт итүгә багышлыйлар, ләкин аларның әлеге теләге, бик катгый булмаганга, озакка бармый. Кыенлыклар чыгуга бу теләкләреннән ваз кичеп, читкә тайпылалар, яисә һаман да әлеге юлдан барган кебек күренергә тырышып, чынбарлыкта берни дә эшләмиләр. Көннәрдән беркөн җәмгыятькә хезмәт итү теләкләре сүнә, эзе дә калмый.

* Йа фәттах, йа галим – Аллаһы тәгаләнең 99 исеме арасындагы, 19 нчы һәм 20 нче исемнәре белән бәйле зикер-доганың бер өлеше. Әл-фәттах – ачучы, аңлатучы, кыенлыкларны җиңеләйтүче, Әл-галим – һәр нәрсәне белүче дигәнне аңлата. Дини әдәбиятта менә болай диелгән: *«Йа фәттах дип көн дә 489 тапкыр кабатлаучыга Аллаһы тәгалә бәрәкәт һәм яхшылыклар насыйп итәр, Йа Галим, дип көн дә 150 тапкыр кабатлаучы моңа кадәр үзе белмәгән серләрне белүгә ирешер».* (Тәрҗ. иск.)

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Холык-табигатьләрендә иҗтимагый эшчәнлеккә сәләте булган кешеләр исә бу тормыш өчен башка тормышларын фида итәләр, бу мәнфәгать өчен шәхси мәнфәгатьләреннән ваз кичәләр. Бөтен тоткарлыклар, кыенлыклар, бәла-казалар аларга чынбарлыкның чагылышы, яшәешнең бер өлеше булып тоела, кылычтан да, туп-мылтыктан да куркып калмыйлар. Иҗтимагый эшчәнлек юлында ирешелгән һәр уңыш – алар өчен җәннәт, ә иҗтимагый тормышсыз яшәү – алар өчен җәһәннәм.

Шәхси тормыш күп очракта аерым бер кешенең тормышы белән генә бәйле булып кала, алай булып калмаган очракта да, бары тик гаиләсендәге кешеләр, туган-тумачалары һәм якыннары белән чикләнә. Иҗтимагый тормыш исә, милләтнең, миллионлаган кешенең яшәеше дигән сүз. Җәмгыятькә хезмәт итүчеләр, димәк, миллионлаган кешегә хезмәт итәләр. Ләкин мондый төшенчәләрдә дә беркадәр чикләү бар, чөнки бу кешеләр үз милләтләре өчен тырышалар, хезмәтләренең җимешләре дә үз милләтләренә мирас булып кала. Кеше никадәр генә хөррият, кешелек һәм мәдәният хакына тырышса да, бөтен дөньяга рәхмәт яңгыры була алмый, чөнки бу сыйфат олуг пәйгамбәрләргә генә хас. Француз кешесеме, инглизме, гарәпме, татармы – кем генә булса да, үзенең милли, дини мәнфәгатьләреннән дә алгарак китә алмый. Мәсәлән, инглиз кешесе никадәр генә хөр булса да, француз булуны инглиз булудан өстен күрмәс. Немец кешесе, никадәр генә мәдәни булса да, Австрия мәнфәгате өчен Германия мәнфәгатен фида итә алмас, итсә дә бу аның самими, йөрәктән эшләнгән эше булмас иде.

Шул исәптән мин дә кайчандыр үз халкыма һәм динемә хезмәт итәргә дигән карарга килеп, инде менә 25-30 ел бөтен бәлаләргә күкрәк киереп каршы торам, бөтен кыенлыкларга түзәм. 30 елга якын һаман: «Милләтем! Милләтем!» – дидем, дим һәм диячәкмен. Минем динем Ислам дине, милләтем дә ислам. Атагыз Ибраһимның милләте. Сезне «мөселманнар» [үзләрен Аллаһыга тапшырганнар] дип атаган – Ул. (Хаҗ: 78).

Мин дә, табигый асылым кушканга, минем өчен иҗтимагый тормыш булган Исламга хезмәт итү юлына бастым, аның хакына бөтен авырлыкларга, юклыкларга түздем, шәхси тормышымны фида итеп, хак дин булган Ислам дине дошманнарына каршы тору өчен бөтен тиешле чараларны күрдем. Хак динебезне яклап чит ил һәм чит дин кешеләренә каршы телдән һәм язулы чыгышлар ясадым, күп тапкырлар кайбер Ислам тарафдарлары белән дә бәрелешергә туры килде. Ислам тарафдарлары гына түгел, Ислам голәмәсе исемен йөртүче кайберәүләр дә хәтта бик көчле басым ясап, мине, көферлек итә, диюгә кадәр барып җиткән вакытлары булды, төрле яла яктылар. Әмма, әлхәмделиллаһ, мин күңел төшенкелегенә бирелмәдем, киресенчә, юлымда нык тордым, илһам көчем артканнан-арта барды. Һәр очракта Коръәннең ап-ачык аятьләре буенча эш итәм, аларны үзем өчен юл күрсәтүче маяк итеп саныйм.

Менә хәзер дә, шул юлга һәм Аллаһы тәгаләнең Җир буйлап сәяхәт итегез... (ән-Нәмл – Кырмыска: 69, әл-Анкәбут – Үрмәкүч: 20, әр-Рум – Греклар: 42) дигән чакыруына буйсынып, мин озын бер сәяхәткә чыгарга карар бирдем. Алдан өстерәүчем дә, арттан этүчем дә юк. Бары тик тырышлык билбавы белән билемне будым да кулыма Аллаһының ярдәменә таяну таягын алдым.

Аллаһы тәгаләгә якынаюны тагын да арттыру фикереннән гыйбарәт булган изге теләгемә таянып, Аллаһының сүзләрен һәм Ислам фикерен дөньяга таратуга бәйле саф ният белән, мин, ватанымны, гаиләм һәм якыннарымны, берсеннән-берсе кечкенә балаларым – йөрәк пәрәләремне Аллаһыга әманәт итеп, «Йа Аллаһ!» дип юлга чыктым.

Коръән-е Кәрим, Җир буйлап сәяхәт итегез һәм күзәтегез... (ән-Нәмл:

69, әл-Анкәбут: 20, әр-Рум: 42) дип, без мөселманнарны күп тапкырлар сәяхәткә чакырса да, кызганыч, соңгы елларда мөселманнар арасыннан бу төр шөгыльгә кызыксыну күрсәткән кеше чыкмады, дип әйтергә мөмкин. Чыккан булса да, безгә билгеле түгел.

Мин элек-электән бер озак сәяхәт турында фикер йөртә идем, ләкин һәртөрле комачаулыклар һәм сүлпәнлек белән вакыт үтә торды. Моннан бишалты ел элек тә бу фикерне тормышка ашырырга теләп катгый карарга килеп караган идем. Ләкин ул вакытлар Русия эчендә башланып киткән инкыйлаб-революция халыклар арасында зур буталчыклык китереп чыгарды, урыны-урыны белән кабынып киткән уяныш хәрәкәтләренә сәбәп булды. Безнең мөселман кардәшләребез дә бу агымга кушылып киткәнгә, милләтнең киләчәге белән бәйле хәвефле уйларым, Русия мөселманнарының милли һәм дини хокукларын саклау кирәклеге, әлеге вазифаның изгелеге инде катгый рәвештә биргән ул сәяхәт турындагы карарымны бераз кичектереп торырга мәҗбүр итте.

Инкыйлаб кабыныр-кабынмас, безнең татарлар, иң башлап, һич тә икеләнмичә үзләренең сәяси асылларын билгеле иттеләр: Петербургта партияләр оеша гына башлаган иде, бездә дә «Мөселманнар иттифагы» исеме белән, бөтен Русия мөселманнарын берләштерүче аерым бер партия төзү карары кабул ителде һәм шул карар нигезендә партия оешты. Бу партиянең төп максаты, исеменнән дә аңлашылганча, мөселманнарның хокукларын саклаучы оешма булу иде. Мөселманнар ул елларда Русиядә инкыйлаб китереп чыгарган бер генә хәрәкәттән дә читтә калмадылар. Казанда хәтта шәһәрнең гомуми һәм башкарма идарәләре берара хөкүмәт кулыннан алынып, халык карамагына күчеп торды. Шулвакыт мөселманнар да үз мәхәлләләрен, ягъни Казан шәһәренең мөселманнарга караган өлешен үз идарәләренә алдылар һәм башкалар кебек нәкъ өч көн буе үзләре белән үзләре идарә иттеләр. Бойкот булган җирләрдә бойкот ясадылар. Бер генә хәрәкәттә дә бер генә мизгелгә дә аптырап калмадылар. Хәтта хөкүмәтнең ил белән иң кырыс идарә иткән елларында да, ике кешенең очрашып сөйләшеп торуы мөмкин булмаган көннәрдә дә, мөселманнар йөзләп кеше җыелышып, мөһим һәм кирәкле эшләр турында фикер алышалар иде. Ул гына да түгел, шактый санда нәшрият ачып, 25-30 исемдә газета чыгаруга да ирештеләр. Шуннан соң матбугат дөньясында бөтен мөселманнарның нәшрият хокуклары сүздә генә түгел, эштә саклана башлады.

Бу вакыйгалар артыннан ук Русия Думасы ачылды, анда да мөселманнар бердәм булып, сайлауларда дисеңме, I нче яки II нче Думаларда дисеңме – һәммәсендә дә армый-талмый хезмәт иттеләр, үзләренең милли һәм дини хакларын саклау өчен зур тырышлык куеп сәяси эшчәнлек күрсәттеләр.

Ләкин, кызганыч ки, Русидә золым караңгылыгы кабат офыкларны каплап алганнан соң, патша хөкүмәте кулындагы чикләнмәгән дәүләт идарәсе фанатизм дилбегәсен үз кулына алды, кеше һәм ватандаш хокукларын тояк астына салып изде: нәшриятларны бастылар, газеталарның күбесен яптылар, бик күп хезмәткәрне зинданга утырттылар.

Шул исәптән безнең дә гарәп һәм төрки телләрдә чыга торган газеталарыбыз ябылды, нәшриятыбыз кораллы гаскәрләр көче белән таркатылды. Без исә, «Үзен коткарган капитан (була)» әйтеменә таянып, күптәнге хыялыбыз булган сәяхәтне хәтерләдек һәм Төркестан тарафларына карап озын юлга чыктык.

Дәвамы бар

Текстны төрек теленнән
***Асия Рәхимова** тәрҗемә итте.* ■

عائله درسلری

Гаилә дәресләре*

Фәхрелбәнат Сөләймания

БАЛА

Бала – берсе ир, берсе хатын ике рәфикъның *(иптәшенең)* бергә кушылуы сәбәбеннән дөньяга килгән бер адәм мәхсуледер ки, дөньяга килүе берлә фани дөньяны бакый дөньядан аерыр яисә дөньядан үткәннәр урынына адәмнәрнең санын тутырыр.

Бала – өйләнүнең ядкяре, ир берлә хатын арасындагы мәхәббәтнең бер җанлы дәлиледер.

Бала – адәмнәр җәмгыятендә гаилә хисен, бергәләшеп вазифаны әда кыйлмак *(башкару)* фикерен уяндырып, җәмгыятьнең киләчәктә бәхетле булуына хидмәт итүче булган бер җанлы мәхсулдер.

Бала – тән вә гәүдә җәһәтеннән бик кечкенә, мәгънәви кыйммәт җәһәтеннән бик олуг бер нәрсәдер. Баланың тәрбиясе гаиләнең сәгадәтенә, адәмнәрдән җыелган мәдәни җәмгыятьнең бәхетлелегенә дә сәбәп булачагыннан, балаларга никадәр күп әһәмият бирмәк лязим идеген бу да белдерер. Балаларны тиешенчә тәрбия кыйлганнар вазифаларын тәмам әда кыйлган *(башкарган)* булырлар. Бәгъзе вәхши вә хайван аналарның карындагы балаларын төшереп тәләф *(харап)* кыйлганнары да бардыр. Бу хәл, Алланың бүләге булган бер вөҗүднең, бер гөнаһсыз балаларның бетерелүе булганнан, зур бер гөнаһтыр. Зур бер җанилык *(җинаятьчелек)* булып, низам *(канун)* берлә дә каты җәза кыйлынырга тиеш булган бер эштер.

Карындагы баласын гозер шәргыйсез төшергән бер ана – җанидыр, кеше үтерүчедер. Алла каршында газапка лаектыр. Бала төшерү өчен эшләнгән берничә зарарлы эшләр берлә аналарның үзләрен үзләре зәгыйфьләндерүләре бөтенләй җүләрлектер, гәүдәләрендә бала китерү мөмкин булмаслык бер гозерләре булмаганда, бала тудырасылары килмәгән, балалардан туйган аналар нәфрәт кыйлынырга лаеклардыр. Дөрест, бала тудырмак вә үстермәк читен вә мәшәкатьле бер эштер, ләкин инсаният галәменә бер вөҗүд кушмак зур бер һөнәр вә шәрәфтер.

Баланың бер мәгъсуманә көлүе бер ананың бөтен кайгыларын, мәшәкатьләрен оныттырырлык кадәр әсәрледер. **Балалар – гаиләнең зиннәте, ана вә аталарның зур күңел юанычыдыр.**

Балалар бик сөекле, бик файдалы бер вөҗүддерләр. Җәнаб хакның аналарга багышлаган хас шәфкате – баланы имезмәк – үстермәк өчен беренче сәбәптер. Махсус бер тавыш берлә «әннә» дигән бер баланың шул фәрештә шикелле хитабыннан әсәрләнми һич күңел булу мөмкин түгелдер. Шуның өчен балалар бик кыйммәтле йимештерләр. Ләкин аларга зиннәт бирер өчен, гүзәл тәрбия кыйлынулары шарттыр.

*Дәвамы. Ф.Сөләйманиянең 1913 елда Казанда дөнья күргән «Гаилә дәресләре: кызлар мәктәбе өчен» китабыннан аерым бүлекләр журналыбызның 2016 елгы 2, 3, 5 нче саннарында басылды.

Закир Пулат улы һәм Бибиәсма Һәдиятулла кызы гаиләсе. Фото Рәхимовлар архивыннан. Биектау районы

ТӘРБИЯ

Балаларның яхшы тәрбия кыйлынуы – гаилә тәрбиясенең нигезедер. **Гаилә тәрбиясе – гомуми тәрбиянең җаны, беренче сәбәпчеседер.** Болай булгач, балаларның тәрбиясе никадәр камил булса, гомуми тәрбия дә камилләнер. Адәмнәр яхшы сыйфатларны вә гүзәл хасыятьләрне кәсеп итү берлә камил булырлар. Адәмлек мәхлукларының хөрмәтлесе булу – гакыл вә фикер һәм дә фазыйләтләрне *(яхшы холыкларны)* кәсеп итү берләдер. Фикернең нуры вә инсаниятнең фазыйләте тәрбия аркасында заһир *(бар)* булыр.

Дөньяга килгән көннән бирле һичбер тәрбия күрмәгән бер адәмнең адәмлеге ялгыз исемендә генә калыр ки, моның кебиләр ни дөньяда вә ни ахирәттә һичбер сәгадәткә ирешми, мәхрүм булып, үкенечкә калырлар.

Бала – Аллаһы Тәгаләнең ата-анага тапшырган бер әманәте булганнан, аны тәрбия кыйлмак ата-анага тиешле булган бер бурычтыр. Дөньяга килгән бер баланың күңеле, имам Газали әйткәнчә: «Һәртөрле нәкышләрдән буш булган бер нәфис җәүһәрдер ки, аңар ни генә нәкыш кыйлынса да мөмкин вә кайсы гына якка тартсаң, анда тартылыр».

Болай булганда ата вә аналар балаларын яхшы тәрбия кыйлырга дин вә инсаният җәһәтеннән мәҗбүр булып, аларның бирәчәк тәрбияләреннән балалар бәхетле булган кеби, үзләре дә әҗер вә савапка ирешерләр. Балаларга яхшы холыкларны өйрәтмәк, аларны начар юлдашлардан сакламак, назлылыкка, артык зиннәтләргә вә рәхәтләнеп тик ятырга күңел куйдырмаслык, укыган вакытта гомерен буш үткәрергә өйрәтмәслек, һәртөрле хәлгә каршы торырлык сурәттә үстермәк, диндар, тугры, раст сүзле, кешегә изгелек теләүче, тырыш вә көчле ясамак, баланы бөтен мәгънәсе берлә инсан итмәк – әүвәл башта ата-анага лязим булган иң кирәкле бурычлардыр.

Бер адәм җаны вә тәне берлә, ягъни мәгънәви вә матди эшләре берлә ике кыйсем *(кисәк)* булганга күрә, бер баланың тәрбиядән тәмам өлеш алуы да фикер вә җанының да, тәненең дә төзеклеге берлә мөмкиндер. Димәк ки, тәрбия: җан вә тән тәрбиясе уларак, ике кыйсемгә бүленүе лязим килер. Тән тәрбиясеннән максуд – сыйххәт, җан тәрбиясеннән максуд – фазыйләть *(яхшы холык)* берлә сыйфатланудыр. Адәмлекнең фазыйләте дөнья вә ахирәттә бәхетле булырга сәбәп булган шәригать боерганча хәрәкәт кыйлу берлә хасил булыр.

Мәгънәви тәрбия: инсаният, инсаф вә гаделлек, гыйффәт, яхшы эшләргә мәхәббәт, начар эшләрдән сакланмак кеби хисләрне балаларның күңелләрендә

тудырачак рәвештә булырга кирәк. Ата-анага хидмәт, карендәшләргә хөрмәт, дуст-ишкә күркәм мөнәсәбәт күрсәтмәк, милләткә хидмәт, хезмәтчеләргә, хәтта хайваннарга каршы да яхшылык берлә хәрәкәтне инсанияткагыйдәләреннән дип белмәк – менә болар барсы да мәгънәви тәрбиянең кирәкле кыйсемнәреннәндер. Бу юлда тәрбия күргәннәрдән бөтен адәмнәр вә инсанияткаләме файда күрерләр.

***

Тәрбиянең ике кыйсеменә дә тоташ булган тагы бер тәрбия бардыр ки, моңа тәрбияи мәдәния исеме бирелер. Бу да мәдәни эшләрдә иң артык тәхсин кыйлынырга *(мактарга)* яраарлык бер хәрәкәтнең рәвешен күрсәтер.

Ләкин мәдәни тәрбия икенче мәгънәсе берлә аңлашмасын. Ягъни пакьлеккә, гыйффәткә хилаф булып, мәдәният йөзеннән лязим кеби күрсәтелгән бәгъзе *(кайбер)* начар эшләрдән сакланмак тиештер. Чын мәдәниятне, мәдәни тәрбияне ислам хакимнәре тәмамы берлә җыйгандыр. Исламият берлә мәдәният икесе игез туганнар булып, Алла каршында дин – исламияттер.

Тәндә сәламәтлек булмаса, гыйбадәт кыйлмак вә хидмәт мөмкин булмадыгы кеби, сыйхәте бозылган бер адәмнең җаны вә бөтен мәгънәвияте мөшкеллек вә газап эчендәдер. Болай булганда мәгънәви тәрбия таза, төпле бер матди тәрбиядән соң гына вөҗүдкә чыга алачагыннан, әүвәлдә баланың тәнен, икенче җанын тәрбия кыйлмак лязим килер. Ягъни әүвәл тән тәрбиясен тәмам кыйлып, бу таза нигез өстенә инсаниятнең нык бинасы булган мәгънәви тәрбияне салырга кирәк. Тәрбия, бишектән башланып, кабердә тәмамланыр. Ләкин бик нык тәрбиянең әүвәлге вакыты балаларда оят әсәрләре күренә башлаган вакыттыр ки, яхшыны яманнан аера башлауларының галәмәте булган оят күренә башлагач та, ата-ана тәрбиягә бик чыннан керешерләр. **Бер балада оялу әсәренең күренүе гакылының нуры әүвәлге шәүләсен күрсәтә башлавы димәктер.** Мисал: алты айлык бала бер дә курыкмый кулын утка тыга алыр, чөнки анда һәнүз *(әле дә)* аеру хисе уянмагандыр. Шундый баланың үз-үзеннән бәгъзе начар эшләргә оялып, аннан саклана башлавы, үзенең кечкенә гакылынча яхшы-яманны аера башлавы булып, тәрбиянең иң артык әсир итә торган вакыты да бу вакыттыр. Бу вакытта гадәтләнгән эшләр һич үзгәрми торган бер гадәт булып калыр.

Ислам галимнәре вә хакимнәренең васыятьләренчә, тәрбиядән саналган янә бер эш бардыр ки, ул да баланы имезеп үстерә торган ананың яки тәрбиячесенең хәләл ашаучы вә изге хатын булуыдыр. **Хәрәмнән хасил булган сөттә бәрәкәт булмаган кеби, тәннең камыры мондый хәрәм нәрсә берлә әчетелгән балаларның бозыклыклар кыйлучан булуы билгеле вә тәҗрибәләр берлә заһирдер.**

Тән тәрбиясе хакында лязим булган тәдбирләр хифзыссыйхәт *(сәламәтлек)* өчен тырышмактыр. Ләкин шуны да онытмаска тиештер ки, баланың тән тәрбиясе берлә бергә әхлак тәрбиясе дә акрынлап бармак лязимдер. Баланың дөньяга килгән көненнән әүвәлге тәрбиягә керә торган заманына кадәр гүзәл инсаният хисләре ата-ана тарафыннан киңәйтелергә тиештер.

МАТДИ ТӘРБИЯ

Матди тәрбия кыйсеменнән шуны да күзгә алмак лязимдер ки, балалар ашарга бик хирыс булалар. Ни тапсалар, шуны ашамакчы булып, ашалмый торган нәрсәләргә кадәр агызларына китерәләр. Баланың бу комсызлыгын бетерер өчен, уртача ашауга өйрәтеп, хәтта соңга табарак кайсы вакытта коры икмәк ашарга да гадәтләндермәк берлә уртача бер тереклеккә иярләндермәк лязим булып, кием-салым тугрысында да уртача тормышка гадәтләндермәк – ата-ана берлә тәрбиячеләрнең бурычы-

дыр. Балам ашасын, тизрәк үссен, диеп, вакытлы-вакытсыз ашатмак, кулына төрле-төрле зарарлы нәрсәләр бирмәк – аны комсызлыкка өйрәтмәк, балага мәрхәмәт түгел, зарардыр. Аналарның бу тугрыда артык шәфкатеннән саклаулары бик лязимдер, чөнки бу рәвештә үстерелгән балалар зәгыйфь, сырхау булып, аяклары ип, корсаклар гөб, башлары тубал кеби булып, биш-алты яшькә кадәр аякларында йөри алмый утырырлар. Ахырында зәгыйфь вә начар булып, бил сөякләре имгәнгән, бөкреләре чыккан булырлар. Боларның ни үзләреннән вә ни дә мәйданга китергән балаларыннан файда көтелмәс.

Балаларга өсте-өстенә киемнәр кидермәк зарарлыдыр. Баланы суыкка, эссегә, һәр михнәт вә мәшәкатьләргә алдан яхшы гына иyләндермәк лязимдер. Буыннарының хәрәкәтен йиңеләйтер вә тәннәренең куәтен арттырыр өчен, йөгермәк, сикермәк вә уйнамак кеби хәрәкәтләрдән тыймый, мондый файдалы хәрәкәтләрдән тәрбия даирәсендә файдалануларына тырышмак тиештер.

Тик утырырга өйрәнгән балалар эшлексез вә ялкау булып үсәрләр. Тәннең яхшы, таза булып үсүе өчен тар киемнәрдән, кысып бәйләүләрдән сакланмак лязимдер. Балаларның тән тәрбияләре тугрысында иң артык кирәк нәрсә – саф һава, яхшы су, вакытлы вә уртача ашау, хифзыссыйхәткә муафыйк уен, киң кием берлә һәр эшне тәртип берлә вакытында кыйлырга соң дәрәҗәдә тырышмактыр ки, милләт вә мәмләкәтемезгә яхшы вә гүзәл хидмәтләр итә алырлык вә үзләре дә бәхетле була алырлык сурәттә куәтле гәүдәле балалар мәйданга чыга алсын.

ГОМУМИ СУРӘТТӘ БАЛАЛАРНЫ ТӘРБИЯ КЫЙЛМАК ЫСУЛЫ

Бер бала кечкенәдән ни рәвешле тәрбия кыйлынган булса, зурайгач та шул рәвешле тәбиягә гадәтләнер. Шуның өчен, тәрбиянең нигезе булган әүвәлге тәрбия бигрәк кирәкле вә бик артык дикъкать ителергә тиешле булган эшләрдәндер. Тәрбиясе өскә алынган бер баланың табигать вә гәүдәсе берлә истигъдад *(сәләт)* вә зирәклеге күзгә алынмак вә бер тәрбия кыйлучыга тапшырырга мәҗбүр булынса, тәрбия кыйлучының бала берлә бер мәзһәбтә, сау вә куәтле вә һәрбер җәһәттән гүзәл вә мәгълүматлы булуын күзәтмәк зур шарттыр.

Мисал: ачучан бер баланы башкаларга караганда артыграк йомшаклык берлә тәрбия кыйлып, ачучанлыгын арттырмаска, аңра сыман балага көче йитмәслек нәрсәләрне өйрәтәм дип кысмаска кирәк. Истигъдад вә кабилиятенә *(аңлый алу сәләтенә)* карап баланың җанын вә вөҗданын нурландырмага, фикерен зиннәтләмәгә хидмәт итмәкнең кирәклеген ата-ана вә бөтен тәрбиячеләр һәрнәрсәдән әүвәл күзгә алмаклары лязимдер.

Тәрбия кыйлучылар баладагы әхлакның көзгесе булдыкларыннан, боларның күркәм холыклы вә инсаниятлелеләрен сайламак лязимдер. Хәлфә никадәр мәгълүматлы булса да, холкы начар булса, баланың холкын бозудан башка һичбер нәрсәгә ярамас. Христиан мөрәббияләр *(тәрбиячеләр)*, билгеле, балаларны үзләренең дини хисләренә күрә тәрбия кыйлачакларыннан, баланың дини булган гүзәл хисе бозылмасын өчен, ислам мөрәббияләренә тапшырмак мәслихәттер. **Ана телен вә диненең хөкемнәрен өйрәнмәс борын, балаларга ят телләрне өйрәтмәк вә укытмак бер гүзәл нәтиҗә чыгара алмас.** Аларның кечкенә вә һәнүз үсеп бетмәгән миләре мондый артык нәрсәләрне сыйдыра алмаганга күрә, вакытыннан әүвәл арыр. Баштарак бераз тәрәккый әсәре күренсә дә, бара-бара зирәклекләре сүнгән кеби бер хәлгә килер. Шуның өчен балаларга, әүвәл үз телләрен вә дини телен белдермәк, башка телләрне аннан соң өйрәтмәк лязимдер. Ислам дине ят телләрне өйрәнүдән тыймыйдыр. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ИМАН ҺӘМ ИҖАТ

Фоат Галимуллин

Замандашыбыз Разил Вәлиев турында җыеп кына сүз әйтү җиңел эш түгел. Моның өчен аның үзе кебек, яшәешебезнең төрле өлкәләрен биш бармагың кебек белергә, шул даирәләрдә кайнарга, ул кичергәннәрне күңелең белән кичерергә кирәк. Ул бүгенге көндә сәяси, дәүләти эшчәнлеге өстенә, иҗаты белән дә халык күңелендә урын алган шагыйрь, прозаик, драматург, публицист. Разил Вәлиев иҗатын сәяси эшчәнлегеннән, ә сәяси эшчәнлеген иҗатыннан аерып карап булмыйдыр. Аның өчен кайсы – беренчел, кайсы икенчел икәнен аерып билгеләү дә кыен.

Шулай да, кеше дөньяга сәясәтче булып аваз салмый, бәлки, билгеле бер вазгыятьләрдә аңа шушы йөкне җилкәсенә алырга туры килә. Әмма, бик сирәк кенә булса да, кеше шагыйрь булып туа.

Якын элгәреләребез дөньяны аңлауда һәм аңлатуда үзләренең ата-бабаларының карашларын төп-төгәл кабатламаган кебек, аларның балалары да күңел дөньялары, яшәеш кыйммәтләрен бәяләү үзенчәлекләре белән шактый нык аерыла. Буын белән буын алышыну гади күренеш кенә түгел, алар рухият мәйданына үзләре белән яшәү фәлсәфәсенең яңа төсмерләрен алып килә. Ләкин нигез нык саклана. Ягъни әдәби үсештәге яңа тенденцияләр сүз сәнгатенең гомуми кануннарыннан әллә ни читкә китә алмый. Бер сүз белән әйткәндә, әдәби буыннар арасындагы бәйләнешләр соңгыларының алдагыларны инкяр итүгә китерергә тиеш түгел.

Мондый уйлануларның сәбәбе бар. Татар әдәбиятының олы талантларыннан торган шактый тыгыз саф утызынчы еллардагы фаҗигаләр нәтиҗәсендә, аннан соң Бөек Ватан сугышы кырларында нык сирәкләнде, кырыгынчы еллар ахыры – илленче еллар башында тагын бер тапкыр «Карлаг»лар, «Комилаг»лар аша узучылар булды. Әмма алтмышынчы еллар башында әдәбиятыбыз тагын тернәкләнеп, көчәеп китте. Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, М.Галәү, Ш.Усманов кебек гаять талантлы әдипләребезнең мирасы кире кайту, М.Җәлил шигырьләренең дөнья мәйданында яңгыраш алуы моңа нык этәргеч бирде. Бу эстафетаны К.Нәҗми, Г.Бәширов, Г.Әпсәләмов, А.Расих, Ф.Хөсни, Х.Туфан, С.Хәким, И.Юзеев кебек корифейларыбыз алга алып китте. Шул ук вакытта әдәбиятның мондый иңле үсеше бары тик калыпланган традицияләр буенча гына бара алмый иде. Тарихи барыш шуны күрсәтә: һәр иҗтимагый ихтыяҗ аны тормышка ашыручыларны да тудыра. В.Маяковскийның «время родило», Һ.Такташның «гасырлар тудырды» дигән атаклы гыйбарәләрен генә искә төшерик. Әйе, шушы «кирәклек» Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, Р.Мингалим, Г.Рәхимнәр буынын тудырды. Аннан соң икенче көчле дулкын М.Әгъләмов, Зөлфәт, М.Галиев, Р.Миңнулин, Х.Әюпләрне әдәбият мохите ярына чыгарды. Алар арасында Разил Вәлиев тә үзенең ныклы урынын алды. Алтмышынчы еллар башында аның мәйданга килүе яңа

Р.ВӘЛИЕВ
МОАБИТ ДӘФТӘРЛӘРЕ

Фикердәшләр, мәсләктәшләр, депутатлар. Разил Вәлиев Фәндәс Сафиуллин (сулда) һәм Марат Мөлеков белән. 1990 нче еллар

бер исемнең пәйда булуы гына түгел иде. Разил Вәлиев – исеме белән дә, җисеме белән дә әдәбиятыбызга яңа сулыш өрүче, шул елларда бераз салмаклана төшкән әдәби хәрәкәткә көч өстәп җибәрүче булырлык яңа бер күренеш тә булды. Аның менә бу шигъри юллары ук үз алдына зур максатлар куйган, пәһлевандай көчкә ия егетне күз алдына китерә:

Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә
Акыл күпме җавап эзләгән...
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм.

Әдәбиятка чын-чынлап, җиң сызганып тир түгәргә, аның изге даирәсендә гомерлеккә калырга теләп килгән яшь кеше генә шулай дип әйтә ала. Моны Һ.Такташның шигърияттәге үз урынын билгеләргә омтылуы белән тиңләштерергә мөмкин:

Мин яралдым серле моңнарым белән
бар дөньяны
Еглатырга. Әйе, миндә көчле
Байроннар җаны!

Шулай да Разил Вәлиевнең шигърияте, Ташлык авылы чишмәсе суыдай, тыныч кына гөрелтене хәтерләтеп башланды:

Төн карасына каләмемне манып
Хатлар язам,
Карам беткәнче язам...
Ә син
шуны да белмисең,
йөрәгеңне кулларыңа тотып
килмисең.

Шагыйрь тормышындагы һәр мизгел, кайнар хисләр белән сугарылып, шигырьгә көчә торды. Тынгысыз күңеле аны Мәскәүнең Әдәбият институтына алып килде. Ә анда татарның рухи халәтенә параллель булырлык истәлекләр, күренешләр бетәсе түгел. Яшь шагыйрь аларны хыялында үзе дә тудыра. Мәсәлән, Останкино телевидение корылмасы белән халкыбызның ханбикәсе арасында бәйләнеш табу гайре табигый дип кабул ителми:

Мәскәү, Мәскәү...
Монда кем аңласын мине,
Кем соң минем көйне көйләсен?!
Кулларымны сузып аста көтәм...
Ыргыт миңа, ыргыт кочагыма
Останкино Сөембикәсен!

Мәскәүдә яшәгән биш ел эчендә язган шигъри әсәрләре Ташлык гөрләвегенә шактый көчле агым булып килеп өстәлә. Монда кичергәннәр, фикер киңлеге мохитендә булу шигырьгә көчми каламы соң?

Без дала балаларына
Казанда юллар тармы?
Белмим, белмим... Мин Мәскәүнең
Миллионынчы татары...

Үзеңне әнә шундый зур гаиләнең бер әгъзасы итеп тою, сүз дә юк, әйткәннәреңнең интонациясенә дә көч, ышанычлылык төсмерләре өсти.

Бу шигъри гөрләвеккә килеп кушылган тагын бер саф сулы чишмә агымы бар. Ул да булса, башкаладан торып туган авылын, әнкәсен сагыну хисләренең табигый агышы. Сагыну тулы хатлар кайчакта шигырь белән дә языла:

Ниләр языйм, әнкәй, ни җибәрим? –
Бар булганым – кара һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...
Шигырьләтә генә җибәрәм.

Менә шулай сак кына, тыныч кына ага башлаган шигъри агым тора-бара киң дәрьяга килеп чыга...

Разил Вәлиев хәзерге татар шигърияттен һәм фикер, һәм форма, һәм интонация төрлелеге ягыннан баетуда күкрәк киереп юл ярып бара. Ул моны элгәреләре алдында җаваплылык тоеп башкара. Күпме шагыйрьләребез: Шамун Фидаи, Шәехзадә Бабич, Давыт Гобәйди, аннары Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәйләрнең шигъри авазы ярты юлда тукталып калган. Яшь шагыйрь үзен алар алдында да бурычлы саный:

Үткәннәргә таба йөзне борып,
Күп таптармын әле бу җирне.
...Үземнекен түгел,
Язам әле
Шагыйрь язмый калган шигырьне.

Биредә күренекле шагыйребез Шәйхи Маннурның яшь буын шагыйрьләргә васыять итеп язган юллары искә төшә:

Агым суның язда ярсуын
Күреп үскән яшь дус, яшь буын,
Биреп барлык йөрәк җылыңны,
Син дәвам ит инде җырымны,
Син җырлап бар инде чорыңны.

Разил Вәлиев буыны шагыйрьләренә дә чорның шактый катлаулысы туры килде. (Хәер, кешелек җәмгыяте яшәешенең җиңел дәверләре буламы икән?) Өлкән шагыйрьнең васыятенә тугры калып, ул да үз заманы вазгыятенең шигъри елъязмасын армый-талмый тудыра килә.

Аның шигъриятенең зур бер кишәрлеге – әлбәттә, җыр тармагындагы табышлары. Р.Вәлиев иҗатының ошбу юнәлеше турында махсус тикшеренү дә таләп ителәдер. Бу уңайдан шунысына гына игътибар итәсе килә: шагыйрьнең күңелендә туган ул җырлар композиторларыбызны илһамландырган икән, бу инде үзе үк әлеге әсәрләрнең җитлеккәнлеге, сәнгатьчә камиллеге турында сөйли. Алар арасында СССРның халык артисты Рөстәм Яхин, РСФСРның М.Глинка исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фасил Әхмәтов, Г.Тукай бүләге лауреатлары Резеда Ахиярова, Шамил Тимербулатов, Татарстан композиторлар берлеге рәисе, авангард стилендә иҗат ителгән әсәрләре белән халыкара мәйданда танылган Рәшит Кәлимуллин, шагыйрьнең иң якын иҗатташ дусларыннан берсе, инде мәрхүм Рәшит Абдуллин һәм башка бик күп талантлы сәнгатькярләрнең булуы үзе бер олы бәя буларак кабул ителә.

Без еш кына классикларыбызның теге яки бу хезмәтләренә таң калып сөйләшәбез. М.Җәлил унөч яшендә «Бәхет» шигырен язган һәм үзенең бөтен киләчәген шул әсәрендә әйтеп бирерлек пәйгамбәрлеккә ия булган, дибез. Һ.Такташ егерме бер яшендә «Җир уллары трагедиясе» дигән даһи әсәрен биргән, Фәтхи Бурнаш унтугыз яшендә әдәбиятыбызда беркайчан да кыйммәтен җуймаслык «Таһир-Зөһрә» трагедиясен калдырган. Ә менә безнең арада йөргән, көндәлек тормышта бергә әвәрә килгән замандашларыбызга мондый бәя бирүне тыйнаксызлыкка саныйбыз. Шул исәптән Р.Вәлиевкә дә бу җәһәттән хуплау сүзе әйтү тиештер. Уйлап карасаң, егерме бер яшьтә «Эт кояшы» повестен язган егет бит ул! Әсәрнең исеме генә дә сагайта. Әйтергә кирәк, кыю язылган. Күңеле белән хөрлеккә омтылган, тормышта матурлык кына тантана итүен теләгән бу төп образның исеме дә нәкъ менә

Разил Вәлиев һәм академик Миркасыйм Госманов

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ,
тарих фәннәре докторы, академик:

«Ходай Тәгалә Разил Вәлиевкә талант-сәләтнең төрлесеннән дә мул итеп биргән; әйтик, якты моң белән өретелгән нечкә хисне дә, омтылыш-теләкләрендә ихласлыкны да, мәсьәләләрне тамырыннан ача ала торган үткен акылны да, уйлаган саен яңа кырлары белән ялтырый торган мәгънәле фикерне дә, вакыйга-күренешләрнең фаҗигале якларын да тормышчан дөрес, шул ук вакытта гап-гади һәм көлкелерәк хәлендә күрә, күрсәтә торган очлы күзне дә, бер үк вакытта мохтаҗны юатуга сәләтле киң күңеллелекне дә бергә җыеп, бергә өеп биргән».

Ирек булырга тиеш иде. Авторның аны башкача атавы, ничектер, сәер яңгырар иде сыман. Дөрес, ирек дигәндә, бу егет әлеге төшенчәдә әллә нинди югары иҗтимагый-сәяси идеалларны күздә тотудан ерак тора. Ул бары тик шәхси омтылышларында гына ирекле булырга омтыла. Шуңа күрә башкаларның үз дигәнчә яшәүгә ирешүләрен хуплау – аның табигый халәте. Бер үк вакытта кыерсытылганнарны аңларга тырышу, шул аңлау көченең тора-бара тирәнрәк хис-кичерешләргә алып килүен табигый эволюциядә күрсәтә алуы – яшь авторның үз заманы өчен зур казанышы иде.

Әсәрнең тагын бер яңалыгы – төп персонажның ул еллар өчен гадәти булмавы. Игътибар иткәнсездер, без аны хәтта герой дип тә атамыйбыз. Чөнки аны әдәбиятта моңа кадәр герой дип аталып килгәннәр рәтенә куеп булмый, ул социалистик реализм таләпләренә бөтенләй туры килми! Әлбәттә, алтмышынчы еллар ахыры шартларында мондый әсәрнең басылып чыгуына өмет итәргә ярамый иде. Ул шулай булды да. Яшь язучы өчен дөньяга чыкмасын белә торып шундый әсәр иҗат итү үзе бер фидакарьлек булгандыр, дип карарга кирәк.

Шул рәвешле, Разил Исмәгыйль улының акыл камиллеген раслаучы күрсәткеч – яшь чагыннан ук гомумкешелек фәлсәфәсен иҗатына нигез итеп алуы, аның бу сукмакка мөстәкыйль килүе. Байтак еллар үткәч, аның мәсләктәше булып әверелгән Туфан Миңнуллинның бер сөйләшеп утырганда әйткән сүзләре хәтердә сакланган. Өлкән драматургларыбызның берсе турында сүз чыккач, ул болай дигән иде:

– Үз вакытында әсәрләре уйналды, басылды, зурладылар, иҗатын мактадылар. Әмма ул Дәрдемәнднең «Сөт калыр, Ватан китәр» дигән сүзләренең мәгънәсенә үз вакытында төшенмәгән. Хәер, ул аларны ничек бәяләсен? Ком-

мунистлар идеологиясе Дәрдемәнд исемен телгә алудан да тайчанды. Шунысы кызганыч: хәзер бу драматургыбызның бер генә әсәрен дә театрлар үз репертуарларына алмый. Димәк, алар хәзерге көн өчен ят. Бу – иҗат кешесе өчен фаҗига.

Р.Вәлиев остазы Т.Миңнуллин белән күп еллар янәшә барды. Сөйләшүләре, фикер алышулары бихисап булгандыр. Дөресен әйткәндә, Туфан Абдулла улы аның үзеннән дә бик күпне өйрәнде дип беләм. Мин, республика парламентында байтак еллар алар янәшәсендә торган кеше буларак, моның шулай икәнлеген үз күзләрем белән күрдем. Р.Вәлиев тә, өлкән каләмдәше кебек үк, иҗатының идеологик ягын гомумкешелек карашларына нигезләве сәбәпле, әсәрләренең гомерен үз кулы белән чикләүдән ерак торды. Хәтта шул көннәр мохите таләп иткән мәүзугларга мөрәҗәгать иткәндә дә яшь автор төп тормыш принципларына тугры калды.

Әйтик, җитмешенче еллар ахырында ул «Яшисе килә» повестен язды. Әсәр, хәрби өйрәнүләр вакытында боҗрасы алынган гранатаны ыргыту өчен кешеләр булмаган буш урын тапмыйча, үз гомере бәрабәренә башкаларны исән калдырып һәлак булган Түбән Кама егете Рифкать Миргазизов батырлыгы турында. Берәү булса, бу батыр рухлы егетне комсомол тәрбиясе җимеше дип, холкы формалашуны җыелышлар, утырышлар кебек рәсми хәл-әхвәлләр чолганышында сурәтләр иде. Р.Вәлиев алай итми. Чөнки ул яхшы белә: безнең халкыбызның үз милли педагогикасы да илеңә, халкыңа, милләтеңә тугрылык саклау, алар бәрабәренә батырлык кылу сыйфатларын тәрбияли торган, гасырлар дәвамында сыналган табигый системаны тәшкил итә. Р.Вәлиев әдәби каһарманы Рифкатьнең батырлыкка килү эволюциясен нәкъ менә шуңа нигезләп күрсәтеп бара да.

Р.Вәлиевнең тормышчан җирлектә әдәби әсәр тудыру хасияте турында уйланганда, үзеннән-үзе, ераграк дәверләрдәге классикларыбыз иҗаты белән параллель үткәрү теләге дә барлыкка килә. Г.Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр» әсәрен язганда таянган тормыш фактлары берәр талантсызрак каләм иясе кулына килеп керсә, аларны бәян итүдән бары тик идеологик схема гына килеп чыгар иде. Әмма бөек сүз рәссамыбыз шул нигездә әнә нинди сәнгатьчә камил әсәр тудырган! Р.Вәлиевнең «Яшисе килә» повестен язу тәҗрибәсе дә Г.Ибраһимовныкына охшаш. Минем үземә бу әсәр турында матбугатта беренче булып сүз әйтү насыйп булды. Повесть 1982 елда Республикабызның М.Җәлил исемендәге яшьләр премиясенә лаек булды, шулай итеп, аның һичшиксез уңышлы әсәр икәнлеге рәсми даирәләр тарафыннан да танылды. Гәрчә ул, алдан әйтелгәнчә, «өстәгеләр» көткән үлчәмнәргә бик сыешып бетмәсә дә.

Юкса, безнең әдәбият башында утырган түрәләр рәсми даирәләр ягына салулап китәргә генә тора. Әйтик, Р.Вәлиевнең туган авылына якын гына атом электр станциясе салына башлагач, биредә хәтта әдәби постлар булдырылды, шушы гамәлне кирәкле дип халык күзенә төртүчеләр дә табылды. Әмма халкыбыз акыллырак булып чыкты. Бүгенге генә түгел, киләчәк буыннарга да куркыныч янап торачак корылманы торгызу туктатылды. Иделе, Чулманы, Нократы булган, нефте, исәбенә дә чыга алмаслык күләмдә битум запаслары тулып яткан республикабызда энергия алуның табигый мөмкинлекләре дә зур. Моның өчен куенда Рифкать Миргазизовның гомерен өзгән граната-шартлагыч кебек куркынычны асрау ихтыяҗы юк иде. Шөкер, Р.Вәлиевне әлеге төзелешне хуплаучылар арасында күрмәдек.

Бездә КамАЗ төзелешенә багышлап сурәтләнгән кеше образларын технологик проблемалар, җыелыш-утырышлар каплап киткән әсәрләр дә язылды. Әмма аларны күпчелек очракта Чаллы төзелеше мәйданына читтән карап кына, андагы колачлылыкка ерактан хәйран калып күзәткән каләмдәшләр

Дуслар.
Разил Вәлиев,
Туфан Миңнуллин

ТУФАН МИҢНУЛЛИН,
драматург, Татарстанның халык язучысы:

«Разил әсәрләрендә мине сөендерә торган чагыштырулар, сурәтләүләр, тапкыр сүзләр еш очрый. «Урамнарга шыплап март тулган», «Оҗмах бирәм димим сиңа, тәмугка да кертмәмен», «Яз гөлләрен күкрәгенә тезеп, тәрәзәләр әнә төш күрә», «Мин бүген марка ябыштырмыйча почта әрҗәсенә ташланган хат кебек», «Күкнең утлы күзе җир өстенә тамып төште – йолдыз атылды» кебек гыйбарәләрне укып, чын әдәбият белән очрашкандай куанасың».

иҗат итте. Шуңа күрә алар вакыт сынавын үтә алмады. Р.Вәлиев исә гомеренең берничә елын шушы мохиттә уздырды, алай гына да түгел, биредәге хәл ителәсе мәсьәләләр белән әвәрә килде. Шуның өчен дә аның «Мирас» романы җирле хәл-әхвәлләр даирәсендәге кешеләрнең эчке дөньяларын, табигый халәтләрен ачуы белән аерылып торды.

Авторны борчыган мәсьәләләр зуррак: яңа каланы бу җирдә ничәмә-ничә йөз еллар элек барлыкка килгән авылларны, зиратларны бетермичә генә күтәреп булмый идеме соң? Хәер, ничек булсын! Аның генераль планын бирегә рәтләп килеп тә карамаган Мәскәү архитекторлары сызган бит. Ә менә халыкның күңел дөньясын чагылдырган, рухи мирас булып әверелгән кыйммәтләрне җимерү бернинди план-сызымсыз алып барыла. Зыятдин абзыйның гомер иткән атавыннан шәһәргә күчерелүе дә шул рухи мирасның һәлакәте буларак кабул ителә. Бу аз да түгел, күп тә түгел – Атлантиданың су астына китүе белән бер. Атлантида табигый бәла-каза нәтиҗәсе булса, Зыятдин бабай атавы – халкыбыз рухының бер бизәге – аңлы кешеләр тарафыннан харап ителә. Бөтен тирә як моңа кадәр шушындагы тегермәндә он тарттырып, ярма ярдырып, җисми һәм рухи яшәү көче алган булса, биредә барлыкка киләчәк «Иске тегермән» ресторанында исә нәрсәләр булачагын күз алдына китерү кыен түгел. «Каенсар», «Акчишмә», «Кушнарат» дип авыллар исеме белән аталган күпкатлы йортлар барлыкка килү генә бу бушлыкны тутыра алмый.

Күрәбез, Р.Вәлиев иҗатында да, сәясәт өлкәсендәге кебек үк, һәр мәсьәләгә халык һәм дәүләт күзлегеннән карый, алар мәнфәгатеннән чыгып эш итә. Чөнки кеше – бербөтен. Ул тормышта

Каләмдәшләр.
Разил Вәлиев,
Фоат Садриев

– бер, иҗатта икенче төрле була алмый.

Тормыш мәктәбе Разил Вәлиевкә гомер буена җитәрлек сабак бирә, бары тик күңел төпкелләрендә бөреләнгән табигый уй-фикер һәм хисләрдән торган иҗат җимешләре генә халкың өчен кирәкле һәм файдалы булуын аңлауга китерә. Шуннан башка чын, ихлас иҗат була алмый. Димәк, И.Гаспралычарак әйткәндә, уйда, эштә, иҗатта берлек кирәк. Иҗатың исә тормыштагы үз адымнарың белән ныгытылган булырга тиеш. Әмма Разил Вәлиев ясаган адымнарның күбесе гадәти түгел. Үз теләгең белән Әфган сугышы эченә барып кереп, андагы якташлар белән очрашулар, ут чолганышында калулар, Чечня һәм Ингушетиядәге хәлләрне үз күзе белән күреп язу өчен иң хәтәр урыннарда йөрүләр... Мондый тәвәккәл адымнар ясарга сәләтле шәхес бары тик соклану һәм хөрмәт хисе генә уята. Халкыбыз аны Татарстан Милли китапханәсе эшчәнлеген моңа кадәр күрелмәгән мәйданнарга чыгаруы, күп еллар буена Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының рәисе буларак, парламентта халык мәнфәгатьләрен яклап эш алып баруы өчен дә ярата, хөрмәт итә. Билгеле ки, Дәүләт Советында бу урын иң кайнары, халык күз алдында

ФОАТ САДРИЕВ,
Татарстанның халык язучысы:

«Без Разил Вәлиевнең тагын бер күркәм сыйфатын яратабыз. Инде чирек гасыр югары кәнәфидә утырса да, аңа һавалану, төкселек кебек ваклыклар ябышмады. Юкса, әзрәк күтәрелә башласа, кайберәүләрне ул күңелсез нәрсәләр тигәнәк урынына сырып ала. Күрәсең, сизгер йөрәк, милләт мәнфәгатьләре белән тоташ яну аны андый ваклыклардан саклады. Язучылар җыелышларында, тантаналы кичәләрдә, башка мәдәни чараларда, аңа югары дәрәҗәсен әйтеп сүз бирсәләр дә, ул язучы, гади тамашачы буларак чыгыш ясый».

булганы, милләтебезнең киләчәк язмышы күп яктан аның эшчәнлегенә бәйле. Монда аңа ил агасы булырга, кыен хәлләрдән чыгу өчен акыл, төплелек, иман һәм иң мөһиме – халык ышанычына ия булу кирәк. Разил Исмәгыйль улында бу сыйфатларның барысы да бар. Ул алга таба да иҗатта, башка төрле иҗтимагый-сәяси эшчәнлектә дә үзе булып калыр, укучыларына һәм туган халкына кирәклеген тою аны зур эшләргә илһамландырып торыр. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Лаек булса кеше изге догага,
Гүзәл тормыш аңа теге дөньяда.

Кирәк җир өстендә, кирәк — астында
Сиңа игелек бар изге атыңнан.

Үзең үлсәң дә син, изге ат алсаң,
Җаныңа рәхәтлек, ат мәңге калса.

Рәгыятьнең[1], күр, өч хакы бар синдә
(Бу хакларны аңа көттерми үтә):

Беренче — илеңдә саф булсаң көмеш,
Гыярын[2] тикшерт, и, акылдар, бик еш.

Икенче — халыкка гадел сәясәт:
Рәнҗеттермә берсен береннән, күзәт.

Өченче — имин тот сәүдә юлларын,
Карак, юлбасардан арулат аны.

Үтәсәң син әгәр халыкның хаккын,
Үзеңә дә таләп куй, и, илбик — хаким.

Рәгыятькә синең өч хакың ачык:
Шуны аңлат аңа, колагын ачып.

Бере — ярлыгыңа ул хөрмәт итсен,
Ни булса да, «шулай кирәктер», дисен.

Икенче — кермәсен казна хакына,
Түләген түләсен үз вакытына.

Өченче — дошманны – дошман, дисеннәр,
Вә син кемне сөйсәң, шуны сөйсеннәр.

Ничек үтәсәң син халкыңның хаккын,
Шулай үтиячәк хакыңны халкың.

Шулай булсын илбик, эш йөртсен юллы,
Рәгыять тә лаек булсын, и, олуг.

Иге холкын белсә халкы ханының,
Тыныч булыр илбик һәм артыр даны.

Бәхетең билгеле шулай булганда,
Сиңа ике өлеш ике дөньяда.

Шуннан соң белкәләр, галимнәр килеп,
Халыкка җиткерә бирсеннәр белем.

Әйткәнчә, көчле кул мөхтәсипләр бар,
Явызлыкны илне гизеп тыйсыннар.

Сатучы күзәтсен әманәтләрен,
Кылып торсын остаз нәсыйхәтләрен.

Игенче игенгә ирекле булсын,
Вә терлек асраучы тереклек кылсын.

Кирәк җир өстендә, кирәк — астында
Сиңа игелек бар изге атыңнан.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.

[1] Рәгыять — подданные.

[2] Гыяр — металл (алтын, көмеш һ.б.) акчаның составы, сафлык дәрәҗәсе.

Ират калды —тугры хезмәтенә ул,
Бүреләргә каршы ясар йортавыл[3].

Сөендер боларны — әйбер җитештер,
Күзәт һәм азат ит бүтән бер эштин.

Файдасына күрә гадел түләп тор,
Баектыр әйбергә һәм көчен арттыр.

Әзерлә дошманга, бүрегә корал,
Кардәшкә — үз, яуга үлем шул була.

Ачылыр, чишелер шулчак бар эшең,
Сөзелер, сафланыр бөтен тормышың.

Сиңа булыр ике дөнья билгесе,
Ходай сөеклесе үзең булгучы.

Тугрылык ул тугры булу һәр көнне,
Теләккә җиткерер тугрылык сине.

Сөяр сине Тәңре тугрылык өчен.
Халыкка тугры бул һәм алма үчең.

Ни ди, ишет, берәү — якты күңелле
(Минем сүзгә аның сүзе дәлиллек):

«Тәңрегә тугры күк, шуңар мәһабәт,
Агач җиргә тугры һәм матур, һәйбәт».

Ястанма һәркемгә, күңлең тот горур,
Ике дөньяда да тугры — тугры ул.

Менә, илбик, үзем белгәннәрем шул.
Сиңа бәян иттем эчен һәм тышын.

Ике дөньяда да файдалы сүзем,
Сиңа әйтеп бирдем шулай дип үзем.

Бу дөньяда рәхәт һәм дә изге ат
Бирер сүзем, тотсаң дөнья-ахирәт.

Бу дөнья байлыгы тиз бетәчәк ич,
Төкәнмәс байлыгың тик изге ат ич.

Бу бапта тәгълимат болай әйтелә
(Һәр сүз үз мәгънәсе буенча килә):

Ястанма һәркемгә, күңлең тот горур,
Ике дөньяда да тугры — тугры ул.

«Атым изге булсын үзем үлсәм дә,
Ни булса да атым калсын, ди бәндә.

Уйла, игелек кыл, изге ат телә,
Мәңгегә тере кал, изге ат белән».

Ишетте илбик сүз, сөенде каты,
Күңел изге-якты, хакыйкать татлы.

Күп алкышлады ул бу Үгделмешне,
Әйтте: — Сөйләдең син үзең белмешне.

Бүгеннән соң Тәңре тәүфыйк бирсен, дим,
Син әйткән бу сүзләр илә эш күрим.

Ходай биргәч синдәй ярдәмчене, мин
Өметләнгән эшкә тиз ирешермен.

Вә бүгеннән соң да син, рәхим итеп,
Ярдәмеңнән, дустым, ташлама инде.

[3] Йортавыл — хәрби сәфәр, поход.

**Рәхимле зат синең өчен көзгедер,
Ияр, аңа карап, күңлең төз булыр.**

Ышанам мин сиңа, инандым үзем,
Сүзне яшермә, и, якты йөзем.

Кояш чыкты миңа, яктырды көнем,
Һәм синдәдер минем иң зур өметем.

Ни шәп әйткән рухи хәлне белгән бер
«Телемдәге тилгә[4] якын», дигән ир.

«Сиңа кем ошаса, шуңа көзге тот,
Үзеңне күрәсең — каршы туры тот».

Рәхимле зат синең өчен көзгедер,
Ияр, аңа карап, күңлең төз булыр.

Кемнең күңле сиңа якынрак булса,
Якын ит син шуны һәм шуңа ышан.

Ышанган кешеңнән гел киңәш сора,
Ышанган кешеңнең сүзен тот соңра.

Үгделмеш аңлады илбикнең сүзен,
Сөенде, «әйе», дип, ярытты күзен[5].

Сүзен кисте илбик, талыгып китте,
Ә Үгделмеш торды һәм чыгып китте.

Шуннан ары илбик тынычын куеп,
Төзеде үз илен, хезмәт салды күп.

Яманнарны куды, яхшыны инде
Үзенә дус кылды, бүләкләр бирде.

Сөзелде халык һәм төзелде иле[6],
Тынычлыкта үтте көне, ай, елы.

Илең тату булса, яшәү дә татлы.
Рәхәткә тиенде ул, тапты шатлык.

Хөрмәтләде илбик бу Үгделмешне,
Ышанып тапшырды аңар бар эшне.

Тыныч йөрсә дә, тик Үгделмеш ага.
Сафада булмады, төште хафага.

Яшәлгән гомерен күздән кичерде:
«Егетлегем зая үтте ич инде».

Ачылды, гүя ки, күңелнең күзе,
Кылмак булды эчке дөньясын төзек.

Әйтте үз-үзенә: «Гафил йөргәнмен,
Гафиллектә зая гомер сөргәнмен.

Китә барган миннән терелек көче,
Булачакмын тиздән таяк тотучы».

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ АЧЫНУ СҮЗЛӘРЕ ҺӘМ ТӘҮБӘСЕ

«Үтте гомер, — диде, әйтте үкенеп, —
Тереклек төкәнде, каралды көнем.

Сыердай биреелдем ашау-эчүгә,
Мал кебек, карамый бүтән бернигә».

Әйтте: — Гафил йөрдем мин көлә-көлә,
Көннәрне кичердем гамьсезлек белән.

Егетлек гайрәтем бушка киткәнгә
Ачынам, егет чак зая үткәнгә.

Яшәү инде бетә, якынлый үлем,
Үлемнән качарга күренми юлым.

Чәчем шоңкар төсе кебек — көл төсле,
Сакалым ябага — язгы җөн төсле.

Утыз ике тешем энҗедәй иде,
Бу дисбенең, нишлим, өзелгән җебе.

Күрер иде күзләр бер көнлек җирне,
Янымда торганны да күрмим инде.

Колагым ишетер иде еракτан,
Хәзер кулым белән генә аңлатам.

**Ышанган кешеңнән гел киңәш сора,
Ышанган кешеңнең сүзен тот соңра.**

[4] Тил — Күңел, эчке дөнья, хәтер.
[5] Күз ярыту — сөенү, себер татарларында хәзер дә кулланыла.
[6] Бу борынгы әйтем булса кирәк. Сөзелү — чистару.

Кара козгын төсле кара башыма
Кугу[7] кунды, җиттем, ахры, яшемә.

Асылыма кайтам – Ходай каршына,
Гозерлим: «Гөнаһны, зинһар, ярлыка!»

Ташладым мин барча ярамас хисне,
Күңел болганычым сөзелә төсле.

Янә уйлап алам: «Шашынмыйм әле»,
Ашыгу яман шәй – ашкынмыйм әле.

Иң элек бу эштә киңәшү кирәк,
Яраксызны ташлап сөйләшү кирәк.

Киңәш белән белеп эш кылу кирәк,
Киңәшсез эшләп тә үкенмәү сирәк.

Ни ди, ишет, әнә кеше кямиле:
Хәл авырлыгының киңәштер име.

Киңәшсәң, иң тәүләп – якының белән,
Чөнки ул хәлеңне якыннан белә.

Һәр эшеңдә уңар киңәшкән кеше,
Көенечле булыр киңәшсез эшең.

Барыйм әле хәзер кардәшкә таба,
Сөйлим әле ошбу хәлне, и, алпар.

Яраклы, дип әйтсә, бу эшне кылыйм,
Яраксыз, дип әйтсә, ташлыйм, калдырыйм.

Кеше үз эшен һәр яктан да күрми,
Бүтәннәрдән сора – әйтсен фикерен.

Киңәшсәң, киңәя синең карашың,
Киң караштан уңа эшең барышы.

Ни ди, ишет, берәү – киңәшче кеше,
«Киңәш башлый, киңәш тәмамлый эшне.

Нишләмәк булсаң да киңәш ничек тә,
Киңәшмәсләр белән, туган, эш итмә».

Каю эш чыкса да, тәүдә киңәшләш,
Теләгеңә тугры илтәчәк киңәш.

**Киңәшсәң, иң тәүләп – якының белән,
Чөнки ул хәлеңне якыннан белә.**

Кичен ятты, иртән торып юынды,
Илбик сәраена атын юыртты.

Рөхсәт сорап керде илбик каршына,
Илбик урын бирде үзе каршылап.

Үтенеп илбиктән, әйтте: — Бүген мин
Кардәшем янына барырга телим.

Боерсагыз әгәр, илбик буларак,
Барып кайтыйм шунда, кылып зиярәт.

Илбик әйтте: — Баргын һәм миннән сәлам
Әйт аңар, и, холкы кямилән тәмам.

«Онытма син, — диген, — догада бийне»,
Илаһка җиткерсен серемне минем.

Ходадан сорасаң, языкларымның
Өмет итеп була ярлыкануын.

Үгделмеш хушлашты, чыкты ашыгып,
Өенә килде һәм язылды кашы[8].

Алтынга манылды дөнья кыртышы,
Зәгъфрандай булды кояшның төсе,

Кашын төйде күк һәм төнәртте йөзен,
Вә тотып бәйләде кешеләр күзен.

Намаз кылды, ятты түшәккә кереп,
Бераз оеп алды, бераз төш күреп.

Түшәк рәтләп, тагын ятты бөркәнеп,
Һәм уянды ялгыз килеш сискәнеп.

Ачылды шуннан соң күзләре кабат,
Ирегеп ятты ул киң күккә карап.

Күзәтте ул ничек Каракош[9] туа
Һәм учактай булып офыктан куба.

Дәвамы бар ■

[7] Кугу — «аккош» (татар сөйләшләрендә дә бар).
[8] Ягьни, тынычланды.
[9] Каракош – Юпитер, Елдырык – Сириус йолдызы, Айгыр, Ирәнтез, Сүкеч – йолдызлык атамалары (нинди икәнлекләре төгәл билгеле түгел).

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Еракта калган ул төндә кара күкрәкле Этуген Җирендә яшь Темучинның үч алу анты яңгырады. Кабахәт меркитләр, өч көнлек канлы бәрелештән соң, коточкыч аяусыз кысрыклаудан, гадел җәзадан котылып, мескен гомерләрен саклап калыр өчен, торлакларын һәм ат көтүләрен ташлап, абына-сөртенә качтылар, ә үч алу антында шулай әйтелгән иде:

...Борынгы, еракта күренгән байрагымны
яуга чыгар алдыннан мин корбанымның
канына манчыдым. Кан акты...
Үзем калын тавышы белән гөрселдәгән,
үгез тиресе тартылган добулбасны
кактым.
Сырган кара көбәмне кидем дә
кара яллы йөгерек атыма утырдым.
Дәһшәтле кылычымны тотты кулым.
Ул әшәке меркитләргә бара юлым.
Алар белән сугышырмын мин үлгәнче...
Кырам бала-чагасына хәтле
меркитләрнең барысын.
Аларның җирләре, әйдә, бушап калсын...

Бу ант арат-киятлар ыругын үч алу орышына күтәргән Темучиннан куркып качучыларның акырышу һәм үкереп елаулары белән тулган төндә тормышка ашты. Качып баручылар уртасыннан өсте ябылган бер арба тәгәри иде. Як-якка бәргәләнеп тә аны таба алмыйча: «Бортэ! Бортэ! Син кайда? Бортэ!» – дип өзгәләнеп кычкырды һәм әлеге мәхшәрдә хатынын эзләп табарга тырышты Темучин, тик әлеге ябулы арбаны куып тоткач, аны куалап баручыларның һәммәсен кыргач кына: «Мин монда! Мин – Бортэ!» – дип, хатын аңа каршы тавыш бирде һәм арбадан сикереп төште, ә ул атыннан җиргә тәгәрәде дә, алар бер-берсенә каршы ташландылар. Кочагына яшь хатыны исән-имин килеп сыенган мизгелдә ул йөрәге кысып алганын тойды: таныш түгел ят ис, тәмәкедән сасыган мыек исе иде, ахрысы, кемнеңдер аның җылы, шома муенына капланып, тупас иреннәре белән кан чыкканчы суырып ләззәт алганын белгертеп тора иде. Ә бу вакытны тирә-юньдә канлы бәрелеш, орыш, үч алу дәвам итте...

Менә шул минуттан ул инде беркем белән дә якалашырга, сугышырга ташланмады. Әсирлектән коткарылган хатынын арбага утыртып, үзен көйдереп узган утны шунда

Башы журналның 2016 елдагы 8 нче санында. Тәрҗемәче – **Мөдәррис Вәлиев**.

ук тышка чыгармас өчен, берни дә әйтмичә, кайту юлына борылды һәм аннары бөтен гомере буе газапланды. Темучин аңлый – хатыны дошман кулына үзе теләп барып кермәде. Шулай булса да, ул ни исәбенә бу хәлдән котылып чыкты? Аның башыннан бер бөртек чәче дә төшмәгән ич. Төптән уйласаң, Бортэ әсирлектә җәфа чикмәгән, аның тышкы кыяфәте дә интеккән кешегә охшамаган иде. Юк, аннан соң да алар арасында бу хакта ачыктан-ачык сөйләшү-аңлашу булмады шул.

Шушы тар-мар итүдән соң исән калган меркитләрнең барысын да кырып бетерде диярлек, бүтән илләргә яки кеше аягы басмаган җирләргә күчеп китә алмаган аз санлы меркитләр инде, көтүче һәм хезмәтче булып, колга әверелделәр, алар хәзер һичнинди куркыныч тудыра алмыйлар иде. Берәүнең дә башына бу нәтиҗә – ул вакытта инде Чыңгызхан булып җитешкән Темучинның котылгысыз үчен гамәлгә ашыру икәнлеген аңламады. Меркитләрнең берсе дә, моның берзаман аларда әсирлектә булган Бортэгә ниндидер мөнәсәбәте бар, дип әйтә алмый иде инде.

Соңрак Чыңгызханның тагын өч хатыны булды, тик язмышның теге вакыттагы беренче рәхимсез оруыннан калган авыртуны баса алмады. Хакан шул авырту хисе белән һаман яши иде. Беркемгә беленмәсә дә, каны саркылып торган йөрәк ярасы белән. Бортэ беренче баласын – уллары Җучины тапкач, Чыңгызхан көннәр исәбен берәмтекләп санаган булды, әмма тегеләй дә, болай да килеп чыга, бала аныкы булырга да, булмаска да мөмкин иде. Билгесез булып калган кемдер аның намусына тупас басып, бөтен гомеренә тынычлыгын алды, каһәр.

Инде бүтән билгесез зат, байрак тегүчегә бала ясап биргән ир, хаканга һичнинди мөнәсәбәте булмаса да, барыбер аның канын кайнатты.

Әле генә аңлаешлы, бөтенлекле дөньясы күз ачып йомган арада кыйшаеп, җимерелеп төшсен өчен, кайчак кешегә аз гына нәрсә дә җитә... Бөек хаканның күңелен үзе кичергән хәлне искә төшерү актарып ташлады. Югыйсә тирә-юнендә барысы да шул хәбәрне ишеткәнчегә кадәр калды. Әйе, алдыннан, чем-кара атларын биетеп, аждаһалы һоруңнарын җилфердәтеп, әләм йөртүчеләр бара, ияре астында, – һәрвакыттагыча, яраткан юргасы Хуба; янәшәсендә һәм артыннан менә дигән чапкы атларында аңа йөгенгән яраннары калышмаска тырыша; як-ягында тугрылыклы сакчылары – ярты меңләп кизүвыллар көтүе; күз күреме араны иңләп, дала буйлап дошманны кырып барырлык көч-куәт – ничәмә-ничә төмәннән торган чирү һәм аларның таянычы – меңләгән олаулар ишелеп килә. Ә баш очында, бу кешеләр агымы өстендә, яуга чыккан беренче көннән бирле Күк-Тәңренең фатихасы булып, тугрылыклы ак болыт йөзеп бара.

Барысы да элеккечә кебек иде, шулай да, хаканның әкренләп көчәя барган яшенен чакырып, кара болытлар куерды, дөньясында нәрсәдер урыныннан кузгалды, үзгәрде. Күрәмсең, кайсыдыр аның ихтыярын санга сукмаган, күрәмсең, кемдер үзенең тотнаксыз җенси дәртен аның бөек максатыннан өскәрәк куярга җөрьәт иткән, күрәмсең, ул адәмчек белгән көе аның боерыкларына каршы барган. Аның атлы гаскәреннән кемдер, хаканга тел-теш тидермәслек итеп, тайпылышсыз хезмәт итәргә сусау урынына, бер җилбәзәк хатынның түшәген артыграк күргән! Һәм ниндидер өч тиенлек ул хатын да – аңардан соң бүтән беркем байрак чигә алмас дип уйлады микән? – хаканның тыюын санга сукмыйча, олаудагы башка бөтен хатыннар, аерым рөхсәт булганчы, үз карыннарын саклаган вакытта, бала табарга тәвәккәллек иткән!..

Әлеге уйлар, явызлык болытлары белән күз яктысын каплап, чүп үлән, кыргый урман кебек акрынлап үсә барды, гәрчә бу очракның кисеп ташлаган тырнакка да тормаслыгын, аңа артык әһәмият бирмәскә кирәклеген аңлый да кебек ул, әмма эчендәге икенче тавыш, боеручан көч белән башына тукый-тукый, торган саен шәфкатьсезрәк була бара, сүзен аяк астына салып таптаганнарны бөтен чирү алдында кырыс җәзага тартуны таләп итә, бүтән фикерләрне баса һәм кысрыклап чыгара иде.

Хәтта тынгысыз Хуба, һәрвакыт ук кебек атылып тип-тигез оча торган юрга, ул көнне хакан ияр өстендә генә үткәргәнлектән, юл дәвамында арта барган ниндидер өстәмә авырлыкны тойган кебек, күбекләнеп торган тиргә батты, элек мондый хәлнең булганы юк иде.

Чыңгызхан, чыраена дәһшәтле төс чыгарып, үзалдына йомылды, әмма алга баруыннан туктамады. Бөтен дөньяда хакимлеген урнаштырырга дигән бөек ниятен тормышка ашыру өчен, дала ташкынының Кояш баешына таба хәрәкәтенә берниндә көч тә комачаулык итә алмас кебек тоелса да, барыбер нидер булды: күзгә күренми торган, энә очы кадәрле генә бер чуерташ аның боерыкларыннан өелгән мәңге какшамас кебек тау башыннан аска таба тәгәрәп китте һәм бөтен күңел тынычлыгын юкка чыгарды. Ул юл буе шул хакта уйланды, тырнак астына кергән шырпы төсле, гел бернәрсә аны борчыды, һәм, чуалган җепнең очын сүтеп-сүтеп тә таба алмаганга, үз тирәсендәге якыннарына торган саен ныграк ачуы килде. Ничек ул менә әле генә, теге ыштырбит инде баласын тапкач, аңа килеп әйтергә батырчылык итәләр, ә моңарчы алар кайда булганнар, кая караганнар, корсаклы хатынны күрмичә торып буламыни? Ул чакта сөйләшү дә икенче төрле булыр иде, – азгын эт кебек артына тибә-тибә куып кына җибәрерләр иде аны. Ә хәзер ничек хәл итәргә? Килеп чыккан хәл турында аңа хәбәр килеп ирешкәннән соң, олаулар өчен җаваплы нойонны аңлатып бирү өчен чакырып, ул аңардан зәһәр итеп сорап куйган иде: чигүче хатын баласын тапканчы, тугрылыклы шымчылар ишеткәнче, ничек шулай килеп чыга алды, бөтенесе дә беленмәс килеш торды? Ничек болай була ала ул? Нойон борын астыннан гына буталчык җавабын мыгырдады: имештер, Догулаң исемле байрак чигүче ул хатын аерым тирмәдә, һәрвакыт читтәрәк яшәгән, үз олавы булган, аңа бер хезмәтче беркетелгән, эшкә чумуына сылтап, һичкем белән аралашмаган, ә йомыш белән килүчеләр булса, төрле тукымалар, гадәттә байрак чигә торган ефәк өеменә төренеп-чумып каршы алган, һәм кешеләр аны, матур булып күренергә, бизәнеп-ясанып утырырга ярата, дип кенә уйлаганнар. Шуңа күрә, янәсе, йөкле икәнен дә белүе кыен булган. Яңа туган баланың атасы кем – билгеле түгел. Әле чигүчедән сорау алырга өлгермәгәннәр. Хезмәтче хатын, берни дә белмим, дип бара. Тот куянның койрыгын...

Чыңгызхан, ачуыннан гарьләнеп, бу тарих шул дәрәҗәдәге игътибарга лаек түгел, дип уйланды, әмма бала табуны тыю – ул үзе урнаштырган тәртип, ә һәр чирүнең җаваплы заты, әмернең бозылуы турындагы хәбәрне өстеннән төшерү өчен, югарыдарак утыручы хуҗасына җиткерә дә котыла, шул рәвешле, күзгә күренмәс чылбыр хаканның муенына килеп урала. Хәзер ул үз боерыгының тотыгы булып чыкты. Инде чигенү мөмкин түгел, җәза бирү котылгысыз иде...

Төн урталарына таба, йөзбашы Эрдене, ашыгыч йомышлар үтәп йөрүенә сылтап, меңбашына киттем, дип, аланнан чыкты, әмма бу аңа төнлә үзенең мәгъшукасы белән качу өчен бер хәйлә генә иде, әлбәттә. Бу вакытта инде хаканга барысы да билгеле булуын ул әле белми, Догулаң һәм бала белән качу юлы киселгәне дә аңа мәгълүм түгел иде.

Алмаш атын, бәйдәге ау эте сыман, йөгәненнән тотып барганда, йөзбашы Эрдене аланнарны хәвеф-хәтәрсез генә әйләнеп узды һәм, гадәттә Догулаң тирмәсе янында торган олауга якынлашканда, Ходайдан бары бер генә нәрсә – һәр төндә тирәюньне әйләнеп чыга торган нойон күзәтчеләренә тап булмауны сорады. Болар – иң бәйләнчек һәм аяусыз адәм актыклары, әгәр берәр атлының ничектер сөт аракысы эчеп сәрхушланган икәнлеген сизеп алсалар да, аңа рәхим-шәфкать күрсәтмәсләр, шунда ук ат урынына тәртә арасына керергә һәм җигелергә мәҗбүр итәрләр, ә олауга менеп утырганы, камчы белән бәргәли-суккалый, дала буйлап куар...

Үз кул астындагы йөз сугышчыны калдырып-ташлап киткәндә, Эрдене белә иде: әгәр тота калсалар, аңа иң югары җәза – киез белән томалап яки асып үтерү яный.

Хакан каһәреннән котылу юлы бер – ерак якларга, чит җирләргә башыңны алып кача алсаң гына исән калу мөмкин булачак.

Даланы бу юлы да айлы төн яктырта иде. Һәркайда аланнар, ат көтүләре сибелеп урнашкан, һәркайда пыскып торучы учаклар янында сугышчылар тезелешеп йоклап ята. Бу кадәр күп кеше һәм олаулар мәхшәрендә кемнең кая баруына һичберәүнең исе китми иде. Йөзбашы Эрдене менә шуңа исәп тотты да: аңа Догулаң һәм улы белән качып китәргә моннан да уңайлырак җай чыкмаячак, – әгәр бу төндә тәкъдир аларга арты белән борылмаса...

Бәлагә тарыганнарын ул осталар табырына якынлашу белән аңлап алды. Өзәңгегә сикереп менеп, ике атның да иярләренә ныклап ябышты да, тынын да чыгармыйча, аларның күләгәсенә сыенды. Әйе, башларына бәла килгән! Иң кырыйдагы тирмә янында, тирә-юньне дөрләп янган уты белән яктыртып, бик зур учак яна. Дистәләп ясавыл, үзара кычкырып сөйләшә-сөйләшә, атлары белән учак тирәсендә таптанып торалар. Иярдән төшкәннәре – өчәү – бүген төндә Догулаңны утыртып качарга җыенган олауга ат җигеп маташа. Аннары Эрдене ясавылларның ничек итеп тирмәдән кулына баласын тоткан Догулаңны алып чыкканнарын күрде. Әнә ул, өстенә сусар тунын ябынган хәлдә, агарынып, хәлсезләнеп, куркынып, сабыен күкрәгенә кысып, учак яктысында басып тора. Ясавыллар нидер сорашалар бугай. Аларның: «Җавап бир! Җавап бир, диләр сиңа! Сөйрәлчек, уйнашчы!» – дип җикеренгәннәре монда хәтле килеп җитте. Аннары хезмәтче Алтунның үкереп елаганы ишетелде. Әйе, бу аның тавышы, һичшиксез, аныкы иде. Алтун өзгәләнеп кычкыра: «Мин кайдан белим?! Ни өчен мине кыйныйсыз? Кемнән тапканын кайдан белим, ди, мин! Далага чыккач, кичә генә узмаган бит! Әйе, баласын ул күптән түгел тапкан, үзегез күреп торасыз. Тик бу хәлнең, димәк, моннан тугыз ай элек булганлыгын аңламыйсызмыни соң?! Кайчан кем белән – мин аны ул чакта белә идеммени?! Нигә мине кыйныйсыз?! Ә аның ник котын аласыз, үлем хәленә җиткереп куркыткансыз, – ул бит яңа туган сабый белән! Ул сезгә хезмәт итмәдемени, сезне яуга алып бара торган һоруңнарыгызны чикмәдемени? Хәзер аны ни өчен үтерәсез, ни өчен?»

Тояк астында калган зәгыйфь үлән кебек мескен Алтун – ул нишли ала инде, йөзбашы Эрдене үзе дә башын күтәрергә кыймыйча торганда, унлаган кораллы ясавылга каршы ул да берьялгызы чарасыз иде бит?! Берсен яисә икесен дөмектереп үлсәң генә, әмма бу корбан нинди дә булса җиңеллек бирәме? Өер булып йөрүләре белән һәрвакыт оталар да шул ясавыллар. Бөтен көтүләре белән бугазга ябышып кан эчү өчен ябырылырга көтеп кенә торалар!

Йөзбашы Эрдене ясавылларның Догулаңны бала белән олауга утыртуларын, аның янына ук хезмәтче Алтунны да ташлауларын һәм аларны каядыр төн эченә алып кереп китүләрен күрде.

Шуның белән барысы да тынычланып калды, тирә-якта шомлы бушлык хакимлеге урнашты. Шулчакта гына бер читтәрәк этләр өрүе, атлар кешнәве, ял урыннарындагы кешеләрнең мыдыр-мыдыр нидер сөйләшкәне ишетелә башлады.

Чигүче Догулаң тирмәсе янындагы учакның уты инде шактый сүрелде. Җир өстендәге әле генә булып узган җил-давылны үзләренә сеңдереп, адәм балаларының тәкъдирендә язылган көрәш газапларын еizaktan күзәтеп торучы тавышсыз-өнсез йолдызлар, учак тирәсендәге бушап калган киңлеккә армас-талмас җете күзләрен текәп, тыныч, гамьсез балкуларын дәвам иттеләр...

Өнендә төш күргән кебек барган йөзбашы Эрдене бер тын эчендә оеган, суынып киткән бармаклары белән алмаш атның башындагы йөгәнен капшап тартып төшерде һәм аның аяклары астына ташлады. Йөгән тонык тавыш белән җиргә ятты. Эрдене, тыны кысылып, үзенең йөрәк тибешен ишетте, сулыш алуы авырайганнан-авырая бара иде. Шулай да ул әле алмаш атның җилкә калкымына учы белән җиңелчә генә сугып алырлык хәл тапты. Бу ат инде хәзер аңа кирәк түгел, ул үз иркенә китә ала

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

иде, һәм малкай, шуны гына көткәндәй, якындагы үз ишләре янына – төнге көтүгә таба юртты. Ә йөзбашы Эрдене, бер максатсыз, кая барганын, ник барганын үзе дә аңламыйча, мамык кебек йомшарган аякларын көч-хәл белән сөйрәп, дала буйлап китте. Аның артыннан, бушап калган йөгәнен әледән-әле чайкап, йомшак кына адымнар белән, тугры һәм аерылмас сугышчан юлдашы – йөзбашы Эрденене ничә орыш эченнән исән-имин алып чыккан кашка аты Акйолдыз атлады. Бу төндә аңа да яраткан хатыны һәм яңа туган баласы белән иясен явызлар тырнагыннан коткарырга язмаган икән шул.

Эрдене, ни дә булса булыр, дип, уйлап-нитеп тормыйча, сукыр кебек, аяк астын капшап кына бара; ике күзе дә юеш сакалы буйлап тамып төшә баручы яшь белән тулы, ә ай нурының тигез агынтысы, аны юатырга тырышкандай, бөкрәйгән, әледән-әле көзән җыерган кебек тартыша-тартыша дертләп ала торган иңнәрендә чайкалып, сыйпап озата иде... Ул, көтүдән куып җибәрелгән, бөтен дөньяда берүзенә генә терек-лек итәргә калган ялгыз кыргый җанвар сыман атлавын белде: булдыра алсаң – яшә, юк икән – үл. Бүтән һичнинди чара да юк... Ни эшләргә инде аңа хәзер, кая барып башын төртергә? Бу газаптан бары тик үлеп кенә – күкрәгенә, бертуктаусыз сызлаган йөрәгенә хәнҗәр кадап кына котылып буладыр, бары тик шулчакта әрнеп-яндырып торган яраны, авыртуны басарга мөмкиндер яки инде, үз-үзеңнән качып, кайдадыр эзсез югалырга, мәңгелек кочагында эреп бетәргә кала...

Йөзбашы җиргә егылды, тонык тавыш белән үкси-үкси, ташларга учларын, тырнакларын суйдырып, алга таба шуышты, ләкин җир аны кочагына алмады, шуннан соң торды, билендәге пычакны капшап тапты...

Дала тын, буш һәм айлы-йолдызлы, уч төбендәге кебек җәйрәп ята. Янәшәдә, ай яктысына коенып, бары тик бер җан иясе – тугрылыклы кашкасы Акйолдыз басып тора, сабыр гына үзенә әмер көтеп пошкыра иде...

Ул иртәдә дә, юлны дәвам итәр алдыннан, алдан ук калкулыкка җыелган барабанчылар, гаскәрнең җыелырга тиешлеген белгертеп, добулбасларын дәррәү дөмбәсли башладылар. Ярсыган добулбаслар, инде тиз генә тына алмыйча, арта баручы шомлы гөрселдәүләре белән тирә-юньне тетрәттеләр. Үгез тиресе тартылган барабаннар, яу вакытында бала тапкан азгын хатынны, байрак чигүчене, – аның исеме Догулаң икәнлеген кем генә белгәндер, – җәзалап үтерергә чакырып, капкын базына төшкән кыргый җанварлар кебек, үкерештеләр, ярсыдылар.

Добулбасларның шашынган тавышы астында, бәйрәм тантанасына чыккан төсле, бөтен коралларын тагып, йөзәр-йөзәр булып тезелешкән атлы гаскәрләр калкулыкны ярымтүгәрәк рәвешендә уратып алган, ә аларның як-ягында – йөкләрен тутырган олаулар, олау өсләренә исә яуга хезмәт итүче барчасы – тирмә коручы, корал ясаучы, каешчы, тегүче осталар, барысы да яшь, әле җимеш китерәчәк ирләр һәм хатыннар менеп төялгән. Бу нәкъ менә аларны куркыту, аларга сабак, гыйбрәт бирү өчен оештырылган мәхшәр-тамаша – бөтен халык алдында җәзалап үтерү иде. Хакан әмереннән чыгарга батырчылык иткән һәркем белеп торсын: ул да шулай, Ходай биргән гомереннән бер мизгелдә мәхрүм калачак!

Калкулыктагы добулбаслар, тамырлардан аккан канны суытып, күңелләрдә катып калган курку тойгысын ныгытып, ягъни Чыңгызхан хөкеме белән ризалашу, хәтта аны хуплауны көчәйтеп, гөрселдәвен дәвам итте.

Менә, добулбасларның бертуктаусыз гүләве астында, өстенә чатыр корылган күчмә алтын тәхете-паланкины белән калкулыкка аның үзен – әмеренә буйсынмаган өчен, куркыныч җинаятьчене – яшь ананы җәзалап үтерү карарын кабул иткән хаканны утыртып алып менделәр. Ул тәхетне җирән төстәге калкулык өстенә – кояшның иртәнге беренче нурларында коенып җилдә җилфердәгән һоруңнар уртасына куйдылар. Алардагы ут бөркүче аждаһалар, җанлы булып, менә-менә сикерергә әзер тора иде кебек. Хакан аждаһада үзенең дәһшәтле көче гәүдәләнеш таба, дип хыяллана, әмма

чигүченең, аны уена да кертмичә, ә бөтенләй башка берәүгә – куенында иркәләгән дәртле һәм кыю ир-егеткә – үзенең аждаһасына җан өргән икәнлеген күз алдына китерә алмый. Тирә-юньдәге берәү дә тиздән башланасы кырыс җәза яшь хатынның тәвәккәллеге өчен булганын белми иде әле.

Менә ул мизгелләр килеп тә җитте. Барабаннар, әкренләп, тавышын баса башлады, җәзалап үтерү алдыннан алар тынып калырга һәм, шул рәвешле, авыр тынлыкны тагын да киеренкерәк итәргә, коточкыч хәл алдыннан вакыт агышын да туктатып торырга тиешләр, ә аннары, җан кыю вакыйгасын кыргый үкерү тавышлары белән озатып, яңадан ярсып дөберди башлаячаклар; бу вәхши туйның максаты да әлеге тамашаны күрергә җыелган бәндәләрнең кан исен тоеп исергән аңын томалап, кыргый тойгыларын – әле генә аралашып яшәгән, һичберәүгә зыян салмаган үз ишләреннән рәхимсез үч алуны, кеше кайгысына сөенеп тантана итүне, асып үтерүгә ул түгел, ә кемдер бүтән берәү дучар булачак дигән яшерен шатлык белән юануларын ныгыту иде.

Барабаннар тынычлана башлады. Инде урнашып килүче бу тынлыкны җыелган халык кына түгел, хәтта җайдаклар астындагы атлар да бозарга кыймас кебек. Чыңгызханның үз йөзе дә таш сыман катып калган. Нык итеп кысылган кырыс иреннәре һәм керфек тә какмый торган тар уентылы күзләренең салкын карашы даладагы агулы елан торышын хәтерләтте.

Җәза үтәләсе урынга иң якын тирмәдән байрак чигүче Догуланңы алып чыккач, барабаннар тәмам тынды. Алып гәүдәле ясавыллар аны кулларыннан эләктереп алдылар да пар ат җигелгән арбага йолкып менгезделәр. Догулаң арбада, аркасыннан терәп торучы караңгы чырайлы яшь ясавыл белән янәшә басып калды.

Рәт-рәт булып торган кешеләр, бигрәк тә хатын-кызлар чыр-чу килде: менә ул, теге чигүче шул үзе инде! Уйнашчы! Иясез әнчек! Яшьлеге һәм шундый матурлыгы белән кайсыдыр нойонга икенче яисә өченче хатынлыкка бара алмас идеме! Ә ул ир дигәне өстәвенә картрак та булса, – тагын да шәбрәк. Бер кайгы белмичә типтереп яшәр иде. Юк, үзенә сөяркә ияләштергән дә бала тапкан, җирбит! Карасана, хаканның илаһи йөзенә төкерү белән бер ләбаса бу! Ә хәзер, әнә, башы белән түләсен. Аның тәхете – дар агачында! Уеннан уймак чыктымы, ә, чибәркәй! – Үз ишләрен чәйнәүгә, гайбәтләргә сусаган бу төркемнең рәхимсез хөкеме добулбасларның усалланып дөпелдәвенең дәвамы иде. Үгез тиресен тартып эшләнгән барабаннар хакан үзе күрәлмый башлаган кемсәгә нәфрәт уяту өчен шулай катгый һәм колакларны тондырып дыңгырдый да ич инде.

– Ә-ә, менә зина җимеше белән хезмәтче дә монда икән! Күрегезче! – дип, олау хатыннары зәһәр сөенеч белән кычкырып җибәрделәр. Бу чынлап та хезмәтче Алтун иде. Ул чүпрәк-чапракка төрелгән күкрәк баласын күтәреп килгән. Алыптай ясавыл озатуы астында, куркынып, як-ягына карана-карана, тәмам куырылып, Алтун, кулындагы җанлы нәни төргәге белән, үлемгә хөкем ителгән чигүченең җинаятен раслаган дәлил кебек, арба яныннан атлый. Җәзалап үтерү мәрәкәсен үтәр алдыннан, моны күзәтеп торучыларны куркытыр өчен, аларны юри шулай алып баралар. Догулаң аңлый иде, хәзер бүтән котылу юлы юк: бернинди кичерүне дә, һичнинди ярлыкауны да көтеп булмый.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ЗӨЛФӘТ ХАН
ЯКИ
ЧЫТЫРМАНДА БЕР БЫЛБЫЛ САЙРЫЙ

Ләбиб Лерон

Кемдер җимерелгән ил калдырыр,
Бездән калыр –
Шигъри сүз генә...
Зөлфәт

Чорыбызның, халкыбызның мәшһүр шагыйре Зөлфәт һәм аның шигърияте хакындагы бу язмамны шагыйрьнең үз сүзләре белән башлау мәгъкульрәк булыр төсле: *«Һәр асыл шигырьнең үз тарихы бар. Күңел тарихыннан мәхрүм шагыйрь – географиядән, тарихтан мәхрүм дәүләт ул»*. Аның «Чытырманда былбыл сайрый» дигән эссе-язмасыннан алынган әлеге фәлсәфи гыйбарәне куәтләп, шагыйрь иҗатына тирәнтен бәяләмә биреп, олуг әдип Нажар Нәҗми 1996 елда болай дип яза: *«Мин аны тәү мәртәбә синнән ишеттем. Күңел тарихы... Аны шагыйрь генә (шигырьче түгел) – үз канында, үз телендә, үз булмышында тойган шагыйрь үзе генә әйтә аладыр. Моны әйтер өчен югары акыл, тирән хисле йөрәк кирәктер...»*

Мин – гап-гади бер юлчы, шагыйрьнең әнә шул күңел тарихына йөз тотып, сәфәр чыктым...

***

...Кое сиртмәләре җырлап тора,
Яңа Сәет – татар авылы.
Бер соклану белән күзәтәм мин
Кызларының текә адымын.

Бабаларым монда чана бөккән,
Агаларым тәртә каерган.
Кул тотынып авыл әйләнәсен
Әйлән-бәйлән уйный карурман...

Яңа Сәет – дөньяга Дөлфәтне, шигъриятькә Зөлфәтне биргән авыл.

Зөлфәт Тукай һәйкәле янында шигырь укый

...Балачакта безнең – бериш малайшалайның, вилсәпитләргә атланып күрше авылларга «ил гизәргә» йөри торган гадәте бар иде. Якын-тирәдә без булмаган, без күрмәгән авыллар калмагандыр, шәт: Тәкмәк-Югары Яхшый-Наратлы (элекке исеме – Мәчти, бу авыл хәзер юк инде)-Байсар... Айман-Колын-Пучы... Сикия-Әмәкәй...

Бу – үзенә күрә бер мавыгу-кызыксыну, үзебезчә дөнья күрергә тырышуыбыз булгандыр инде. Әти-әниләр мондый сәяхәтләргә чыгуыбызны, бәлки, юкны бушка аударып йөрү дип кенә кабул иткәннәрдер. Хәер, күп очракта алар кайсы авылга барып кайтуыбызны белми дә кала иде. Алдан ук маршрутны билгеләп («Бүген фәлән авылга барып

Зөлфәт якын дусты, иҗатташы Фаил Шәфигуллин белән. 1970-1980 еллар

кайтабыз!»), чыгып китәбез сәфәргә, ачыгып, алҗып, хәлдән таеп кире кайтабыз. Әмма бу ачыгу-алҗулар безнең күңелләрдәге шатлыклы тәэсирләр янында бер ләззәтле интегү генә: без бит бүген тагын бер авылны ачтык!

Чираттагы шундый сәяхәтләребезнең берсендә Яңа Сәет һәм Уразмәт авылларына килеп чыктык. «Менә шушы Яңа Сәет авылында Зөлфәт абый туган инде... Менә бу Уразмәт мәктәбендә Зөлфәт абый укыган... Монда шагыйрь Рәдиф Гаташ укыткан...» дигән уй, әлбәттә, башыбызга да килеп карамады. Күрәсең, кызыксыну дигән өстенлек ул чагында әдәбиятка түгел, географиягә күбрәк бирелгәндер...

***

...Миңа өч-дүрт яшьләр чамасы чакта, ул – Дөлфәт Маликов, булачак шагыйрь Зөлфәт, хәлфәсе Рәдиф Гаташ фатыйхасын алып, Казан каласы тарафына йөз тотып сәфәр чыккан. Аның күңел төенчегендә – якты хыял-идеаллар, зур өметләр, садә уй-хисләр, язылася шигырьләр, ирешәсе максатлар, самими үҗәтлек, шөбһәле оялчанлык (Казан аны кабул итәрме?)...

Ул – мосафир. Ә мосафирларның барыр юллары беркайчан да тигез булмый, туры гына булмый аларның барыр сукмаклары. Адым саен сикәлтәдер йә түмгәктер, барган саен – борылышлар,

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Мәскәүдә Әдәби институтта укыган чак.
Алгы рәттә (сулдан уңга): Зөлфәт, Валерия Гроссу (Молдова), Фирдәвес Әһлия, Роза Кожевникова, Надира, Лилия, Шамил Мөхәммәдъяров (тарихчы); урта рәттә: Равил Рахмани, Сәҗидә, (...); арткы рәттә: (...), Солтан Шәмси, Зәйтүнә Исхакова, Туфан Миңнуллин, Л.Климович, (...). 1972-1975 еллар

тау менүләр, тау төшүләр, ымсындыргыч Серле Билгесезлек...

Бу дөньяда без – һәммәбез – мосафир. Юл газабы – гүр газабы, диләр. Хак. Шулай. Кайчак булмый таянырга таяклар да, адаштыра юл күрсәткеч маяклар да...

Байтак юллар-еллар узгач, ул әйтәчәк әле Шагыйрь-остазына:

Соңнан күпме үткелләрне кичтек! –
Кемнәр кайда? Дөнья ни хәлдә?
Син әйткәнчә, бөек идеаллар
Одеалга калды бит, хәлфә!

...Кая гына барып чыктык, хәлфәм,
Инде кая барыйк, илдәшләр?
Без барасы юллар юкка чыкты –
Юл өзеге безнең бу яшәү...

Әйт, мөгаллим, ник чор чорсызланды?
Кара карлар ява күңелгә –
Аксакал һәм егет була белгән
Чын ир җитми бугай бу илгә...

***

...Аның Казанга килүенә ундүрт ел вакыт үтәр, инде ул шул вакыт аралыгында шагыйрь Зөлфәт дигән исем-ат алыр, «Мәхәббәт», «Йодрык», «Туган тел хакында» һәм «...Җилдерде ул дала атларында...» («Чакырылмаган кунак – татардан да яманрак») дигән атаклы шигырьләрен язып, дан-шөһрәт казаныр, «Сагынуга дәва юк икән», «Елыйсың, нигә еларга...», «Һаман яратам», «Ашкын, кешем» кебек популяр җырлар һәм «Мәкерле песи» исемле беренче татар балалар операсының либретто авторы булыр...

Әйе, ундүрт ел узар...

Һәм мин – инде унҗиде яшьлек егет, Казан университетына укырга керү теләге белән килгән абитуриент, яшьтәшләрем Ркаил Зәйдулла, Ләис Харрасов (Зөлкәрнәй) белән бергә тарих буенча соңгы имтиханны тапшыргач, кала тулай торакларының берсендә аның – Зөлфәт абый белән очрашырмын. Имтиханнарны уңышлы тапшыру уңаеннан җәһәт кенә оештырылган кечкенә мәҗлесебезгә ул каләмдәш дус-

Беренче рәттә (сулдан уңга): Зөлфәт, Рәдиф Гаташ, Мөхәммәт Мәһдиев, Ләбиб Лерон; икенче рәттә уңнан беренче – Ркаил Зәйдулла, аның янында, бераз арттарак – Чулпан Әхмәтова (Таңчулпан), арткы рәттә сулдан икенче – Җәмилә (Резеда) Әхтәмова. 1980 нче еллар уртасы

лары Фаил Шәфигуллин һәм Фәннур Сафин белән килгән булыр...

Тыйнак мәҗлес башланыр, кунакларга дип алынган коньяктан аз-маз авыз итә-итә мәзәк хәлләр сөйләнер, шигырьләр укылыр, кунаклар безнең кай төбәкләрдән килүебезне – гәрчә матбугат битләрендә ара-тирә күренгәләгән шигырь-язмаларыбыз буенча кай яклардан булуыбызны инде тәгаен белсәләр дә – янә кызыксынып-сораштырып алгалар, шулвакыт Зөлфәт абый, Фәннур абый, Ләис һәм мин, һәммәбез бер яктан – бер төбәктәнрәк булуыбыз белән мактанып, шаярып кына масайган булып, Фаил абый белән Ркаилне үртәп, үзара көлешеп алган булырбыз, аннары барчабыз бергә, тыела алмыйча, рәхәтләнеп көләрбез... Зөлфәт абый: «Кыстати, әй, армиядәге дустың турындагы язмаң озакламый «Яшь ленинчы»да чыгачак!» – дип миңа сүз арасында гына куанычлы хәбәр әйтеп куяр...Теле телгә йокмаган Зөлфәт абыйның сөйләгәнен тыңлап, кызыклы җирләрендә һәммәбез белән бергә көлеп, әмма күп вакыт тыенкы гына елмаеп утырган Фаил абый да, минем тарафка башы белән ишарәләп: «Әле аның бер мәзәге дә тиздән бездә – «Чаян»да басылачак», – дип, мине тагы да үсендереп җибәрер...

Бу – 1979 елның 14 августы булыр.

***

Шигырь сөючеләр, шагыйрь иҗатына бихуш-мөкиббәннәр Зөлфәтнең Шигъърият дигән ымсындыргыч дөньяга ашкынып, рухланып, ярсулы дәрт-дәрман белән килеп керүен бик яхшы хәтерлидер. Иҗатының башлангыч чорында ук халык ихтирамын яуларлык классик шигырьләр язган чын шагыйрьләр сирәктер дип беләм.

Туган телгә гимн булып яңгыраган, карап торышка гап-гади булып тоелган бу шигырьне кайсыларыбыз гына белми икән:

Тел ачылгач, әйтә алсаң:
«Әни», – дип,
Тел ачылгач, әйтә алсаң:
«Әти», – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта әйтә алсаң:

Яшьлекнең иң гүзәл мизгелләренән берсе

«Әни», – дип,
Соң минутта әйтә алсаң:
«Әти», – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...

Яшьлеге, иҗаты таңында Хәсән Туфаннан, Сибгат Хәкимнән, Нури Арсланнан, хәлфәсе Рәдиф Гаташтан фатыйха алган Зөлфәтнең күңел тарихы көннән-көн, елдан-ел ныгый, байый барды.

Зөлфәт шигъриятендә шанлы үткәнебезне сагыну да, бүгенге болгавыр заманның аһ-зарлары да, ил-көн өчен борчылу да, киләчәкне зар-интизар булып юксыну да бар.

Зөлфәт шигъриятендә – яшьлекнең, сөюнең кабатланмас мизгел-халәтләре, табышлары, югалтулары, хис-кичерешләре...

Зөлфәтнең күңел тарихында туган җир-туфракны, нигезне өзгәләнеп ярату бар, нәсел шәҗәрәсен, гореф-гадәтләребезне мәңге хәтердә тотыйк, онытмыйк-югалтмыйк, дигән шөбһәле искәртү бар.

Шигърият – Зөлфәт өчен изге тылсымдыр:

Шигъри сүзем минем –
саф тылсымым
Авыр чакта сезгә кагылсын –
Савыктырсын, горур итсен берүк,
Кеше итсен безне бу тылсым!

***

Язмыш дигәнең бик кызык нәрсә икән ул, әй! (Форсаттан файдаланып әйтим: «Әй» – Зөлфәт абыйның сөйләм телендә вакыт-вакыт очраштыргалый торган сүз).

Тулай торактагы беренче очрашудан соң янә дүрт ел узар һәм «Яшь ленинчы» гәзетасы редакциясендә миңа Зөлфәт абый белән бергә эшләргә насыйп булыр дип кем уйлаган!

Әйе, ахыр чиктә – бу язмыш. Бу – чынбарлык. Тормышка ашкан хакыйкать.

***

«Һәр асыл шигырьнең тарихы бар», – ди шагыйрь. Ул мең кәррә хаклы. Аның саллы, затлы шигърияте моңа ачык дәлил.

...Ике урман арасында
Боланнар баласыдай

Зөлфәт абый кызы Кадрия һәм уллары Фазыл, Илһам, Азамат белән. 1980 нче еллар

Йөргәнбез... Уйга килмәгән
Адашып каласылар...

Чынлап та, без адашып калучылар түгелме соң?!. Туган авыл безнең төшләргә еш керә... Бүгенгедән үткәннәргә төбәлгән Сагышлы Хыял булып...

...Хыялымда шаулый киң кырлары,
Йөрәгемдә шаулый карурман.
...Бабаларым монда чана бөккән,
Агаларым тәртә каерган...

Без – адаштырылганнар.

Әле кайчан гына күңел төенчекләребездә булган якты хыял-идеаллар челпәрәмә килде бүген. Зур өметләр – челпәрәмә. Усалландык. Уйларыбыз – кырыс. Хисләребез – салкын. Самими үҗәтлек дорфа үҗәтлеккә әйләнде. Яшәү өчен җан тартышкан мәл...

...Юл өзеге безнең бу яшәү...

Кайда адаштык без – кайсы чорда?

Кайчан? Ничек? Ни сәбәпле мондый хәлгә төштек? Алда ниләр көтә безне? Шәрә Өметсезлекме? Ачы Хәсрәтме? Җансыз Битарафлыкмы? Чәрдәкләнгән Хәтерме?

Ниләр көтә безне...

...Алда – мин яулыйсы
Дорфа Бушлык,
Аннан ары – һич Шәфкатьсез Офык.
Янә ары китсәм – Өметсез Яр,
Иң соңында – котылгысыз Ышык.

Ханнар моңа ирешкәнгә кадәр
Узар иде күпме җан түшәп?
Мин ничекләр узыйм соң бу юлны? –
Мин хан түгел, мин – бары тик
Зөлфәт...

Яшьлек елларында ук язылган бер шигырендә олуг шигърият турында, иҗатына мәшһүр Тукайның җитди йогынты ясавы хакында:

Киләчәккә китеп бара иде,
Кагыласы итте миңа да! –

– дип язды шагыйрь.

Кешем! Гомер дигән ярсулы, ашкынулы мизгел агышын, бүгенгене һәм үткәнне тыңлаганда игътибар ит: дөнья дигән чытырманда бер Былбыл сайрый – ишетәмсең?! ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ҮТКӘННӘН ХАТЛАР

Шигърият Мәҗнүне

Хатлар җыю гадәтем юк, алай да китап эчләрендә, фотолар арасында, төрле папкаларда очраклы рәвештә генә сакланып калганнары юк түгел. Арасында инде әдәбияттамы, башка бер өлкәдәме танылып өлгергән замандашларымның үсмерлек каләменнән төшкәннәре дә бар. Җанга кадерле хатларда яшьлек хыялларыбыз, уйлау рәвешебез, киләчәккә өметләребез, өлкәннәргә мөнәсәбәтебез ачык чагыла. Миннән соң әлеге истәлекле язулар барыбер ташланыр, дим. Хәзерге заманда бар нәрсәне саклау мөмкин дә түгел. Киштәләремне «яшьлек ядкярләре»ннән арындырганда, кемгәдер кызык тоелыр, дип уйлап, бер-икесен журнал укучыларына да җиткерергә ниятләдем. Авторларының күңел серләрен фаш иткәнем өчен, алдан ук гафу үтенәм. Бәлки, бу язмам аларда да ниндидер истәлекләрне яңартып җибәрер һәм шуның белән күңелләрендә яшьлекнең саф хисләрен, садә тойгыларын тергезер.



Хәсән Туфан язучыларның «Аккош күле» бакчасындагы йортында. 1977 ел

Кемнең кем буласын балачагында да, яшьлегендә дә чамаларга мөмкин, әмма һәрвакытта да түгел. Шулай да Ркаил Зәйдулланың Хәсән ага Туфанга язган хаты, мәкалә атамасындагыча, чын Мәҗнүн каләменнән төшкәнлеккә шик уятмый. Хәер, автор үзен нәкъ шулай атый да. Ркаилнең тәүге әсәрләре үк камиллек, образлылык, ихласлылык, милләтпәрвәрлек, күпмедер пафослылык белән аерылып тора. Шул ук сыйфатлар аның иҗатында хәзер тагын да көчәйтелгәнрәк хәлдәдер. Мәктәп укучысы язган әсәрләр зур әдәбият ишеген талантлы, әзерлекле яшь каләм ачарга теләгәнне анык күрсәтә.

Ркаил хатының кечкенә генә тарихы да бар. Хәсән Туфан вафатыннан соң, архивын тәртипкә китерергә, дип, мине элек ул яшәгән фатирга җибәргәннәр иде. Бердән, мин аның төсле паста белән төрле кәгазь кисәкләренә язган шигырьләренә кереп баттым.



Ркаил Зәйдуллин. Чичкан авылы. 1977 ел



Сәлам Чувашстаннан.
Исәнмесез Хәсән ага!
Сезне борчып хат язганым өчен алдан ук гафу үтенәм.
Мин күптән түгел генә барыбызның да рухи башкаласы Казанда булып киттем. Октябрь бәйрәме иде, һәм мин шундый тантаналы бәйрәм көннәрендә Сезне борчып йөрисем килмәде.
Әйе шунда, мин бераз шигырьләр язгалыйм. Һәм алар турында сезнең фикерегезне беләсем килгән иде. Шуңа күрә берничә шигыремне хат белән сезгә җибәрергә булдым. Вакытыгыз кысан булса да бу нәрсәләргә карата шушы адрес белән фикерегезне язып җибәрегез әле?
429345 Чувашия АССР
Комсомольский район,
дер. Чичканы
Зәйдуллину Ркаилу Р.
Хушыгыз Хәсән ага, сезгә корычтай саулык теләп шигърият мәҗнүне Ркаил Зәйдуллин.
1977 ел. 9 ноябрь.

Икенчедән, алардагы үзен тоткынлыкка җибәргән режимны, хәтта Сталинны мактавын күреп гаҗәпкә калдым, коммунизмның җиңәсенә ышаныч, ул идеяләргә теләктәшлек тойдым. Дөрес, соңыннан Туфанның моңарчы басылмаган әлеге әсәрләрен мин беркайчан да беркайда да очратмадым.

Фатир хуҗасы, студент кына икәнлегемне – яшьлегемне күреп, якыннан белмәгәнлектән, архивны тәртипкә китереп бетерәсемә шик белән карагандыр, яңадан чакырмады. Бәлки, үзләренә ярдәм кулы сорап барган мөгаллимнәремнең зур эшне студентка гына тапшырып котылуларына үпкәләгәндер дә... Әллә миннән инициатива көттеме икән?.. Болары миңа билгесез. Дәшмәгән җиргә бару гадәтем юк, архивка көн эчендә дә шактый керә башлаган идем, ул эш шунда тукталды. Соңрак, белүемчә, бу төр ачы тәҗрибәне башка шагыйрәләр дә узган икән.

Яшьтәшләремнең Туфан мирасы өчен артык кирәкмәгән дип саналган әйберләр арасындагы шагыйрьгә язган хатлары белән танышу аеруча кызык тоелды. Хуҗабикәгә исә аларны барлау һәм саклау түгел, ә зур талант мирасын анализлау, нindidер эзгә салу мөһимрәк иде шикелле. Әнә шундый артыграк әйберләр арасыннан, якыннан белгәч, кызык күк тоелып, Ркаил Зәйдулла хатын үземә алган идем. Аңа бу турыда элегрәк күпме сөйләсәм дә, күп санлы папкаларым эченнән табып бирә алмадым. Инде менә, вакыты җитте, дигән кебек, хат үзеннән-үзе яңадан кулыма керде.

Әлеге хатта кайбер юллар, гыйбарәҗөмләләр яшел паста белән ассызыкланган. Димәк, Хәсән Туфан хат белән танышкан, шагыйрьнең анда язылганнарга ачык мөнәсәбәте булган. Зур шагыйрьнең отышлы, оригиналь рифмаларга, кыю

фикерләргә игътибар иткәнлеге күренә. Адресны ассызыклавыннан чыгып караганда, авторга җавапны йә язгандыр, йә язарга әзерләнгәндер кебек. Әллә соң бу хакта онытылмасын, хат яңадан кулга кергәндә, язарга тиешлегем, яшь каләм иясенең фикеремне көтүе исемә төшсен дип, Хәсән ага, үзенә хас булганча, яшел кара белән юллар астына сызып куйдымы икән?

Укучым, хатның сүзгә-сүз күчермәсе белән син дә таныш һәм уйлан. Укытучы дустым, син бүгенгебезнең гаҗәеп зур талант иясенең күңелендә тудырылган яшь образын үзеңнең өметле балаларың янәшәсенә куеп кара. Ркаилгә бит әле нибары 15 яшь икәнен онытма, ә инде ул чагында ук бернинди дәреслекләргә дә кермәгән Хафизлар, Хәйямнарны белә, алар иҗатындагы әдәби алымнарны, образларны актив куллана. Һәм... үзен Туфан белән хат алышырга лаек, өлгереп килгән каләм иясе итеп тоя. *«Илһам! Богау-зынҗырлардан котылып кил, / Сикәлтәле, авыр, озын юл булып кил»*, – дип теләгән Ркаил дустым. Бүген үзүзең алдында җавап тот: теләгәннәреңә ирештеңме?

Рифә Рахман

Ркаил Зәйдуллин – Хәсән Туфанга

СӘЛАМ ЧУВАШСТАННАН.

Исәнмесез Хәсән ага!

Сезне борчып хат язганым өчен алыннан ук гафу үтенәм.

Мин күптән түгел генә барыбызның да рухи башкаласы Казанда булып киттем. Октябрь бәйрәме иде һәм шундый тантаналы бәйрәм көнендә Сезне борчып йөрисем килмәде.

Эш шунда, мин бераз шигырьләр язгалыйм. Һәм алар турында Сезнең фикерегезне беләсем килгән иде. Шуңа күрә берничә шигыремне хат белән Сезгә җибәрергә булдым. Вакытыгыз кысан булса да, бу нәрсәләргә карата шушы адрес белән фикерләрегезне язып җибәрегез әле?

429345.
Чувашия АССР,
Комсомольский район,
дер. Чичканы
Зайдуллину Ркаилу Р.

Хушыгыз, Хәсән ага, сезгә корычтай саулык теләп, шигърият Мәҗнүне Ркаил Зәйдуллин.

1977 ел. 9 ноябрь

ТАТАРЛАР

Йә җиңелгән татар, йә җиңгән.
Х.Туфан

Татар каны ага тамырда.
Н.Арслан

Туган халкым – батыр татар халкы,
Шуңа күрә мәңге горурмын.
Катыйль алдында да, Җәлил кебек,
Тезләнмичә басып торырмын.

Сынатмастыр, сүрелмәстер күңел,
Дөрләр дә ул, балкып янар да.
Гаҗәп түгел, Тукай каны ага –
Татар каны ага тамырда!

Бу башлардан барсы үткәндер шәт,
Давыл булып күпме яу килгән?!
Тузан баскан ташлар сөйли башлый:
Йә җиңелгән татар, йә җиңгән.

Бу дөньясы яралганнан бирле,
Язмыш безне азмы кыйнады...
Беләзекне богау кысса кысты,
Югалтмадык әмма иманны.

Һәр гасырның ата шайтаны бар,
Урландылар кайбер өметләр...
Без һаман да татар булып калдык,
Бирелмичә калдык, егетләр!

КИЛ СИН, ИЛҺАМ

Кил син, илһам, кил, тарсынма күңелемне,
Рухыңны өр һәм җанландыр шигыремне.

Давыл-туфан, гарасатлар булып кил син,
Күкрәгемә Бөек Көрәш үзе керсен.

Урман шавы, көчле явым булып кил син,
Шигъри йөрәк табигатьтән аерылмасын.

Хәйямнардан, Хафизлардан калган касә,
Бер йотымны калдыр миңа, мин дә эчәм.

Бу касәгә җәннәт гүя үзе сыйган,
Хәйям-сакый үзе моңа шәраб койган...

Илһам! Богау-зынҗырлардан котылып кил,
Сикәлтәле, авыр, озын юл булып кил.

Ир-егетләр пошмас булып яталармы?
Авырлыклар куркытмыйлар татарларны.

Илһам, кил син. Беләгемә дәрман керсен.
Йөрәгемә күктән утлы шигырь иңсен...

ЗӘҢГӘР ЯШЬЛЕК

Һавалар нинди биек!
Мостай Кәрим

Офыкларга таба карап,
Яңа сукмаклар салдым,
Әмма күңелем, йөрәгем
Гүзәл бер илдә калды.

Барысы да матур анда,
Гаҗәеп гүзәл иде,
Томанга төренеп калды
Зәп-зәңгәр яшьлек иле...

Кул сузарлык җирдә генә
Зәп-зәңгәр яшьлек әнә,
Ап-ак томанын таратып
Кайтасы иде янә.

Болытлар күренми күктә,
Һавалар нинди биек!
Кайталмыйм әмма бу илгә,
Сагындым сине, диеп.
Их!

КАБЕРЛӘР

Күпме баһадирның кабере дә
Калмаган бит җирдә, димә, юри.
Дахауларда элеккечә тора
Мөҗәйләрне йоткан крематорий.

Крематорий суынып бетмәгән,
Кайнарлыгы аның бәрә йөзгә,
Шагыйрь белән мичтә гөрләп янган
Җырлар моңы үзәкләрне өзә!

Уттан яралганнар гына бары
Кызу ялкыннарга әйләнәләр.
Ә җаннары, кызыл гөлләр булып,
Пьедесталда ята бәйләм-бәйләм.

Күпме баһадирның кабере дә
Калмаган бит җир йөзендә, димә,
Берлиннарда элеккечә тора
Җәлил башын кискән гильотина.

Чәчкә тулы киң болыннар белән
Бу йөрәккә сыйган каберләр дә.
...Өзелеп калган моңны дәвам итеп,
Яңа җырлар туа бәгырьләрдә!

1977 ел ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

И, гомер агышлары...

Нәкыйп Каштанов

Гомер агышлары кызыклы да, сагышлы да. Дуслар белән очрашу, гамьле әңгәмәләр куерту, иҗади уңышлар һәм табышлар, ачышлар кешене рухландыра, аңа канатлар куйгандай итә. Ә инде туганнарны, якыннарны, дусларны югалтуны, аларның бу дөньядан үтүен барыбыз да бик авыр кичерә.

Билгеле ки, беребез дә бу дөньяга мәңгегә килмәгән. Шулай да бергә берегеп яшәгән, фикерләр уртак булган кешеләрне соңгы юлга озату сагышларына күнегеп булмый...

Шактый еллар элек, иҗат белән җенләнә генә башлаган вакытларым иде. Ялгышмасам, 1967 ел иде кебек. Язучылар берлеге бинасында яшь прозаик-шагыйрьләрнең очрашулары оештырыла башлады, бергәләп җыелып, әдәбият темасына гәп корабыз, бәхәсләшәбез, фикер алышабыз. Мин яшь шагыйрь Илдар Юзеевны беренче тапкыр шунда күрдем, танышып, сөйләшеп тә киттек. Без аның белән еш күрешә торган булдык. Ипекәйгә тамак туйса да, башка азык-төлеккә, кием-салымга кысынкырак яшәгән еллар иде ул. Балаларны үстерергә кирәк. Әлбәттә, тормыш мәшәкатьләре белән бәйле төрле борчулар саулыгын да какшаткандыр, Илдар Юзи еш кына минем белән үзенең сәламәтлеге хакында киңәшә...

Илдар Юзеев балалар матбугаты редакцияләрендә еш була, шигырьләрен калдыра. Минем дә «Салават күпере»нә килгәләп йөргән чагым. Илдар ага да бу басманы аеруча үз итә. Очрашабыз, сөйләшәбез.

Соңрак «Салават күпере»ндә Вакыйф Нуриев эшли башлады. Биредә шагыйрьне Вакыйф белән бергә Ләбиб Лерон, Фәрит Муллахмәтов зурлап



каршы ала. Нуриев тиздән минем дә редакциягә килеп җитәчәгемне әйтсә, Илдар Юзи, китмичә, көтеп тора. Ай саен шушы рәвешле бер-ике тапкыр күрешәбез. Очрашкач, сөйләшеп сүзләр бетми. Шагыйрь белән әңгәмә куертып утыру үзе бер ләззәт, дөньяның матур яклары күбрәк ачылып киткәндәй тоела. Икебезнең дә очрашудан күңелләребез мәмнүн була.

2003 ел иде. Илдар абый белән очрашып, бер-беребезгә эчке уйларыбызны бушатыштык, җаннар да тынычланып калгандай булды. Сөйләшеп утыру, күрәсең, шагыйрьнең күңеленә дә хуш килгән. Ул тиз генә каләм кәгазь алып, иң өскә «Нәкыйп Каштанга» – дип сызгалап куйды да 12 юллык шигырь язды.

«Салават күпере» редакциясендә бер очрашу хатирәсе булып, 2004 елда төшерелгән ошбу фоторәсем калды. Илдар Юзи, шушы күрешүдән соң озак та үтмәде, арабыздан китте, бакыйлыкка күчте.

Моңсу көннәрнең берсендә кулыма очраклы гына «Казан утлары»ның 1992 елгы 5 нче саны килеп керде. Ачып карый башладым. Шулчак шагыйрьнең «Ычкынырмын, ахры...» дигән юллар белән башланган шигыренә күзем төшеп, тетрәнеп киттем. Күрәсең, бу елларда Илдар Юзинең җанында тынычсызлык булган...

Редакциядән: Күренекле табиб, әдип, журналыбызның авторы **Нәкыйп Фәсхетдин улы КАШТАНОВ**ка 8 гыйнварда 75 яшь тулды! Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез! ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Әткәйнең сабаклары

Разил Вәлиев

«Әнисенә охшаган ир бала бәхетле була», – диләр бездә. Мин үземнең кемгә охшавымны кистереп әйтә алмыйм. Бер караганда, «әнкәйгә», дип әйтсәң, дөрестер сыман. Икебез дә бер үк көнне – 4 гыйнварда туганбыз, буй-сыным да әткәйнеке сыман ике метрлы баһадирдай буй-сын түгел, әнкәйгә тартым түгәрәк йөзле, базыграк гәүдәле булып яратылганмын. Шагыйранә холкым, үҗәтлегем, эшкә маһирлыгым, бәлки, алтын куллы әнкәй нәселеннән бераз күчкәндер. Әйе, язмышымның иҗат эше белән бәйле булуына, бәлки, үзе дә бәетләр чыгарган, әдәбиятка гашыйк әнием сәбәпчедер. Алайса, нишләп мин, һич көтмәгәндә, сәясәт дөньясына кереп киттем, бер-бер артлы төрле җаваплы урыннарда эшләдем соң? Журналның җаваплы сәркатибе, Язучылар оешмасы җитәкчесе, Милли китапханә директоры, Татарстан Дәүләт Советы депутаты һәм парламентның Комитет рәисе булдым. Болары, һичшиксез, әткәй язмышының дәвамы, аның үрнәге һәм тәрбиясе җимешедер.

Тәрбия, дигәннән… Ул атлаган саен акыл өйрәтеп, «вәгазь укып» иңдерелгән тәрбия түгел. Әткәйнең алай иркенләп «тәрбия дәресләре» үткәрергә вакыты да юк иде… Күмәк хуҗалык рәисенең эше таң атканда башланып кара төн җиткәч кенә бетә. Без аны бик сирәк күрәбез. Дөрес, әнкәй һәрдаим аның барлыгын искә төшереп тора: «Әтиең болай дип әйтте, тегеләй дип әйтте», – дип, әткәй исеменнән эш тә куша, тыңламый башласак, әткәйгә җиткерәсен дә кисәтеп куя. Кыскасы, өйдә тормаганда да әткәй

Исмәгыйль Вәлиев һәм Наил Хәмзин (күренекле юморист, язучы Алмаз Хәмзиннең әтисе)

һәрвакыт безнең янәшәдә кебек булды. Төшке ашка кайтканда яисә кышкы озын кичләрдә әткәй миннән чын-чынлап имтихан ала: бу арада ниләр эшләгәнмен, мәктәптә нинди белгеләр алганмын, соңгы арада нинди китаплар укыганмын һ.б. Кәефе килгән чакларда урындыкка бастырып миннән – алты яшьлек малайдан Такташның «Мокамай» шигырен сөйләтә. Җиде авылны берләштергән хуҗалыкның шундый олпат гәүдәле рәисе холык-фигыль ягыннан һич кенә дә гадәти җитәкчеләргә охшамаган. «Сугышка кадәр – бригадир һәм агроном, фронтта яраланып кайткач дистә еллар буе рәис булып эшләп, аның авызыннан ялгышып та сүгенү сүзе чыкмады», – дип сөйлиләр. Әткәйнең ачуы килгәндә әйтә торган иң зәһәр сүзе «саботажник» булган. Күрше Кәлимулла абыйның әнкәйгә зарланып торганы әле дә хәтердә: «Таһирәттәй, кичә эшкә чыкмаган идем, Исмәгыйль абый мине аты-юлы белән «саботажник» дип сүкте. Хәзер күзенә күренергә оят инде. «Саботажник», – диде бит, җир тишегенә керердәй итте». Гаҗәп: тозлап-борычлап, биш катлы итеп сүгенмичә хәтта ат белән үгезне дә тыңлата алмый торган заманда ул ни рәвешле җиде авыл халкын кулда тотты икән?!

Әткәй рәислек иткән чорда «Уңыш» колхозы унөч ел буе районда беренчелекне бирмәде, күчмә кызыл байрак, беркая да күчмичә, унөч ел буе идарә түрендә балкып торды. Бу уңышларны күреп һәм бәяләп, аңа «Хезмәт Кызыл байрагы» ордены тапшырдылар, велосипед, соңрак «Рекорд» телевизоры бүләк иттеләр. Ул заманда авылда велосипед бүгенге «Мерседес»ка тиң иде!

Әткәйнең «тәрбия алымнары» беркемнекенә дә охшамаган: ул кешене артык ачуланмыйча, ямьсез сүзләр әйтмичә эшләтә белә. Кечкенә генә бер уңышыңны күрсә: «Менә, минем улым булдыра бит!» – дип канат куя, аннан соң тагын да ныграк тырыша, дәртләнебрәк эшли башлыйсың. Ярамаган эшеңне

Гармун алдым кулыма...

күрсә дә кабынып китми, башын чайкый-чайкый: «Ай-яй-яй! Шулай ярыймыни? Безнең нәселдә булмаган хәл бит бу!» – дип җаныңа үтәрлек итеп әйтеп куя. Авыл халкы белән дә шундый кешелекле мөгамәләдә иде ул.

Әле дә хәтердә, өй каршында утырган бер әби белән исәнләшмичә киткән өчен ул миңа үтә гыйбрәтле сабак бирде: «Авыл кешесе гомер-гомергә бер-берсенә сәлам биреп, исәнләшеп яшәгән. Кешегә, аерата өлкән кешегә сәлам бирмичә узу – бик зур әдәпсезлек, тәрбиясезлек. Синең өчен миңа кызарырга туры килде. Аның башлап сүз кушуы: «Исмәгыйль үзенең малаен исәнләшергә дә өйрәтә алмаган», – дигән кебек булды». Шушы «сабактан» соң мин һәммә кеше белән исәнләшә торганга әйләндем.

Әткәй белән әнкәй холык һәм фикер сөреше ягыннан бер-берсенә һич тә охшамаган, алар икесе ике дөнья кешесе иде. Әнкәй заманында «кулак» ярлыгы тагылган, утызынчы елларда малымөлкәте таланып, колхозга тапшырылган хәлле нәселдән. Әткәй исә – авылның

Разил Вәлиевнең әнисе ягыннан әбисе белән бабасы

эш аты, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра торган гаярь токымнан. Әнкәйнең нәселнәсәбе бик дини. Әткәйнең дине – ленинизм тәгълиматы. Икесе ике идеология, ике иман кешеләре булса да, илгә, халыкка хезмәт итү, кешеләргә яхшылык эшләү, гадел һәм ярдәмчел булу аларны үзара охшаш итә, берләштерә иде.

Әткәйдә урлашу, хәрәмләшү кебек сыйфатлар бөтенләй юк. Әнкәй кайвакыт: «Кайтканда тарантасыңа берәр кочак печән дә салып кайтмыйсың», – дип киная белдергәндә, ул: «Мин бер кочак салып кайтсам, колхозчылар аны йөге белән урлаячак, ул чакта аларга ничек итеп авыз ачып сүз әйтим?» – ди иде. Хәтерлим: энекәшем Рәмзил прораб булып эшләгәндә авыл басуында ай буе хуҗасыз яткан бер өем чөгендерне, барыбер кар астында кала, дип машинасына төяп ишегалдына алып кайткан иде. Әткәй, моны белеп алгач, чөгендерне яңадан машинасына төятеп, алган урынына илтеп бушаттырды.

Кеше, никадәр генә мөстәкыйль булып, үз тормышын үзе җайларга, үз язмышын үзе язарга тырышса да, нәселнәсәбе, әти-әнисе салган юл-кысадан әллә ни читкә чыга алмый торгандыр. Гасырлар буе буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәт, йола һәм әхлак тәрбиясе моңа ирек бирмидер. Мин әнкәйнең дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен, кешеләргә мөнәсәбәтен күреп үстем, аларны, үзем дә сизмәстән, күңелемә өлге итеп алдым. Әткәй мине бәдәни яктан да, рухи яктан да көчле булырга өйрәтте.

Ишле гаиләнең бер бик яхшы үзенчәлеге бар: ата-ана тәрбиясе өстенә, биредә балалар да бер-берсенә тәрбия бирә, үпкәләтмичә генә бер-берсенең ялгышын төзәтергә, читтән кыерсытучы булса, бер-берсен якларга, берберсеннән өйрәнергә тырыша. Авылда ел әйләнәсендә эшнең очы-кырые юк. Безнең гаиләдә һәр бала өчен әткәйәнкәй тарафыннан эш бүленеп куелган иде. Кемнең нәрсә һәм ничек эшләгәнен күз уңында тоту, безне эшкә өйрәтү – олы апабыз Равиягә йөкләнгән. Өйдәге чисталык һәм тәртип өчен ул җаваплы. Разилә апа, хислерәк, хыялыйрак булганга, күп вакытын китап укып, шигырь ятлап, рәсем ясап үткәрә. Ул гармун да тарткалый, шигырьләр дә яза. Әнкәйгә багышланган беренче шигыремне дә аның сүзен тыңлап язган идем мин. Өченче туганыбыз Рәмзинә, бик иртә әткәй-әнкәйнең кул астына кереп, алар

кушкан һәр эшне җиренә җиткереп эшләргә өйрәнде. Үсеп җиткәч, ярты илне гиздe, һәр җирдә хөрмәткә лаек булды. Дүртенчебез Рәфика бәләкәйдән үк гаҗәеп җор телле, шулай ук әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк бала иде. Шуңа да Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетына барып керүе беркемне дә гаҗәпләндермәде. Бишенчебез Резедә баскан җиреннән ут чыгара, тоткан җиреннән өзә торган тәвәккәл холкы белән гомер буе безне шаккатырып яши. Иң кече сеңлебез Рания дә шагыйранә җанлы. Безнең гаиләдә, бәетләр, такмаклар чыгарган әнкәйдән тыш, Разилә апа, Рәмзил энем һәм Рания сеңлемнең күңелләренә иҗат оеткысы салынган, киләчәктә аларның шигырьләрен туплап, үземнекеләрен дә өстәп бер җыентык чыгарырга да исәп бар әле.

Боларны ни өчен шулай тәфсилләп язам соң? Гаиләдәге сигез бала – сигез төрле холык, сигез төрле сәләт... Мин җиде баланың бер-берсенә (шулай ук үземә дә) тәэсирен тоеп, җидесеннән җиде төрле һөнәргә, җиде төрле осталыкка өйрәнеп үстем. Бүгенге холык-фигылемдә, кылган гамәлләремдә, ирешкән уңышларымда, һичшиксез, аларның өлеше зур.

Әткәй барыбызны да тигез күрде. Беркемгә дә артыграк игътибар бирмәде, артыграк иркәләмәде. Үзара ыгы-зыгы чыгып үпкәләшкәндә дә безне килештерү җаен таба иде. Зарланып янына килсәң: «Урамда тик торган баганага берәү дә килеп бәйләнми, үзеңдә дә гаеп булгандыр», – дип, баштан сыйпап юата. Олпат гәүдәле булганга гына түгел, менә шундый кече күңелле, олы җанлы булганга да аны «Олы Исмәгыйль» дип йөрткәннәрдер инде авылда.

Әле дә Ташлыкта әткәй белән игезәк сыңары Ибраһим абый турында: «Егет чакта ике потлы герне ырыс капкасы өстеннән ыргытып уйный торганнар иде», – дип сөйлиләр.

Унсигез яшь тулганда өйләре янып көл булгач, әткәй Донбас шахтасына китеп, бер ел күмер чаба, аннары авылга кайтып өр-яңа өй җиткерә. Ә инде хуҗалык рәисе булып эшләгәндә төзегән йорт-кураларын санап бетерерлек түгел, билгеле.

Сугышны башыннан ахырына кадәр диярлек кичеп, ике тапкыр яраланганнан соң култык таяклары белән авылга кайтып егылса да, ул, нигәдер, фронт хәлләрен җәелеп сөйләргә яратмый иде. «Сөйлә инде, безгә кызык бит», – дигәч: «Нәрсәсе кызык булсын кеше үтерүнең?!» – дип моңаеп кала иде. Шулай да беркөнне ачылып киткәне истә калган: *«Сугышның кызган чагы, инде атнага якын ут астында окопта ятабыз, ике яктан аталар да аталар, башны күтәрерлек түгел. Озакламый ашарга икмәгебез бетте. Атыш бераз тынып торган арада взвод командиры бер солдат белән мине ипи алырга җибәрергә булды. Полк ашханәсенә бер чакрым чамасы барасы. Шуыша-шуыша киттек. Ярты көн шуышканбыздыр. Без барып җитүгә, окоплар ягында тагын атыш башланды, бер-бер артлы бомба ташлап, самолётлар очып узды. Атыш туктагач, җилкәгә берәр капчык ипи салып сөенә-сөенә кайтырга чыктык. Кайтып җитсәк... окопта үле тынлык – өсләренә бомба төшеп, взвод тулысынча һәлак булган. Үзебез елыйбыз, үзебез алып кайткан ипине ашыйбыз. Тозлы күз яшьләренә чыланган ипи аңкауларны, үңәчне, эчне яндыра. Әле хәзер дә авызыма ризык алсам, шушы көн искә төшә. Ипидән тозлы күз яше тәме килгәндәй була. Бәлки, шуңа да кадерледер безгә бу ипи-ипекәй...»*

Кулга автомат түгел, ә каләм алып, сугышның иң кызган вакытында – 1985 елда – Әфганстанга барып чыгуым, 1995 елда чечен-ингуш халкына гуманитар ярдәм төялгән самолёт белән юлга кузгалуым да әткәйнең сугыш хатирәләренә барып тоташа торгандыр. Язмышлар кабатлануы, буыннар дәвамчылыгы шушыдыр инде ул.

Никадәр тыныч, сабыр холыклы

Разил Вәлиев әти-әнисе һәм якын туганнары белән

булса да, аның бер «каешлы сабагын» искә алмасам ярамас. Дүртенче сыйныфны тәмамлаган ел иде. Көннәрдән беркөнне биш-алты яшьти җыелыштык та, үзебезнең башлангыч мәктәпне тәмамлап, «егет» булып җитүебезне күрсәтергә булдык. Безнеңчә, егет кеше, һичшиксез, тәмәке тартырга тиеш иде. Миңа тәмәке табу, дөресрәге – әткәйнең бер кап «Север» папиросын чәлдерү бурычы йөкләнде. Җыелышып басуга чыктык та, баш әйләнеп күз тонганчы, бер кап папирос беткәнче «рәхәтләнеп» төтәттек. Өйгә ничек кайтып җиткәнне хәтерләмим. Әмма әткәйнең беренче мәртәбә йомшак җирне каеш белән «сыйлаганын» мәңге онытасым юк. «Беренчедән, папирос урлагансың. Караклык – ул иң начар гадәт. Икенчедән, тәмәке тарткансың. Мин тартканга карама син, мине сугыш өйрәтте, үлем күзенә карап окопта яткан көннәр өйрәтте, ә сине кем өйрәтте?» – дип ярсый-ярсый кабатлады ул. Бу – чынлап торып беренче һәм соңгы мәртәбә тәмәке тартуым булды, арт сабагымны укыткан өчен мин әткәйгә гомер буе рәхмәтле булып калдым. Шуннан соң озакламый әткәй дә тартуын ташлады.

...Туган якка бер кайтуымда авыл картлары белән иркенләп гәпләшеп утырган идек. «Әтиең колхоз рәисе булып эшләгәндә җиде авылның биш мең гектар сөрү җире бар иде. Без шул җирне, бер аршын да калдырмыйча, сугыш елларында да үгез җигеп сукалый, тырмалый, чәчә, урак белән ура-җыя идек. Әтиең, буш җир калмасын, дип, хәтта багана төпләрен дә көрәк белән казыта иде... Хәзер дә шул ук биш мең гектар җир. Ыжгырып торган машина-тракторларның, комбайннарның исәбе-хисабы юк. Шулай да җиребезнең яртысы буш ята, анда чүп-үлән, куак-агачлар котырып үсә. Бу мәхшәрне әтиең күрсә, йөрәге ярылыр иде», – дип зарланды алар. Шулчак арадан берсе: «Җир кадере, кеше кадере бетте шул хәзер. Мондый илнең бәхете булырмы икән?!» – дип уфтанып куйды...

Язмамны: «Әнисенә охшаган ир бала бәхетле була», – дип башлаган идем. Халык белмичә әйтмидер, бу сүзләрдә өлешчә хаклык бардыр, билгеле. Минемчә, чын бәхет ул Кеше кадерен, Җир кадерен белгән җәмгыятьтә генә була торгандыр. Мин шундый гаиләдә туып үстем. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Рәхмәт аңа!

(Нияз Даутов турында истәлекләрем)

Рафаэль Сәхәбиев

Әйе, һәр заманның үз шәхесләре, үз мәшһүрләре була. Яңа буын килә, искесе онытыла төшә. Яшьләр үзләрен элеккеләргә караганда талантлырак, дип уйлый. Мин дә шулай уйлыйм шикелле. Бездән алдагылар да үзләренә кадәргеләрне талантлырак, дип санагандыр. Ә бит, ныклап уйлап карасаң, бу бик үк дөрес түгел. Минемчә, корган планнарыбыз, эшлисе эшләребез алдагыларныкы белән чагыштырып эшләнә.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

Нияз Даутов

Мин эшләгән Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында безгә кадәр бик күп шәхесләр хезмәт иткән. Аларның күбесен инде онытып барабыз. Ә кайберләрен оныттык та бугай. Менә шундый шәхесләрнең берсе – РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның халык артисты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, танылган җырчы, режиссер һәм педагог, профессор Нияз Курамша улы Даутов (1913-1986).

Нияз ага Даутов үз заманында, үз чорында бик популяр иде. Гомеренең соңгы елларында ул безнең театрда баш режиссер булып эшләде. Казанда туып үскән, Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлаган. Станиславский һәм Немирович-Данченко исемендәге театрда эшли башлаган. Матур тавышлы бу талантлы егетнең планнарын сугыш боза – ул 1943 елда Мәскәүдән Свердловскига китәргә мәҗбүр була. Иҗат гомеренең иң данлыклы еллары шундагы Опера һәм балет театрында үтә. Нияз аганы анда бик яраталар, мәшһүребезнең режиссерлык эше дә шунда башлана. 1953 елда ул Урал консерваториясен тәмамлый.

Нияз ага Свердловск киностудиясендә 1944 елда Союз күләмендә танылган артистлар белән төшерелгән «Сильва» опереттасында уйный – баш рольдә (Эдвин). Кинофильмны караган кешеләр белә: анда Нияз Даутовның өлеше искиткеч зур. Чибәр кеше, көдрә чәчле, матур тавышлы... Шуның белән ул бөтен Советлар Союзына билгеле кешегә әйләнде.

1965-1975 елларда мәшһүребез Чиләбе опера һәм балет театрында баш режиссер булып эшли. Аннары Нияз аганы Казанга ул вакыттагы Өлкә комитетының беренче секретаре Фикърәт Табеев чакырып кайтарды. Аның театрга баш режиссер булып кайтуы безнең – юньле режиссер күрмәгән артистлар өчен, әйтеп бетергесез бәхет, олы куаныч булды. Нияз ага, җиң сызганып, бер үк вакытта Казан дәүләт консерваториясендә дә эшли башлады. Без моңарчы күрмәгән, белмәгән эшләр, укулар башланды. Үзендә укыганнарны туп-туры театрга эшкә ала иде ул. Без аның ничек киенүенә, йөрешенә соклана идек. Нияз аганың режиссер буларак бер шәп ягы бар: ул һәр артистка уйнап, йөреп күрсәтә, ә бу исә яшь артистка эшен җиңеләйтә иде. Җырлаганда гел матур итеп җырлау турында гына уйламагыз, образ белән барыгыз, шунда гына тавыш үз урынына эләгә, дип һәрчак әйтеп килде ул. Аның икенче бер зур эше: Нияз ага яшь герой-героиняларны (әйтик, Евгений Онегин белән Татьянаны) яшьләргә уйнарга бирә иде. Элекке чорларда яшь кызларны – картаеп беткән әбиләр, яшь егетләрне симез абзыйлар уйнаган. Нияз ага әлеге мәгънәсезлекне бик тиз туктатты. Әлбәттә, өлкән артистларга бу ошап бетмәде...

Нияз Курамша улының белмәгән нәрсәсе юк иде. Ул бик күп укыды. Аеруча классик әсәрләрне яратты. Укырга комачаулый, дип, шактый вакыт телевизор алмады. Рәсем сәнгатеннән яхшы

«Сильва» фильмының афишасы. Төп рольләрдә Зоя Смирнова һәм Нияз Даутов. 1944 ел

хәбәрдар булды. Фатирындагы диварда нинди генә картиналар юк иде! Безне – яшьләрне өенә еш чакырды, төрле-төрле фраклар, күлмәкләр, бантлар бүләк итте. Миңа Святослав Рихтерның Парижда тегелгән, «Рихтер» дип аталган күлмәге эләкте. Бик тәмле итеп пешерелгән ашлар белән сыйлый иде безне Нияз ага. Әйе, ул аш пешерергә дә бик маһир иде! Кыскасы, талант!

***

...Нияз аганың җәсәден Актерлар йортына куйдылар. Мин шунда бер олы артисттан сорыйм: нишләп әле иртә китәсең, җирләргә бармыйсыңмыни, дим. «Юк, мин аның үлеме дөресме икәнен генә белергә килдем!» – диде дә китте...

Арабызда менә шундый кешеләр булганда, зур-зур шәхесләребез ничек онытылмасын инде?!

Бервакытны телестудиядә чагында шундагы бер хезмәткәр тирләп-пешеп килеп керде дә: «Наконец-то Даутовның бер язмасын да калдырмыйча сөртеп бетердек», – диде. Шатлыгы йөзенә чыккан. «Нишләп шундый әшәкелек эшләдегез?» – дигәч, пленка җитми, пленка юк бит эшләргә, ди. Йа, Хода! Шундый кешеләр кулына калса, безнең мәдәни мирасыбыздан бернәрсә дә калмас...

Яңадан Нияз аганың яхшылыгына тукталыйк. Яшьләргә бик ярдәмчел иде, мәрхүм. Алар өчен фатир сорап яисә башка мәсьәлә белән Өлкә комитетына еш керә иде. Бервакыт Хәйдәр Бигичев чирләп китте. Нияз ага Мәскәүдәге дуслары (ялгышмасам, С.Рихтер иде шикелле) аша Хәйдәргә операция ясаттырды. Хәйдәр шуннан соң күп еллар яшәде, уңышлы эшләде.

Нияз ага бервакытта да безне онытмый иде. Мин читтагы ялга киткәч, телеграмма суккан: «Рафаэль, тизрәк килеп җит, сиңа фатир бирәләр!» – дигән...

Нияз аганың яшьтән үк алып барган көндәлекләре бик матур, бик кызык эчтәлекле иде: үзенең беренче укытучысы белән хат алышуын, аның белән иҗат планнарын уртаклашуын, кемнәр, нинди артистлар белән эшләвен – барысын да бәйнә-бәйнә тасвирлаган, язган. Кешене тәрбияли, аңа сабак бирә торган сүзләр, дип саныйм мин әлеге көндәлектәге язмаларны. Нияз Курамша улының көндәлекләрен, хатларын Татарстанның халык артисты Эдуард Трескин бик яхшы белә. Актерлар йортында аларны ничәмә мәртәбә укыды ул. Рәхмәт аңа!

Нияз аганың яхшылыклары турында бик күп язарга була. Сүземне йомгаклап, опера сәнгатенә керткән эше һәм яңа кадрлар әзерләгәне өчен, Нияз ага Даутовны һәрчак искә алырга, һичкайчан онытмаска кирәк, дим.

Редакциядән: автор сөйләгән истәлекләрнең видеоязмасы һәм «Сильва» фильмы белән www.beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ИЛЧЕ КҮЧТӘНӘЧЕ

Равил Вәли

Салих Сәйдәшев

Татар музыка сәнгатенең иң асыл һәм олпат вәкиле була торып, Сәйдәш театр бинасына терәп салынган янкормадагы кысан гына фатирда яшәде. Кухня – тар, бәдрәф-фәлән кебек уңайлыклар – ишегалдында... Әмма, яшәү шартларын яхшыртуны үтенеп, ул бер түрә каршына да бил бөгеп бармады. Ә аңа исә үзләре теләп ярдәм кулы сузучылар табылмады.

Ләкин Сәйдәш зарланмады.

Әйе, фатиры кысанын кысан. Аның каравы, күпкатлы, күп подъездлы, юка стеналы биек йортларда яшәмәгәч, күршеләрне музыка авазлары белән борчудан курыкмыйча, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында рәхәтләнеп иҗат белән шөгыльләнергә мөмкин. Композитор яки музыкант кешегә монысы – иң мөһиме.

Өстәвенә, ул үзәктә яши. Опера һәм балет театры да, консерватория һәм музыка училищесы да, татар радиосы һәм башкалары да янәшәдә генә. Җитмәсә, иҗат итеп арыгач, бераз һава сулап керү өчен якында гына парк-бакчалары бар.

Сәйдәш аеруча ак колонналы Казан университеты каршындагы Ленин бакчасында йөрергә ярата. Биредә кая карама – яшьләр. Алар, кулларына портфель тотып, лекцияләренә ашыгалар.

Студентлар сукмагы читендәге озын элмә такталарга дистәләгән яңа гәҗитләр ябыштырып куелган. Иң беренче эш итеп, Сәйдәш тә әнә шундагы көндәлек яңалыкларга күз йөртеп үтәргә ярата. Күп басмалар, аеруча Казанда нәшер ителә торганнары, тиздән Куйбышев ГЭСы сафка басачагы турында хәбәр иткәннәр. Хәзер су астында калачак авылларны, тарихи ядкярләрне тикшерү, күчерү эшләре башланып киткән икән. Тиздән, бу мәсьәләләрне җентекләп күздән кичерү өчен, Казан галимнәреннән торган гыйльми экспедиция Идел Болгарстаны якларына чыгып китәчәк, ди.

Тарихчы галим булмаса да, никтер, Сәйдәш бу хактагы хәбәрләрне кат-кат укыды. Кайсыдыр күңел кылларына кагылып үттеләр, күрәсең.

Сәйдәшне Ленин бакчасына еш әйдәгән тагын бер сәбәп – бирегә якын гына Фәннәр академиясенең Казан филиалы бинасы урнашкан. Ә анда Сәйдәшнең күптәнге танышы – тарихчы галим Хәйри Гыймади эшли. Бер килгәч-килгәч, теге экспедиция турында күбрәк беләсе килеп, ул әнә шул дусты янына да кагылып чыгасы итте.

Юраганы юш килде Сәйдәшнең! Хәйри Гыймади да, тарихчы галим буларак, әнә шул фәнни сәфәр составына кертелгән икән. Алай гына да түгел, бар дөньясын онытып, хәзер әнә шул экспедицияне оештыру эшләре белән мәш килеп йөргән көннәре икән!

Хәйри Гыймади Сәйдәш дустын кош тоткандай балкып каршы алды:

– О-о!.. Салих ага!.. – дип, күрешер өчен ул аңа ике кулын сузды.

– Саумы, бәгырь!

– Гомерегез озын булыр, ахрысы. Менә нәкъ сезнең хакта уйлап утыра идем әле, Салих ага!

– Минем хакта?.. Нәрсә?.. Әллә берәр фәнни гамәл көтеләме?

– Дөрес әйтәсез... Гамәлнең дә нindие әле! – диде ул, дулкынланып. – Бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына, дигәндәй, бик вакытлы килдегез, Салих ага!

– Яле, алайса... Ишетеп карыйк, Хәйри бәгырь!.. Ни-нәрсә чыгарып куймакчы булалар икән минем юлыма?

– Ленин бакчасындагы көндәлек басмалар каршыннан үткән булсагыз, үзегез дә укып беләсездер инде...

Илче, шагыйрь, драматург Хәбибулла Фәтхуллин

– Булачак гыйльми сәфәр турындамы?

– Менә-менә... Ничек?.. Бәлки сез дә безгә ияреә алырсыз, ә? Ашау белән юлда йөрүләр бушлай дигәндәй...

Оҗмахка төртеп кертмиләр бит – Сәйдәш тизрәк ризалашу ягын карады:

– Алайса, мин бик риза да бит... Тик... композитор кеше анда, Идел буенда, диюем, нинди генә файда китерә алыр икән соң?

Хәйри Гыймади аңа кискен каршы төште:

– Китерәчәк... һәм ничек кенә китерәчәксез әле! Тиздән, бик тиздән сусаклагыч диңгезе астында каласыларын сизеп ыңгырашкан дулкыннар сезгә Идел буйларының ерак үткәне, изге Болгар җирләренең бай кичәгесе турында бик күпне сөйләп бирә алачак, минемчә.

– Мин дә шулай уйлыйм, шуңа өметләнеп, ерак сәфәргә чыгарга әзермен. Кайчан кузгалырга, бәгырь?

– Тагын берничә көннән.

– Шулай тизме?!

Галим кешенең сүзләре бетмәгән иде әле:

– Кабатлап әйтәм: Куйбышев ГЭСын төзүгә юнәлтелгән бик кайнар көннәр хәзер. Гәҗит-журналлар да, радио да, изгән дә баскан, дигәндәй, гел шул хакта сүз алып бара. Гидростанциянең үзен төзү әле бер хәл. Аның бит әле су астында калачак галәмәт күп җирләрен күздән кичереп чыгарга кирәк. Куйбышев ГЭСының мул җәелгән ул суы, Идел елгасы буйлап күтәрелеп, Татарстанның да күпмедер җирләрен каплап алачак. Анда исә искиткеч күп тарих серләрен яшергән борынгы Итил, изге Болгарстан...

Хәйри Гыймади, бераз туктальп тын алып торгач, соклану катыш сорап куйды:

– Салих ага, унөченче йөз галиме Мәхмүд Кашгарый сүзлегеннән борынгы Итилебез турындагы гаять атаклы һәм музыкаль аһәңле теге юлларны бәлки сез дә укып беләсездер, ә?

– Атаклы һәм музыкаль, дисезме?.. Ә-ә... Әйе, әйе! Гаҗәеп аһәңле юллар: «Итил суы ака торур, кыя төби кака торур...» Дөрес әйтәмме?

Хәйри Гыймади шулчак татлы хыялга бирелеп алды:

– Менә-менә... Бәлки без дә ерак сәфәрдән берәр опера яки балет кебегрәк яңа музыкаль әсәр ияртеп апкайта алырбыз әле, ә, хөрмәтле Салих ага?

– Ай-һай, Хәйри бәгырь... Артык зурга үрелмибезме икән?

– Ә нәрсә?.. Изге Болгар җирендә опера яки балет язарлык тарихи темалар җитәрлек минемчә.

– Анысы шулайдыр да... Ләкин эш бит менә нәрсәдә, бәгырь...

Хәйри Гыймади колакларын сагайтты:

– Нәрсәдә, Салих ага?

– Опера кирәксә, Нәҗип Җиһановка дәшәрсез инде, Хәйри бәгырь!– диде Сәйдәш кистереп. – Бу жанрны мин үзем өнәп бетермим. «Тәтәй бара – мин дә барам, мин тәтәйдән ник калам?» – дигәндәй, көнбатыш композиторлары һәм аларга тагылган урыс операларына ияреп йөрисем килми. Минем үз җанымнан, үз холкымтабигатемнән өзелеп төшкән үз жанрым бар. Ул – халыкчан, озын һәм моңлы көйләр, музыкаль спектакльләр!.. Ә менә тиешле тарихи тема табылса, балет хакында уйлап карарга була.

– Табылыр ул тарихи тема, табылыр... Мин моны сезгә күптәнге фикердәшегез гена түгел, тарихчы галим буларак та әйтәм!

– Шулай дисезме?..

Ике дус, ике фикердәш, хәерле сәфәр теләп, бер-берләренең кулларын кысышты.

***

Экспедициянең тулы хокуклы бер әгъзасы сыйфатында, Сәйдәшкә дә җилкә аша киелә торган озын каешлы кыр сумкасы бирелде. Шуңа тиешле нота билгеләре язылачак кәгазь-карандашларын салып, ул һәр көн иртән Идел буйларына чыгып китә торган булды. Бер-бер артлы тәгәрәшеп килгән дулкыннарның, аларның ярга шап та шоп бәрелгән авазларын тыңлый-тыңлый, ул көн дә дистәләгән чакрымнар үтте. Ерак гасырлар серләрен үзләренә сеңдергән әлеге дулкыннар Сәйдәшкә Гөлнара дигән борынгы татар кызының кайнар гыйшыклы тормышы турында бик тәфсилләп сөйләп бирде.

Дөрестән дә, композитор булган кешегә зур су, озын су ярларын иңләп-буйлап йөрүләр дә бик кирәк икән! Нинди генә авазлар җыелмасы ишетелми анда йөргәндә! Ул дулкыннар нәкъ кеше табигате кебек: көчле җил-давыл купса, шомлы ыңгырашу тавышлары чыгарып, ярга ыргылалар; җил тынып калса, алар да сүнәләр-сүреләләр...

Хәер, зур елга, зур су буйларында туган мондый хисләр Сәйдәш өчен күптән таныш иде инде. Чөнки ул бик тәҗрибәле һәм һәвәс балыкчы да иде. Дөрес, Сәйдәш заводфабрикалар чолганышында калган Казансу елгасы тирәсендә кармак салып утыруны бигүк өнәп бетерми: бердән, суы чиста түгел; икенчедән, театр хәтле театрның оркестр дирижеры буларак, гел тамашачылар каршында басып торгач, аны күпләр танып белә. Шуларның кайбер әрсезләре төрле сораулар биреп йөдәтмәсен өчен, Казанга якын тирәләрдән ераграк йөрергә тырыша.

Аның иң яратып балык тоту урыны – Идел аръягындагы Кызыл Байрак авылы. Биек яр өстендә суга терәлеп диярлек торган бу авылның барлыкка килүе дә бик гыйбрәтле. Мәгълүм ки, 1552 елда Казан яулап алынгач, Явыз Иван татар авылларын Итил, Чулман, Агыйдел кебек зур су буйларыннан сөрдергән. Ә узган гасырның революциядән соңгы егерменче елларында әлеге бушап калган әкияти гүзәл урыннарга кабат татар гаиләләрен күчереп утырту мөмкинлеге бирелә. Шөкер, татарның яңа оешкан дәүләт җитәкчеләре бу мөмкинлектән бик нәтиҗәле файдалана. Әлеге җитәкчелар арасында яшүсмер Сәйдәшнең җизнәсе Шиһап Әхмәров тә була. Ул күчеп утыручыларга кредит ярдәме күрсәтүче дәүләт оешмасын да җитәкли. Әлбәттә

инде, яңа калыккан йорт-каралтылар арасында аныкы да була. Җәйге ял вакытларын биредәге гүзәл табигать кочагында үткәрә башлагач, Сәйдәш өчен дә күк капусы ачылып китте.

Идел суын берничә турыдан бетон дамбалар ярып кергән. Шулар буенча атлап кереп, Сәйдәш тирән һәм тын урыннан беләк буе бәртәсләр, буй-буй сызыклы матрос күлмәкләре кигән алабугалар, юан-симез тәнле сазаннарны тота торган булды.

Ә тегеләй дә болай үтеп торган теплоходларның гудокларын кычкыртып узулары, аларны зәңгәр күктә канатларын җилпи-җилпи озата барган акчарлакларның моңлы тавышы... Боларның һәммәсе дә композитор кешедән җыр язуны таләп итә.

Кеше уракта, ә ул балыкта, дип уйламасыннар өчен, Сәйдәш экспедициягә кармакларын алып тормаган иде. Һәм дөрес эшләгән булып чыкты. Мондагы яр буйларында аңардан тыш та җирле балыкчылар җитәрлек булып чыкты. Тиздән, туган авыллары белән берлектә, алар да яңа төбәкләргә күчеп китәчәк. Шуңамы, күпләре моңсулар!

Ә берсе балыкка уч төбенә сыеп бетәрлек кенә нәни транзисторын алып килгән. Шуны ком өстенә җайлап-көйләп куйган да, бөтен дөньясын онытып, үзе яраткан көйләрне тыңлап утыра.

Менә соңгы елларны Камал театры сәхнәсендә зур уңыш белән барган «Күзләр» пьесасыннан Рәйсәнең «Хуш, авылым!» исемле беренче җыры яңгырый башлады. Ул – озак еллар чит дәүләтләрдәге СССР илчелегендә эшләүче яшь драматург һәм шагыйрь Хәбибулла Фәтхуллин белән композитор Салих Сәйдәшевнең уртак иҗат җимеше. Халыкчан-озын сулышлы бу моңлы көй тамашачы мәхәббәтен бик тиз яулап алды:

Туган җирем, сөйгән авылым
Бигрәк якын күңелгә.
Кай илләрдә яшәсәм дә
Оныта алмам гомергә.
Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт
Таң җилләре искәндә.
Мин җырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

Балыкларга озын-моңсу җырлар тыңлатып, кармак салып утырган бу агай кинәт Сәйдәшкә бик якын булып китте. Аның бит үзен дә еш кына балыкчылар су буенда бигүк килешеп бетмәгән шөгыль белән тоткалыйлар иде. Имеш, тавышланырга ярамый торган җирдә Сәйдәш гел авыз эченнән генә нидер көйләп утыра!

Аңа:

– Керәсе балыкларны куркытып бетерәсең бит, тукта инде! – дип тә карыйлар.

Сәйдәшнең исә андыйларга тапкыр җавабы һәрчак әзер:

– Менә шулай көйләп-сызгырып дигәндәй, киресенчә, мин балыкларны үз яныма тылсымлап китерәм!

Тотылган балыкларны санап карыйлар. Дөрестән дә, Сәйдәшнеке бүтәннәрнекеннән һәрвакыт күбрәк килеп чыга!

Менә аңа иптәшкә Идел ярында тагын бер сәер балыкчы табылды!

Дәвамы бар ■

Сорнай, гөслә, күчнай...

8 декабрьдә Казанда «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы кысаларында «Татар халкының музыка уен кораллары: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» дигән күргәзмә тәкъдим ителде. «Корстон» бинасында оештырылган бу чарага зур кунаклар килде. Шулар арасында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та бар иде.

Оештыру эшләрен Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе Фәнзилә Җәүһәрова, фәнни хезмәткәрләр Эльмира Каюмова, Гөлназ Гыйлемҗанова башкарды. Милли уен коралларының бай мирасын татар эшмәкәрләренә күрсәтү нияте белән Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров чыккан иде. Матди якны да конгресс үзе күтәрде.

Күргәзмәнең үзенчәлеге шунда ки, тупланган экспонатларны башка музейларда даими күрү мөмкин түгел,

Күргәзмәнең олуг кунагы – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов

«Риваять» этно-төркеме чыгыш ясый

Г.Сәгыева фотолары

Кыллы уен коралларының ниндие генә юк!

чөнки алар аерым белгеч һәм башкаручыларның шәхси тупланмаларыннан алынган. Зур кыйммәткә ия булган үрнәкләрне Рәгъде Халитов, Дамир Габдрахманов, Геннадий Макаров, Рәшит Мостафин, Ринат Гыйләҗев һәм ошбу язма авторы тәкъдим итте. Шулай ук Самара өлкәсе осталары тарафыннан ясалган гармуннар да үз урынын алган иде.

Уен коралларының урнашуы хронологик тәртипкә корылды. Өрмәле музыка кораллары – төрле-төрле таш сыбызгы, курай, сорнай, быргылар игътибарны аеручa җәлеп итте.

Бәрмә һәм үзе яңгырый торган уен кораллары – кубыз (тимер һәм агачтан эшләнелгән варган), каравылчы шалтыравыгы, дөмбери (бубен) кебекләр аерым бер күргәзмәне тәшкил кылды.

Кыллы уен коралларыннан исә ятаган, гөслә, кыл кубыз, думбра, скрипкә, мандолинаны күрергә була иде.

Алар экспозициянең үзәгендә урнашып, килүчеләрнең күз явын алып тордылар.

Аерым стенд гармуннарга багышланды. Гармун, татар мәдәниятенә XIX гасырның икенче яртысында гына килеп керсә дә, чын милли уен коралына әверелгән.

Фәнни куратор буларак, янә шунысын әйтәсем килә: күргәзмә барлык җыелган үрнәкләрне дә үз эченә сыйдыра алмады. Шуңа күрә, «иң-иңнәр»не генә сайларга туры килде. Һәрбер экспонат – кабатланмас, уникаль әйбер. Берничәсен генә атап үтәм. Өрмәле кораллардан: балчык най – 1976 елда Казан Кремлендә археологик казылмалар вакытында табылган таш сыбызгы (XII гасыр чамасы); кучнай – кушылган сыбызгылар, Пана флейтасының милли төре. Күп кыллы чиртмәле музыка кораллары рәтеннән 2015 елда Мари Илендә табылган ике яклы гөслә һәм Әстерхан татарларының думбрасы да игътибарга лаек (аның кыллары сарык эчәкләреннән ясалган).

Чарада музыка уен кораллары тавышын да ишетергә мөмкин иде. Мәсәлән, танылган «Риваять» этно-төркеме чыгыш ясады.

Күргәзмәнең максаты татар халкының уен кораллары белән таныштыру гына түгел иде. Музыка коралларын ясау һәм аларда уйнау традицияләренең бүгенге шартларда югала баруы – гаять борчый торган мәсьәлә. Фәнни эзләнүләр дәвам итсен өчен сыйфатлы техник кулланмалар сорала. Киләчәктә буыннар арасындагы җеп өзелмәсен иде. Күргәзмәнең эпиграфы итеп, Фатыйх Хөснинең: «Өзелгән кылдан өзек җыр чыга...», – дигән сүзләре юкка гына сайланмады лабаса.

Эльмира Каюмова,
сәнгать фәннәре кандидаты. ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

СИНЕМАТОГРАФ – Француз теленнән килгән сүз – «җанлы фотография», «җанлы картиналар». Башкача – *кинематограф*. 1. Кинотеатр, фильмнар күрсәтелә торган бина; 2. Тулаем кино сәнгате.

Француз уйлап табучысы Люмьерның тамашачылар өстенә «ажгырып» килә торган курьер поезды төшерелгән мәшһүр лентасы Россиядә беренче тапкыр 1896 елда Түбән Новгород күргәзмәсендә күрсәтелә. Шул ук елны аны Мәскәүдәге «Эрмитаж» бакчасында тамаша кылалар. Казанда исә «җанлы фотографияләр» беренче тапкыр 1897 елда шәһәр театрында демонстрацияләнгән. Казанда синематограф тарихыннан кайбер мәгълүматларны җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың хатирәләреннән табарга мөмкин.

СИНЛӘР – Борынгы төркичәдә «сез» алмашлыгы («син»нең күплек саны). *Мен сенләргә болдум каһан.* Мәхмүд Кашгарый сүзлегеннән (XI гасыр).

Фото tatarstan.ru сайтыннан алынды

Өремче шәһәрендәге татар мәчете

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынан басылып килә.

СИНЬЦЗЯН – «Кытай Төркестаны», «Шәркый Төркестан», кайчагында «Гарби Төркестан» да диләр – Кытайда Ислам мәркәзе. Хәзерге вакытта автономияле район (Синьцзян-Уйгыр провинциясе) булып исәпләнә, мәйданы 1,6 миллион кв.км (ягъни Франция территориясеннән өч тапкыр зуррак), башкаласы – *Өремче*. Массакүләм кытайлаштыру сәясәте үткәрелүгә карамастан, төбәктә төрки чыгышлы 16 миллион мөселман исәпләнә (башлыча сөнниләр). Суфи дәрвишләр тырышлыгы белән монда Ислам XIV гасырның беренче яртысында инде тәмам тамыр җәя (уйгырларда будда динен кысрыклап чыгара).

Мәшһүр «Ефәк юлы» шушыннан үтә.

Бу провинциянең тарихында Казан татарларының исемнәрен байтак очратасың.

СИТСЫ – Киҗе-мамык тукыма. Диалектта – читсе/читсы. Бу сүз – асылда голланд теленнән, безгә нимес -поляк-рус телләре аркылы үтеп кергән (русчасы – ситец). Үзбәк сүзлекләрендә – чит, гәзләмә. Төрек телендә – басма. // Аклы ситсы – ак төс өстенлек иткән тукыма.

СИУ КАБИЛӘСЕ – XVII-XVIII гасырларда Төньяк Америкада Миссури елгасы бассейнында һәм Олы дала территориясендә, Миссисипидән алып Кыялы тауларга, Калифорниядән алып Арканзаска кадәр яшәгән кавем. Сиу кабиләсе ирек сөючәнлеге белән аерылып торган, ак колонизаторларга каршы батырларча көрәшкән. 1852, 1872, 1890 елларда алар изүчеләргә каршы баш күтәргән. Колонизаторлар миллионлаган индианнарны юк иткән. 1963 елгы исәпләүләргә караганда, сиу кабиләсеннән хәзер 77 мең чамасы гына кеше калган, алар Төньяк һәм Көньяк Дакота, Каролина, Монтана, Небраска штатларында резервацияләрдә яши. Сиу кабиләсе берничә төркемгә бүленә: дакота-ассинбойн, мандан, виннебаго, жидатса, апсарака һ.б. Аларның телләрендәге төрки телләр белән охшашлыкка узган гасырда ук игътибар иткәннәр. Отто Рериг дигән галим 1866 елның көзендә Төньяк Америка индианнарының сиу кабиләсендә яши, аларның телен өйрәнә һәм аларның телендә төрки параллельләрнең шактый күп икәнлеген күрә. Безнең гасырның 70 нче елларында татар галиме Әбрар Кәримуллин һәм Сочидан рентгенолог М.Арибжановлар матбугатта бу мәсьәләгә кагылган чыгышлар ясады. Галимнәр бу фактны кайчандыр (безнең эраның 30-15 нче меңьеллыклары арасында) Евразиядә яшәгән төркиләрнең хәзерге Беринг бугазы булган урындагы коры җир «күпере» аша Төньяк Америкага үтеп керүләре һәм әкренләп көньякка таралулары белән аңлата. Хәер, Ә.Кәримуллин Азия төркиләре Америкага Тын океан аркылы да юл ачкан булырга тиеш, дип саный.

Фото VseDomaRossii.ru порталдан алынды

СЛУЖИЛО-ТАТАРСКАЯ УРАМЫ *тар.* — Казанда йомышлы татарлар урамы. XVIII гасырның икенче яртысында барлыкка килгән. Хәзерге Тукай урамы. Хакимиятләр анда йомышлы татарларга гына яшәргә рөхсәт иткән. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2017

ГАРМУН САЙРЫЙ САНДУГАЧТАЙ...

Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

ТР Милли музеенда Идел-Урал буенда яшәүче милләтләрнең һәм башка халыкларның традицион һәм профессиональ музыка уен кораллары саклана. Алар арасында гармуннар — иң кадерле ядкярләрдән.

Фәйзулла Туишев гармуннары – Милли музейның йөзек кашы. Аларның саны егермедән артык, һәрберсенең үз исеме бар: Гөлҗамал, Мәликә, Мәрьям, Асия, Бәдрениса, Фәхрениса һ.б.

Гүзәлия Җәләлева әзерләде. ■



Игелекле Фатиха ядкяре

Тәэминә Биктимерова

2016 елның 24 ноябрендә Казанның кыз балалар гына укый торган 12 нче татар гимназиясендә мәгърифәтче һәм иганәче Фатиха Габделвәли кызы Аитова музее ачылды. Әлеге уку йорты да аның исемен йөртә.

Ни өчен нәкъ менә аңа, аның исемен мәңгеләштерү өчен эшләнде бу изге гамәл?

1869 елның 25 гыйнварында Троицк шәһәрендә атаклы миллионер Яушев Габделвәли һәм аның җәмәгате, алдынгы карашлы, зыялы Мәүдүдә ханым гаиләсендә туган ул. Моңарчы биографиясен өйрәнгәндә күп кенә ак тапларга очрарга туры килгән иде. Бары Казанда яшәгән оныклары истәлекләренә генә таянып язылды мәкаләләр. Чыннан да нинди гаиләдә туган, әти-әниләре, туганнары кемнәр һәм нинди һөнәр ияләре булган икән? Яушевларның тарихыбызда тоткан урыннары ничек? Аллага шөкер, Троицкига баргач, кулыма «Ислам на Урале. Энциклопедический словарь. Выпуск V. Москва-Нижний Новгород. ИД «Медина», 2009» дигән китап эләкте. Китапның 415-418 битләре Яушевларга багышланган. Аларның бабалары 1552 елда Казанны саклаучылар арасында булганын белеп сөендем. Чыгышлары безнең Әтнә ягыннан, Иске Мәңгәрдән булган икән. Урыслар Казанны алгач, Троицкига китеп урнашкан. Тырыш хезмәт белән байлык туплап, миллионер сәүдәгәрләр булып китә алганнар. Милләтебезгә күрсәткән игелекләре китапта язылган. Укыган кешегә бик файдалы, гыйбрәтле сүзләр күп анда.

Ярар, сүз Фатиха ханым хакында бит әле. 1887 елда Казан бае, шулай ук миллионер Сөләйман Мөхәммәтҗан улы Аитовка (1862-1922) кияүгә чыга ул. Сөләйман Аитов Казанда сәүдәгәрләр банкысының идарә әгъзасы, 1897-1901 елларда шәһәр Думасы гласные (депутаты), күренекле иганәче. Ятим балалар йортына, мәчетләргә, ваба чире белән авыручылар өчен хәстәханә төзеп, аны ачуга да зур чыгымнар тоткан. Сөләйманның гыйлем иясе булуы хакында Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы булып торуы сөйли. Гаилә тормышында күңелсезлекләр еш булган икән. Өч мәртәбә өйләнсә дә, өч хатыны да бала тапканда вафат булган. Татар хатынына рус табибын чакыру оят гамәл булып, үз акушерларыбыз әзерләнмәгән вакыт бу.

Фатиха Аитова

18 яшьлек Фатихага яучы булып Троицкига олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗани үзе барган. Гомер буе Фатиха апа аны үзенең рухи остазы дип санаган, хөрмәт белән искә алган.

Ред.: Фатиха Аитова музееннан фоторепортаж һәм Тәэминә Биктимерова сөйләгәннәрнең видеоязмасы белән ***beznenmiras.ru*** сайтында танышырга мөмкин.



Сөләйман һәм Фатиха Аитовлар уллары (сулдан уңга) Исмәгыйль, Йосыф, Касыйм, Якуб, Ибраһим белән

1897 елда Казанның Постау бистәсендә Фатиха һәм Сөләйман Аитовлар ятимә кызлар өчен һөнәр мәктәбе ача. Казан губернасында ачлык булган ел бу. Ачлыктан интеккән ир-егетләрнең Бакудагы нефть, балык промыселларына китәргә мәҗбүр булуы тарихта билгеле. Донбасс, Себер ягындагы шахталарда да татар егетләре күмер чапкан. Казан губернасындагы авыллардан эш эзләп читкә китүчеләрнең саны 1899 елда 154185кә җиткән.

Ә кыз балалар, тол хатын, ярлы-ятимәләр ризыкны кайдан тапсын? Тарих сәхифәләрен, архив документларын укысаң, тын кысыла. 8-9 яшьлек кызлар асрау булып ялланырга мәҗбүр булган. Ярлы крестьяннарның коточкыч авыр хәле үз кызларын сату хәленә китереп җиткергән. Гасыр башында чыга башлаган «Йолдыз», «Фикер», «Казан мөхбире», «Вакыт» газеталары кызларның фаҗигале хәле хакында даими рәвештә хәбәр урнаштырып торган. Мисал өчен, 1907 елгы «Йолдыз» газетасы «Ачлыктан кыз сату» дигән мәкаләдә түбәндәгеләрне яза: *«Казан губернасы, Тәтеш өязе «Үш» карьясендә (авылында) Хәлилә исемле 19 яшьлек кызны йөз сумга, «Бураш» карьясендә Бибисара исемле 18 яшьлек кызны алтмыш сумга, Гыйззелбәнат исемле 20 яшьлек кызны алтмыш сумга, Маһибәдәр исемле 22 яшьлек кызны җитмеш сумга сатканнар. Бу сәүдәнең махсус маклерлары да бар»*. 1910 елгы «Идел» газетасында: *«Бер кеше, кызларын саткан ата-аналар карьясенә барып бакса, шик юк ки, кан елар иде»*, – дип язылган.

Мондый хәлләргә тыныч кына карый алмаган иманлы байларыбыз, шөкер, булган. Фатиха апа белән Сөләйман абыйлар ачкан һөнәр мәктәбе дә – шул ярдәмнең күркәм бер мисалы. Кызлар монда тегү, чигү, мех теркәү, чүәк-кәвеш тегәргә өйрәнә башлаган. Ачлыктан котылу өчен бер чара бит: эшләнмәләрен саткач, кызлар үз көннәрен үзләре күрә алган, аз гына булса да, матди хәлләре җиңеләйгән.

1909 елда хәзерге Тукай урамында кызлар өчен икенче мәктәбен ача Фатиха апа. Мәктәптә уку срогы башта 4 ел, соңрак 9 ел була. Хәзер инде кул

һөнәреннән башка дини һәм дөньяви фәннәр укытыла, аш-су осталары да әзерләнә башлый. Мәктәптә әхлак, гигиена, җыр дәресләре кертелә. Нәкъ менә шушы мәктәптә белем алган татарның җырчы сандугачлары Сара Садыйкова, Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләймановалар халкыбызның мәңгелек горурлыгы була алды. Бу мәктәптә хәллерәк кешеләрнең кызларына бераз акча түләү куелган. Ярлы кызлар бушлай укыган, аларга көн саен сөт тә бирелгән. Читтән килүчеләр өчен пансионат ачылган.

Күңеле гел изгелектә булган Фатиха ханымның. Ул инде татар кызлары өчен гимназия ачу теләге белән хыяллана башлаган. Бу уе 1913 елда, Россиядә Романовлар тәхеткә килүенә 300 ел тулу уңае белән бәйрәм итү көннәрендә тагын да көчәйгән. Сөләйманы белән өч ел рәттән Берлин, Вена, Прага кебек шәһәрләргә барып, гимназияләргә кереп, уку тәртипләре белән кызыксынулары да юкка гына булмаган икән.

Рус кызлары өчен ачылган гимназияләрдәге уку тәртипләре белән генә канәгатьләнмичә, татар кызлары өчен ачылачак гимназиясен Европадагы алдынгы уку йортлары югарылыгына күтәрмәкче булган ул! Уку әсбапларын күпләп кайтартулары шул хакта сөйләмимени?

Элекке байларда урнашкан гадәт буенча, йорт шартларында менә дигән белем алган ханым, булачак гимназисткаларның анкетасындагы «Кайсы телне өйрәнәсегез килә?» дигән сорауга рус һәм татар, гарәп телләреннән тыш, немец, француз, инглиз телләрен дә күрсәткән. Сокланмый мөмкинме?

Татар кызларының борынгыдан ук белем алуга мәхәббәт-теләкләре зур булганын да бик яхшы күздә тоткан бу зыялы ханым. Ә татар кызларының шушы изге, матур теләкләре хакында безгә хәзер күпме әдәбият, күпме халык иҗаты әсәрләре сөйли. Мисалга «Җиде кыз бәете»н генә искә төшерик әле:

Каргалының урамында
Карга бастым боз диеп.
Унике ел укып йөрдек,
Белмәделәр кыз диеп.

Бәет җиде кызның ирләр кыяфәтендә унике ел буе ирләр мәдрәсәсендә укып йөргәне хакында сөйли. Нинди матур югары әхлак, никадәр тырышлык соралгандыр бу кызлардан. Инде мәдрәсә тәмамлап чыкканда гына мулла улы, сизеп алып, берсенә өйләнеп кала алган бу каһарман (батырлык дими, ни дисең?) кызларның. И, халкымның нинди генә ул-кызлары булмаган, рухлары мәңгегә шат булсын, Амин!

Фатиха ханым гимназиясен 1916 елның 29 октябрендә тантаналы шартларда ача алган. Татарның ир балалары өчен дә гимназия ачылмаган бервакытта, патша хөкүмәте шартларында, берүзе ачкан! Без милли күтәрелеш шартларында да милли университетны ача алмадык. Хәзер татар кызлар гимназиясе бар, шөкер. Әмма татар теленнән башка фәннәр рус телендә укытыла. Сәбәбе аңлашыла, кабатлап тору кирәкмидер, мөгаен.

Татар кызлары гимназиясе шул дәрәҗәдә генә булса да әйбәт хәл, дип саныйм. Исеме дә Фатиха Аитова исемен йөртә. Исемен куйганда да каршы төшүчеләр булды булуын.

Кызларга игелек эшләгәндә байлыгын да, сәламәтлеген дә кызганмаган бу изге җанның Совет власте бар мал-мөлкәтен, уку йортын да тартып алган. Хәтта бер тиен пенсия дә түләргә кирәк санамаган. Мәгариф министрлыгы исеменнән Исхак Рәхмәтуллин (ТАССРның мәгариф халык комиссары) Мәскәүгә берничә гариза язып караган. «Персональ пенсия алырга» хаклы дип, хезмәтләрен санап күрсәткән. Бирмәгәннәр. Ике улы – Ибраһим белән Йосыф (икесе дә югары белемле), репрессиягә эләгеп, лагерь газапларын кичергән кешеләр. Азат булгач та, күп еллар Казанда яшәргә рөхсәт ителмәгән әле аларга. Ибраһим Аитов

вафатына кадәр Ростов-Дон шәһәрендә яшәгән. Күренекле дин белгече, «Йолдыз» газетасының мөхәррире һәм нашире Әхмәтһади Максуди кызы Шәфикага өйләнгән. Шәфика ханым Ростовтагы Тимер юл инженерлары әзерли торган институтның чит ил телләр кафедрасы мөдире иде. Ибраһим Аитов яңа сорт виноградлар уйлап табып үстереп, аларга Ф.Әмирхан, Г.Тукай исемнәрен биргән. Атаклы сәяхәтче Тур Хейердал белән дуслашып, аны үз йортында гаиләсе белән ике тапкыр кунак та иткән.

Фатиха апа, 1922 елда Сөләйман абыйны җирләгәч, төпчек улы Якуб гаиләсендә Мәскәүдә яши. 1941 елда Якубны гаиләсе белән эвакуациягә мәҗбүри җибәргәч (бай баласы, янәсе), Йосыф исемле улының хатыны Мәрьям апа кулында кала. Кулына кала, дип язуымның сәбәбе шул: Фатиха апа бу вакытта бик нык авыру була, 16 ай буе тора алмый, урын өстендә тән һәм җан газаплары кичереп ята. Йосыфы да, Ибраһимы да әле тоткынлыкта. Фатиха Габделвәли кызы Яушева 1942 елны бакыйлыкка күчә. Урыны җәннәттә булсын.

Музей ачарга республика җитәкчеләреннән рөхсәт сорап, без дүрт кеше бардык: мин, Роза Туфитуллова, гимназия директоры Илһамия Тимеркәева һәм укыту эшләре буенча директор урынбасары Фирая Шәйхиева.

Материаллар табуда фидакярлек күрсәткән журналист Вера Хәмидуллинага рәхмәтем зур: Троицк шәһәренә барып, 88 фоторәсем, метрика кәгазьләрен алып кайтып бирде. Фатиха Аитова мәктәбендә эшләнгән чигү, тегү үрнәкләрен дә ул китерде. Илһамия ханым да күңеле белән якын итеп, зур тырышлык күрсәтте, булачак музей өчен күпме борчылды. Яхшылык үзенә дә яхшылык булып кайтсын, ярабби! Соңрак безгә Татар хатын-кызлары берлегенең «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Кадрия Рәис кызы да кушылды һәм үз көчен, вакытын кызганмады.

Л.Гобәйдуллин фотосы

Тәэминә Биктимерова гимназия укучыларын Фатиха Аитованың тормыш юлы белән таныштыра

ТР Милли музее хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Алсу Данил кызы Хәйруллинаның тырышлыгын аерым күрсәтәсем килә. Музейны ачуда ярдәмен кызганмаган Мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттаховка һәм аның хезмәткәрләренә дә зур рәхмәт. Татар мәгарифе тарихында мәгърифәтче хатын-кызга ачылган беренче һәйкәл бу!

Фатиха Аитова музее ачылды. Йә, Раббем, гомерлек булсын! Исемен әйтүгә, сүзебез рухына шатлык өстәсен. Амин. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның гыйнвар ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөселманнар өчен аш ханәсе

Шәһәр идарәсе фәкыйрь мөселманнар өчен Яңа бистәдә Салихҗан хәзрәт мәсҗиде мәдрәсәсендә ашханә ачкан. Ашханәнең попечительлегенә мелла Садыйк Иманколый, мелла Габдулла Бәдигов һәм Гыйләҗетдин Монасыйпов сайланганнар.

Кояш. – 1917. – №1065. – 10 янв.

Мөселман журналлар хадимнәренә миһләт [отсрочка]

Депутат Гайсә мирза Еникиев Казандагы «Сөембикә», «Аң», «Ялт-йолт» һәм «Русия сәүдәсе» журналлары идарәләренә хат язып, миһләтләр баш комитетының 4 нче гыйнвар мәҗлесендә мөселман журналлары хадимнәреннән идарә саен өчәр кешегә миһләт бирергә карар кыйлганын белдергән. Ләкин журналчылар, гаризаны мәхәлли [җирле] миһләт комитетына бирмичә, мәркәз комитетка бирергә тиешлеләр икән. Баш комитетның 4 нче гыйнвар мәҗлесенә депутат Гайсә мирза үзе дә кертелгән. Депутат җәнабләре, мөселман журналларының аеруча әхвәл эчендә яшәүләрен, аларның хадимнәренә миһләт бирергә тиешлеген мөкәммәл сурәттә исбат иткән. Һәрхәлдә, Гайсә мирзаның кирәк мөгаллимнәргә, кирәк матбугат әһеленә миһләт бирелү эшендә зур иҗтиһады күренде.

Кояш. – 1917. – №1066. – 12 янв.

Шәһәр Думасына мөселманнар

Шәһәр Думасына мөселманнардан әгъзалар билгеләр өчен тәшкил ителгән комиссия утыз ике кешене чамалап билгеләп куйган. Бу һәйәт [комиссия] мәҗлесендә рус партияләреннән кайсысына кушылырга мәслихәт икәне русларның оешып бетмәгәне өчен хәл кыйлынып бетмәгән әле. Рус партияләренә кушылганда түбәндәге шартларны гарыз итәргә уйлыйлар икән: 1) управа әгъзаларының икесе мөселманнан булырга; 2) һәр комиссиядә бер кеше, мәктәпләр комиссиясенең өчтән бере мөселманнан булырга; 3) шәһәр карамагында булган мөәссәсәләргә [оешмаларга] кеше сайлаганда, һәр мөәссәсәдә мөселманнарның өчтән бер микъдарында булуына тырышырга; 4) шәһәр карамагында булган ирләр гимназиясе илә кызлар тиҗарәт [сәүдә] мәктәбен мөселманнарга якын булсын өчен Болакның бирге ягына күчерергә; 5) Яңа бистә дамбасын су басмаслык дәрәҗәдә күтәрергә.

Кояш. – 1917. – №1071. – 24 янв.

* Даталар иске стиль белән бирелә.

Мөселманнар теләге

Шәһәр главасына йөздән артык имза белән мөселманнардан ошбу мәзмунда [эчтәлектә] гариза бирелгән: «Соңгы көннәрдә шәһәрдән сарык ите алып озатучылар күбәйгәнлеге сизелә. Болар пайтәхеткә озатырга җыялар, дип сөйләнә. Хәзерге көндә ат ите беткәнлек сәбәпле, сарык ите бердәнбер азык булып кала ки, бу бетсә, мөселман җәмәгасе уңайсыз хәлгә калачактыр. Сарык итенең бәһасе үткән елгыга караганда ике өлеш күтәрелде.

Без, мөселманнарны уңайсызлыкка төшүдән саклау юлында, кулыңыздан килгән һәммә чараны кыйлуыңызны сездән үтенәмез. Шулай ук шәһәр халкы өчен хайван бугазлау йортында суела торган сарыкларның микъдарын билгеләвеңезне үтенәмез».

Мещаннар тормышына гаид [караган]

Мещаннар старостасы[1] өчен кеше билгеләп куярга дигән җыелышларга килүчеләр аз булганлык сәбәпле, моннан элекке җыелышларда мәсьәлә каралмый калган иде. Инде бу көн якшәмбе, 29 нчы гыйнварда, көндезге сәгать 1дә шушы эш өчен икенче мәҗлес җыелачак. Мәсьәлә әһәмиятле булганлыктан, мәҗлестә мещаннарның күп булуы матлуб [шарт]. Мәҗлескә мещаннарның һәммәсе катыша аладыр. Моннан элекке сайлауларда мөселман әгъза кертә алмаган мөселманнар өчен, бу мәҗлескә бигрәк әһәмият бирүләре вә үзләренең мәнфәгатьләрен күзәтә торган кешене сайларга дикъкать итүләре бигрәк матлубтыр.

Татарча спектакль

Үткән җомга көнне «Сәйяр» труппа мәгъруф [танылган] рус мөхәррирләреннән Найденовның «Ванюшин балалары» дигән 4 пәрдәле драмасын уйнады. «Ванюшин балалары» русларда гына түгел, бездә дә бар һәм бик күп алар. Гаилә эчендә ялгыз үскән, япандагы үлән кебек, үз язмышына тапшырылып тәрбия ителгән балаларның барысы да «Ванюшин балалары» алар.

Пьеса «Сәйяр» труппа тарафыннан тигез генә, матур гына уйналды. Элек бөтен балаларын куырып торган, соңыннан тәүбә кылып, алар белән килешергә уйлаган Ванюшин ролен Кариев шома гына алып барды. Алексей ролен уйнаган 2 нче Камал бик табигый уйнады. Аның бу уйнавы әүвәлге уйнауларыннан бик күп өстен иде. Константин ролен уйнаган 1 нче Камал да ролен тигез генә алып барды. Людмила ролендәге Болгарская үзенең ролен бик матур үтәде. Анна ролендә дә ул гүзәл иде. Елена ролендәге Таҗдарова, Клавдия ролендәге Әхмәдова һәм Шуткин ролендәге Искәндәров зарарсыз иделәр. Ильская белән Нәфигә туташ үзләренең рольләрен бик табигый үтәделәр. Бу кадәр табигыйлек артистка Ильскаядан көтелгән булса да, Нәфигә туташтан бер дә көтелмәгән иде. Шуңар күрә аның бу уенын әйтми китү мөмкин түгел. З.Н.

Кояш. – 1917. – №1073. – 29 янв. ■

[1] Казан губернасында 1870-1917 елларда мещаннар идарәсе булган.

Вак-вак ләтыйфәләр* һәм хикәя кисәкләре

ИКЕ КЕШЕ АРАСЫНДА

– Сез ул кешене яхшы беләсез, әгәр бурыч сораса, аңар ышанырга ярыймы?

– Һич тә шөбһәсез, ярый. Хәтта мин аңар бөтен гомеремне инабәт итеп[1] бирер идем.

– Сез алай әйтерсез әйтүен, ләкин мин аңар бер бәһалерәк нәрсә ышанырга мөмкинме? – дип сорыйм.

КҮРӘЗӘЧЕ ХАТЫНДА

– Сез миңа тик бәхетсезлекләр булачагын гына хәбәр бирәсез!

– Нигә, әллә мин синең илле тиенгә отыш билетының 200 мең сум акча чыгуын вә синең миллионерга кияүгә чыгачагыңны хәбәр биримме?!

КИҢӘШ

Бер саран бай урамда барган табибны туктатты да, акчасыз гына киңәш сорап, файдаланмакчы булды:

– Караңыз әле, табиб әфәнде, берничә көн инде мин бөтен әгъзаларымда каты авыру хис итәм. Хәтта кайчакта, авыртканына чыдый алмыйча, бик каты кычкырам да. Табиб әфәнде, сез үзеңезгә мондый хәлләр вакыйг булганда нишлисез?

– Ачык әйтә алмыйм әйтүен дә, сезнең урында булсам, мин дә бик каты акырыр идем шикелле.

Ялт-йолт. – 1913. – №49. – Б.10.

ТӘМӘКЕ ТӨТЕНЕНДӘ

– Казылыгыңыз бик шәп коптить ителгән икән, әллә Габдулла Килдишевтан[2] алдыңызмы?

– Юк, үземез тутырган казылык. Ул кыш буе иремнең бүлмәсендә эленеп торды, ә ирем минем бик күп тәмәке тарта. Менә шунда, тәмәке төтенендә, ул бик шәп булып коптиться иткән.

Ялт-йолт. – 1913. – № 49. – Б.12.

ЯҢА ЕЛ ТЕЛӘКЛӘРЕ

«Вакыт»ның шикле рәсемнәр басып, «Кояш» абзый кармагына эләкмәвен.

«Йолдыз»ның Казан хәбәрләрен күбәйтүен.

«Кояш»ның очраган берәү белә ызгышмавын.

«Аң»ның аксауда мужик атына тәкълид[3] итүен.

«Сүз»нең дәвамын һәм алтынчы номердагы кебек тозсыз фельетон язып пычранмавын.

*Ләтыйфә – күңелле, көлкеле, үткен мәгънәле кыска хикәя, мәзәк.
[1] Инабәт итеп – ышанып
[2] Габдулла Килдишев – Казанның Мәскәү урамында казылык кибете тоткан сәүдәгәр, нашир.
[3] Тәкълид – ияру, охшатып эшләү.

Рәсем өстендә: «Яңа ел алдыннан татар журналлары идарәсендә бер көнлек хисап».

Рәсемдә: «Безнең журналистлар»

Рәсем астында: «Бу күренештән көләргәме әллә җыларгамы? Буны шушы хәлдән бик күпне көткән кешенең үзенә калдырабыз».

«Акмулланың» шул җүләрлегендә дәвам итеп, мөбарәк исемне пычратуын, ләкин соңыннан тәкъдир себеркесе берлә матбугат чарлагыннан себерелүен.

«Шура»ның идарә карзинкасы зуррак эшләвен.

«Ак юл»ның шул эзеннән барып эт, мәче сурәтләреннән бер көтү ясавын.

«Заман календаре»ның хата, ялган мәгълүматлар берлә халыкны ныграк адаштыруын.

Фатыйх Әмирханның «Урталыкта»сына «Хәят» биреп чынландырмавын.

Мөфтигә каршы торуда, гәзитәләр берлә сугышып, шөһрәт алган тагы берәр мөхәрриребезнең энесенә имамлыкка шәһадәтнамә алып бирер өчен мөфти алдында баш июен.

Ялт-йолт. – 1916. – № 103. – Б.10.

*Текстны һәм искәрмәләрне басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

2016 елның 7 декабрендә Казанның «Истанбул» паркында Садри Максудига һәйкәл ачылды. Авторы – сынчы Асия Миңнуллина

«Безнең мирас»

елъязмасы / гыйнвар

● 285 ел элек (1732)

Күренекле мәгърифәтче, педагог һәм тәрҗемәче Сәгыйт Хәсән улы Хәлфин (1732-1785) дөньяга килә.

● 195 ел элек (1832)

Сәгыйт Хәлфиннең оныгы, күренекле мәгърифәтче Ибраһим Исхак улы Хәлфин (1778-1825) «Әхвәли Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле әсәрне китап итеп бастырып чыгара. Язма нөсхәләре XYIII гасыр башларында барлыкка килгән дип саналган бу әсәрнең авторы билгесез.

● 90 ел элек (1927)

Татарстан гыйльми үзәге тел белгече Җамал Вәлидигә татар теленең тулы сүзлеген эшләп чыгуны тапшыра.

● 80 ел элек (1937)

24 гыйнварда Муса Җәлилнең «Алтынчәч» исемле опера либреттосының беренче вариантын укып тикшерү була.

● 70 ел элек (1947)

31 гыйнварда татар дәүләт академия театры Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» исемле әсәрен сәхнәгә куя.

● 60 ел элек (1957)

«Совет әдәбияты» журналында Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясе басылып чыга.

● 55 ел элек (1962)

29 гыйнварда әдип Кәрим Әмири (1893-1962) вафат була.

● 50 ел элек (1967)

«Казан утлары» журналында Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повесте дөнья күрә башлый.

● 45 ел элек (1972)

«Казан утлары» журналында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы басыла башлый.

● 25 ел элек (1992)

9 гыйнварда «Мәгариф» Бөтентатар милли берлеге оеша. Берлекнең максатлары – татар милли мәгарифен үстерү, Татарстан Республикасының халыклары телләре турындагы законнарын тормышка ашыруда катнашу, татар милли мәгариф хезмәткәрләрен хокукый һәм социаль яклауны тәэмин итү. ■

Мирасворд

Шәрык илләрендә йөк ташучы

Яшертен сүз, хәбәр, донос

... утыру

Гарәп артикле

Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйре

Әдһәм ... (тел галиме)

Туфан, Сарьян

Кәҗә бәтие (диал.)

... нарат (ылыслы агач)

Борынгы грек драматургы

Мал табибы (иск.)

Н.Фәттахның «Итил суы ака торур» романындагы персонаж

Испания һәм Франциядә яшәүче халык

Сицилия утравындагы янартау

Эре бөртекле әйберләрне төеп ваклау өчен агач савыт

Химик элемент

Нота

Фатих Әмирхан повесте

Теше, ана (диал.)

Коелган орлыктан үскән иген (диал.)

1906 елда Оренбургта татар телендә чыккан юмор-сатира журналы

Леонардо ... Каприо

... Таһир (фин татары, профессор)

Россиядә элеккеге җир үлчәү берәмлеге

Миргазиян, Рәфикъ

Рифкать Гомәров оештырган һәм җитәкләгән ансамбль

Һәвәс, оста, маһир (иск.)

Казандагы Тукай вафат булган хастаханә

Чыңгыз ханның законнар җыелмасы

Кайсын Кулиевнең милләте

Түгәрәк камырга изгән бәрәңге ягып пешерелгән камыр ашы

Дүрт яшьлек ат

Гарәп хәрефе

Борынгы грек фәлсәфәсендәге төп төшенчәләрнең берсе

Урта гасыр Болгар шәһәре

... - Ланка

Күрәзәлек, юрау

Триумфаль ...

... Брегвадзе

Рәис Габдулла төзеде.

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: сәмруг, имам, Зәки, Камали, Әюп, Мутин, микадо, аргын, Шу, «Белек», турма, вафа, Өлә, вәгазь, амт, Акыш, мәте, бәз, Максат, Рәми, мәрә, фам, Мар.
Өстән аска: Алишев, Шәрәф, кулавыз, ра, скифата, ефәк, ләм, каган, Азимов, Әмир, төзем, катапульта, Гази, ир, Рә, Әкрам, Әнгам, Әсма, аем, Амур, пинә, тати.



СОДЕРЖАНИЕ

Историческое наследие: «Булгар. Ремесленные мастерские»; «Странники». А.Мухаммадиев; «Наследие летописей белорусских татар». З.Канапацкая; «Вам от меня светлые пожелания...» М.Файзи; «Воспоминания». Б.Галиев; «Неуступчивый профессор» Садри Максуди». А.Сибгатуллина.

Татарский мир: «Минтимер Шаймиев». Р.Бухараев; «Минтимер абыкай». М.Ильясова; «Мой ученик – Президент!» Х.Ахмадуллина.

Духовное наследие: «Габдерашит Ибрагимов». А.Рахимова; «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Кутадгу билик». («Благодатное знание»). Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана». Ч.Айтматов; «Зульфат хан или в чаще поет соловей». Л.Лерон.

В глубине памяти: «Уроки отца». Р.Валиев; «Спасибо ему!» Р.Сахабиев.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин.

На страже памяти: «Гармонь заливается соловьем...» Г.Залалева; «Память благодатной Фатихи». Т.Биктимерова.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: январь 1916 года». Л.Губайдулин.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

Historic heritage: «Bulgar. Craft workshops»; «The pilgrims» by A.Mukhammadiev; «The heritage of the Belorussian Tatars' manuscript» by Z. Kanapatskaya; «The bright wishes from me to you...» by M.Fayzi;«The memoirs» by B.Galiev; «Pertinacious professor by Sadri Maksudi» A.Sibgatullina.

The Tatar world: «Mintimer Shaimiev» by R.Bukharaev; «Mintimer abiykay» by M.Ilyasova; «My pupil is the President!» by Kh.Akhmadullina.

Spiritual heritage: «Gabderashit Ibragimov» by A.Rakhimova; «Islamic world» by G.Ibragimov.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; «Zulfat khan or The nightingale signs in the thicket» by L.Leron.

From the depth of memory: «Father's lessons» by R.Valiev; «Say thank to him» R.Sakhabiev.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin.

On the guard of memory: «Accordion sings like a nightingale...» by G.Zalaleva; «The souvenir of gracious Fatikha» by T. Biktimerova.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: January of 1916».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Истанбул».
Киндер,
майлы буяу.
2013 ел

РӘШИТ ГАЗИЕВ

«Болгарда тәрәзә».
Киндер,
майлы буяу.
2003 ел

Театр рәссамы, нәкышче Рәшит Хамис улы Газиев 1954 елның февралендә Казанда туа. 1974 елда Казан сәнгать училищесын, 1980 елда исә Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кино институтын тәмамлый. Ул – Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты (2007), Татарстан Республикасының халык рәссамы (2009).
Рәшит Газиевның әсәрләре Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм Татарстанның Дәүләт сынлы сәнгать музейларында, шулай ук М.Горькийның әдәби-мемориаль музеенда саклана.

www.beznenmiras.ru

ИНДЕКС:

ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)

РОССИЯДӘ – 70275

Тәртип
93.5 FM
халык радиосы

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) һәм «ТАТМЕДИА» бинасындагы китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан киоскларыннан, элемтә бүлекләреннән сатып алырга мөмкин.

№01 / 2017